Безнен
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
06
июнь 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Миргазиян Юнысның беренче хикәясе
67 бит

Татар Кәләпүшкине. Кем ул?
78 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

06
(318)
июнь 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Рафаил Төхфәтуллин

ТАРИХИ МИРАС

4 «Идегәй» – халык дастаны. *Л.Мөхәммәтҗанова*
6 Итәге (Итүк батыр)
16 Хан Урдасы (Хан Ставкасы) татарлары. *Г.Мырзагалиева*
24 Исемдә калганнар. *Г.Төхфәтуллин*
30 Фамилияләребез. *Г.Хаҗиева*
34 «Сугыш сафы» газетасы. *Л.Гобәйдуллин, Р.Шәрәфиева*
38 *Мирхәйдәр Фәйзи:* «Күңелем гүя оҗмахка керде»
45 Буыннар бәйләнеше. *К.Тукаева*
50 Тарих көзгесендә Кыр Бикшиге авылы. *Н.Каштан*

ДИНИ МИРАС

55 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)**

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, А.Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ӘДӘБИ МИРАС

60 Исфәндияр Ишгай шигырьләре
64 Мәскәүгә – Миргазиян абыйга. *Л.Лерон*
67 Безнең өй өянкеләр астында иде... *М.Юныс*
75 Хушлашмый да китеп бардың. *С.Зыялы*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

78 Мәхмүт Хөсәен вафаты. *Л.Лерон*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 Барудиның кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
82 Прокурор. *Ф.Нәфиев*
89 Сугыш еллары кайтавазы. *Г.Җиһангирова*
92 Карлыгач оясы. *С.Сәубанова*
100 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

102 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*



105 «Галиябану» спектакле: ике Хәлил, ике Галиябану
106 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 Татар тарихи лексикологиясенә бер караш. *М.Булатова*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июнь*
120 Алхәбәр

Заказ №А-1111. Тираж – 1460 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 27.05.2020. Чыгу көне: 01.06.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Бу сан «Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Габделгазиз Тәхфәтуллин оныклары Рөстәм һәм Мансур белән. Яңа Кенәр, 1956 ел. *(Рөстәм Тәхфәтуллин архивыннан.)*

Тормышта һәркемнең үз сукмагы бар. Әгәр дә кеше үзенең барлык өметен, барлык көчен, омтылышын, акылын тулысынча шушы сукмак буйлап юнәлтә икән, бу инде сукмак кына булып калудан уза, бу инде олы юл. Олы юл — олы тормыш.

Рафаил Төхфәтуллин

Рәзинә һәм Рафаил Төхфәтуллиннар балалары Рөстәм (әнисе янәшәсендә) һәм Мансур белән. Яңа Кенәр, 1955 ел

«...Алга зур өметләр, якты теләкләр белән яшик. Балаларыбызны чын кешеләр итеп үстерик. Бик зирәкләр, бик акыллылар бит алар, киләчәктә аларның зур эшләре белән шатланырлык булсын».

(Язучы Рафаил Төхфәтуллинның хатыны Рәзинәгә язган хатыннан. 10 декабрь, 1957 ел.)

Рафаил Төхфәтуллин

(01.01.1924-18.07.1994)

Тазалык-саулык – үзе бер талант. Аны саклый белү һәм ныгытканнан-ныгыта алу – мондый сәләт һәркемгә дә бирелми бугай.

***

Кешенең характеры – аның язмышы, диләр бит. Димәк, язмышың еш кына үз кулыңда.

***

Нык һәм мул сыйдырышлы хәтер – менә акыл талантының нигезе нәрсәдә!

***

Фидакарьлек һәм дан ярату – кешеләрдәге бу капма-каршы ике сыйфат бервакытта да бергә сыеша алмый. Фидакарьлек еш кына үзеннән-үзе табигый дан алып килә. Ләкин чын фидакарь кеше, аңа карап, һич тә борын чөйми. Үз данына хәтта нәфрәт белән карап, фидакарь хезмәтен дәвам итә. Мондый дан, алтынның үз ялтыравыгы кебек, кешенең үз бизәге ул.

***

Чын әдәби әсәр һәрвакыт бераз музыка да ул. Юк, поэзия әсәрләрендә генә түгел, ә нәкъ менә кырыс проза әсәрләрендә дә музыка яңгырарга тиеш. Әлбәттә, ритм-рифма белән түгел, ә юл араларыннан чын музыка ишетелеп торсын. Укыганда, бу музыка сине тирән дулкынландырып, уйландырып, күңелеңне сафландырсын, нәфисләндерсен.

***

Иҗатның бар бик авыр юлы, бар җиңелчә юлы. Моңарчы ул җиңелчә юл каләмеңне җете кызылга манып язу иде. Ә хәзер, киресенчә, каләмеңне үтә кара корымга манып язсаң – уңасың. Болар икесе дә минем юл түгел. Чөнки алар икесе дә – дөреслектән уңга-сулга тайпылу.

***

Дөньяга якты күз белән карыйсың икән, аның якты яклары һәрвакыт бар. Хәтта кара якларына караганда да күбрәк ул яктылык.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

«Идегәй» – халык дастаны

Лилия Мөхәмәтҗанова

«Идегәй» – халык иҗатының алтын фондына кергән эпик ядкәр. Аның халыкта телдән таралган вариантларыннан алып, әдәби камиллек дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән язма вариантларына кадәр тарих кайтавазы буларак та, шигъри-сәнгати җәһәттән дә гаять кыйммәтле. «Идегәй» – эпик фольклорда дәвамчанлык үрнәге. Сюжеты һәм тематикасына карагандa, бу дастан, XV гасырда барлыкка килеп, шушы вакыттан башлап формалашкан һәм таралган. Һәрхәлдә төрки дөньяда «Идегәй»нең XV гасырда барлыкка килүе Алтын Урдадагы тарихи фактлар, реаль шәхесләр һәм әсәрдә тасвирланган вакыйгалар, геройлар белән раслана. Гасырдан гасырга күчеп, безнең көннәргә тарихи үткәнне һәм дәүләтчелек идеясен китереп җиткергән бу эпос – дөнья фольклорында һәм әдәбиятында, һичшиксез, үз урыны булган масштаблы феноменаль күренеш.

«Идегәй» дастаны ерак гасырлардан телдән-телгә күчеп сөйләнеп килгән. Казан татарларында эпос жанры, язма-китаби үзгәрешләр кичереп, фольклордагыча телдән әйтеп башкарылудан бигрәк, китаби дастаннар рәвешендә үсеш алган. Халкыбызның иксез-чиксез Себер киңлекләрендә яшәүче этник төркемендә эпик истәлекләр «тере» формасында, ягъни сөйләмә формада сакланып кала алган. Бәхеткә, дастан текстлары төрле чорда төрле белгечләр тарафыннан халыктан язып алынган, алар, архивка тапшырылып, хәзерге көнгә исән-имин килеп җиткәннәр.

Эреле-ваклы күпләгән вариантлар арасында 1919 елда Нигъмәт Хәким Себердә Сиддыйк карттан язып алган текст иң күләмлесе санала. Ул вариант фольклор галиме Ф.Вәһапова төзеп бастырган «Татар эпосы. Дастаннар» (Казан, 2004, 640 б.) җыентыгына кертелгән. Заманында, тәгәлрәк әйтсәк, 1915 елда Хафиз Рәхмәтуллин хәзерге Омск өлкәсенең Тара округына кергән Усть-Ишим районындагы Олы Бүрән авылында яшәгән Гафур бабайдан язып алган вариант исә игътибарны үзенчәлекле сюжеты, шигъри өлешенең шактый зур булуы, өстәмә рәвештә килеп кергәнгә охшап торган урыннары белән җәлеп итә. Текст Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең 52 нче фондында саклана. Бу дастан 1940 елда «Кызыл Татарстан» газетасында басылып та чыккан, әмма, ни кызганыч, шул чордан алып «Идегәй»нең Х.Рәхмәтуллин варианты тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала килә. Югыйсә бу ядкәр гасырларны кичкән «Идегәй»нең башка версия-вариантлары рухына һич тә ят түгел. Шуның өстенә, дастанның әлеге варианты, сирәк очрый торган фольклор әсәре буларак, төрки эпос билгеләрен саклавы, тарихи-героик дастаннар төркемендәге эпик истәлекләргә тәңгәллеге белән кадерле. Һәм, әлбәттә, шанлы Алтын Урданың татар ханлыкларына таркалу чорын чагылдыра торган, шул дәвердә дөнья тоткан ханнар, әмирләр, бәкләр хакында хәбәр итәрдәй тарихи чыганак буларак та бик кыйммәтле әсәр ул.

Х.Рәхмәтуллин дастанны язып алганның соңында текстның теленә әдәби үзгәрешләр керткәнгә охшаган. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә»сенә 1940 елда Х.Рәхмәтуллин үз куллары белән тапшырган 42 битлек текстны басмага әзерләгәндә, «Идегәй» текстын язып алучы тәкъдим иткән рәвештә калдырдык. Әсәрнең «Итәге (Итүк батыр)» дигән исеменә килгәндә, монысы да чыганактагыча бирелде. Гомумән, төрки эпоста герой исеменең фонетик үзгәрешләр кичереп төрләнүе эпос канунына туры килә торган күренеш.

«Идегәй» – кайчандыр Алтын Урда составына кергән төрки халыклар өчен уртак мирас. Татар версиясе вариантларын аеру – шартлы гамәл, хәлбуки «Идегәй» дастаны, каләм осталары тарафыннан ничек кенә эшкәртелсә һәм төрле дәрәҗәдәге үзгәртүләргә дучар ителсә дә, аның телдән язып алган вариантлары да, хәтта Н.Исәнбәт исеме белән билгеле, камиллекнең соң дәрәҗәсенә җиткерелгән шигъри текст, ягъни китаби-язма рәвешкә китерелгән җыйналма варианты да – барысы да халкыбызның гүзәл эпик мирасы.

Итәге (Итүк батыр)

(Хафиз Рәхмәтуллин варианты)

Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Үткән заманда Урал убасы[1] аръягында, Идел суы буенда, Саттимер атлы бер морза торган. Кунышы[2] мул, куе күп булган. Аның Кондызбикә атлы сылу кызы булган. Вә янә аның куйларын көтә торган Янбай атлы япанчысы[3] булган. Ул япанчы үзе асыл егет икән. Ерау булган. Куй көткән чагында курай уйнаган, йыр йырлаган. Ул егет морзаның кызы Кондызбикәгә эшкәрә яраган. Кондызбикә аңа ашык булган[4].

[1] Уба – елга.
[2] Кунышы – кереме.
[3] Япанчы – көтүче.
[4] Ашык булган – гашыйк булган.

Көннәрнең берендә морзаның утлагына шомлы бер юлбарыс чапкан. Куйларын кырган. Япанчылары барысы да качып кайтканнар. Нәмә сәбәптән булган икән, юлбарыс япанчы Янбай көтә торган көтүгә кагылмаган.

Бер көнне морзаның торасына[5] шул ук юлбарыс килеп, морза күршесенең бердәнбер баласын алып киткән. Баланы юлбарыс авызыннан коткарып алу өчен, батыр егет Янбайны җибәрергә карар биргәннәр. Япанчы батыр Янбай, морзаның акбүз атына атланып, юлбарысны эзләргә киткән.

[5] Тора – яшәү урыны, кала.

Карагайлы урманның камышлы күле янында юлбарысны эзләп тапкан. Янбай белән юлбарыс арасында каты көрәш башланган. Озак көрәшкәннән соң, Янбай җиңгән. Юлбарысны үткер сөңге белән кадап үтергән һәм аның авызыннан баланың башын алып куенына салган да, юлбарысны ияре артына тагып, торага кайтып киткән.

Баланың атасы, инәсе, ялгыз балаларының башын күкрәкләренә басып, зар иңрәгән. Япанчы Янбайга меңнән-мең рәхмәтләр әйткәннәр.

Сылу кыз Кондызбикәнең безнең Янбайга янә дә ашыгы арткан. Ашау-эчүеннән калган. Шулай да атасына серен әйтүгә йөрәге җитмәгән. Япанчы егеткә кияүгә бирмәс дип уйлаган.

Көннәрнең берендә Янбай көтүдән кайткан. Кара өйдә аш эчеп утырган чагында Кондызбикә кара өйнең ишек тупсасына килгән. Килгән дә, куеныннан ефәк яулыгын алып, Янбайга ташлаган. Әйткән:

– Ефәк яулыгым куеныңа сал,
Мине онытмай исеңә ал;
Бүген далага бармагыл,
Кара өйдә ялгызың кал, – дигән.

Дигән дә киткән. Янбай уйланган-уйланган да кызның серенә төшенгән. Әйткән:

– Кондызбикәм тиккә килмәс,
Ефәк яулык тиккә бирмәс;
Бүген далага бармай калыйм,
Сау башымны авыруга салыйм, – дигән.

Ашын эчкән, ямансулаган булып, ястыкка яткан. Аннан Саттимер морза килгән, килгән дә: «Бүген табынга[6] барасыңмы, әллә йортта каласыңмы?» – дигән. Янбай сырхавын аңлаткан. Морза: «Алайса барма», – дигән. Янбай кара өйдә ялгыз яткан. Кич булган, шәфәкъ баткан, карт-корылар йокыга яткан. Тыш яктан берәү куркыбрак ишек каккан. Ачса, Кондызбикә тупсага басып тора, ди. Янбай аптырап калган. Кондызбикә аңа кулын сузган, кулын сузган да әйткән:

– Көнгә керсәм, уемда син буласың,
Төнгә керсәм, куенымда юк буласың,
Ыруың-көнең атама тиң булмаса да,
Күңелем кошы кунган чәчәк
син буласың.

Аннан Янбайны суырып-суырып үпкән дә чыгып киткән.

Көннәр үткән, айлар үткән, елгаларда күптән-күп сулар аккан. Кондызбикә белән Янбай, төрле хәйләләр күреп, әллә ничә рәт шулай күрешкәннәр. Тора-тора Кондызбикә корсаклы була калган. Корсаклы булуына тугызынчы ай баскан. Көннәрнең берендә Кондызбикә Янбайга әйткән:

– Күңелем кошы кунган чәчәк
син булсаң да,
Ыруың-көнең атама тиң булмады.
Көнем тулып, улың туар дип торсам да,
Йортымда миңа тыныч булмады.
Чулпан йолдыз калыкмаста
мин китәем,
Күз күрмәгән җиргә барып
мин җитәем,
Тулпар юрга айгырым кайтып килер,
Ял астында аның сиңа хәбәр булыр, – дигән.

Чулпан йолдыз калыкмаста, таң атмаста Янбай Кондызбикәне озатып куйган.

Кондызбикә, тулпар юргасын юргалатып, төн киткән, көн киткән, киткән дә көннәрнең берендә күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән илгә барып җиткән. Барып җиткән дә Идел елгасы буенда – карагайлы урманда куныш[7] ясаган. Тулпар айгырын утлауга куйган. Менә бервакыт тулгак тота башлаган. Азапланган, азапланган – баласы туган. Туган да чыр-чыр сыктаган[8]. Аннан баласының кендеген кисәр кеше булмаган. Баласы янә чыр-чыр

[6] Табын – көтүлек җир.

[7] Куныш – кунып чыгу урыны, куыш.

[8] Сыктау – елау.

сыктаган. Ул вакыт урманда сунар кылып йөри торган бер абышка[9] булган. Баланың чыр-чыр сыктавын ишетеп, бу абышка болар янына килгән. Килгән дә баланың кендеген кискән. «Әй, кызым, кай яктан килдең?» – дигән.

Кондызбикә әйткән:

– Ирем белән моннан ерак-ерак илдән күчеп, яхшы җир, малга тук ил эзләп килә идек, моннан еракта – карагайлы урманда куна калдык. Төн уртасында атыбыз пошкыра башлады. Карасак, бер кара аю атыбызга чапкан. Ирем дәррәү аю белән сугыша башлады. Аюны да үтерде, үзе дә авыр яраланып үлде. Иремне күмдем, үзем килүемдә булдым, – дигән.

Аннан Янбайга хат язган. Хатын тулпар юргасының ял астына таккан, таккан да тулпар юргасын камчыман суккан. Тулпар юрга дәррәү юргалап киткән.

Сунарчы абышка таңга калган. «Бу ни кылганың, кызым?» – дигән. Кондызбикә әйткән:

– Туып-үскән илем бар,
Суын эчкән күлем бар,
Юргам илемә кайтар,
Туганым ялын тарар,
Ялын тарап, хәбәр алар, – дигән.

Аннан соң абышка, баланы чикмән итәгенә салып, буйнына аскан. Аскан да Кондызбикәгә әйткән: «Баламчагам юк, кызым булырсың», – дигән. Кондызбикәне өенә алып кайткан.

Балага, итәккә салып китергәнгә күрә, Итәге дип исем биргәннәр. Соңыннан, Итәгене сөеп, Итүк дип атап йөрткәннәр. Кондызбикә сунарчы картта тыныч яши, Итүк матур гына булып үсә башлаган. Ләкин бу яхшы, тыныч тормыш озакка бармаган, сунарчы карт үлгән һәм, тормыш авырланганга күрә, Кондызбикә, баласын күтәреп, эш эзләргә чыгып киткән. Байтак вакытлар эш эзләп йөргән. Туктамыш ханның торасына барып, бер сарай алдына туктаган.

Сарайдан алтын чәлбәрле[10] чапан кигән кеше чыгып килә икән. Кондызбикә аңа очраган. «Әй, морза кеше, сезнең йортка кәнизәк кирәкмиме?» – дип сораган. Ул кеше әйткән: «Мин морза түгел, мин – падишаһ, үзең падишаһның сарае алдында торсаң да, падишаңны белмәгән син нинди хатын буласың?!» – дигән.

Кондызбикә аңа әйткән:

– Күңелнең очса талмас бер
кошы бар,
Һәркемнең эстәп йөргән
йомышы бар,
Мин кермәгән,
мин басмаган сарайларда
Мин күрмәгән, мин белмәгән
күп кеше бар, – дигән.

Аннан хан Кондызбикәгә борылып караган да аның сылулыгына хәйран калган. Аннан сораган: «Ирең кайда, ирең бармы?» – дигән. Кондызбикә: «Ирем юк, мин – тол хатын», – дигән. Хан, көлеп, әйткән:

– Асыл кош читлектә дә
хур булмайды,
Сылу хатын, ире үлсә дә,
тол булмайды, – дигән.

Кондызбикә әйткән:

– Теләр ирсәң, сараеңда
көн булырмын,
Теләмәсәң, сараеңда көң[11] булырмын.

Аннан соң хан кәнизәкләрен чакырып алган да әйткән: «Бу хатын сараемда баш кәнизәгем булыр, кертегез, үзенә аерым чардак бирегез», – дигән.

Көннәр үткән, төннәр үткән. Көннәрнең берендә хан Кондызбикәне чакырткан да әйткән:

– Балаң минең таркын[12]
балам булыр,
Көмештән бишек бөктерермен,

[9] Абышка – карт.

[10] Чәлбәрле – чигелмәле.

[11] Көң – кара эштәге хатын, хезмәтче хатын.

[12] Таркын – тархан.

Такталарын ефәктән үрдерермен,
Түшәге тебеттән[13] *булыр,*
Юргәге[14] *асыл акбүздән булыр,*
Бишек бавын алтыннан
чимәйләрмен[15]*,*
Үзең минең бикәм бул,
Минең теләгем бүген шул, – дигән.
Кондызбикә әйткән:
– Солтаным,
Әй, ханым-иям,
Әлегә сабыр итеп тор;
Иделдә калган энем бар,
Киңәшләшер уем бар;
Энем күрергә киләр,
Изге киңәшен бирәр;
Күп кичекмәс, көтеп тор, – дигән.

Аннан соң хан тынычланган. Еллар үткән, хан тагы бер чакырып сораган. Кондызбикә һәрвакыт хәйлә тапкан... Тора-тора Итәгегә 8 яшь тулган. Торага чыгып балаларман уйнаган. Аю баласы өнендә ни күрсә, шуны эшләр дигәндәен, Итәге дә ханның сараенда күргәннәрен эшләгән: балаларны яу ясап, бер-беренә каршы сугыштырган, аларга чыбыктан атлар ясарга кушкан, яхшы ат ясап китерүчеләренә бүләк биргән, яман ат ясаучыларын сүккән, «булдыксыз яу» дип атаган. Атларын саклау өчен, куралар эшләткән. Аларны көттерергә яуларыннан сакчылар куйган. «Яман ат ясаучы бала яхшы атлы баланың атын урларга тиеш түгел», – дип, яуларга боерык биргән...

Итәгенең боерыгына буйсынмыйча, бер бала берничә тапкыр ат урлаган. Башта Итәге карак баланың бу эшләрен кичергән. Ахырда, төзәлмәгәч, балалар белән бергәләп хөкем ясаган да, ханның баш чаба торган урынына илтеп, карак баланың башын чаптырган.

Аннан соң Итәгенең аты илгә таралган, аны Итәге би дип йөртә башлаганнар.

[13] Тебет – кош мамыгы.
[14] Юргәк – бишек.
[15] Чимәйләү – бизәү.

Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Кондызбикәгә улының бу кыланышы ошамаган, ул улын каты орышкан. Улына әйткән: «Бу эшеңне куй, улым. Ил көткән канга туяр, мал көткән ашка туяр; синең атаң – япанчы, куй бакты, син дә куй бак», – дигән. Акыллы Итәге инәсенең сүзен тыңлаган: көндезләрен далага барып, куй багучылар белән куй көткән. Куй багучылар Итәгене бик яратканнар. Ана кара лачын, соры карчыга һибә[16] кылганнар. Кара лачын, соры карчыга Итүккә бик тиз өйрәнгәннәр. Ул аларман кошлар аулаган.

Көннәрдән беркөн Итәгенең инәсе бик яман авырый башлаган. Авырый башлагач, ул улына әйткән: «Улым, мин сине инде үстердем, синең илең бар, туган җирең бар, атаң бар. Син тагы да үсәрсең, илеңне онытма. Туган атаң, безнең кайгыдан 16 ел буена кан йотып, картайган булыр. Син аны эзләп тап, күңеленә шатлык утын як. Атаң Янбай атлы булыр, ак йөзле, кара кашлы, кара күзле, озын вә шыклы, килешле буйлы, киң җилкәле, тотса, ташны вата торган көчле куллы япанчы булыр. Илең Идел буенда, моннан еракта, Саттимер илендә. Анда барсаң, атаңны табарсың, күңеленә шатлык утын ягарсың. Әгәр мин үлә калсам, атаңа хәбәр бир: мин аңа тугры

[16] Һибә кылу – бүләк итү.

булдым, читләр кулы миңа тимәде, тик атаңның ыруы, көне бабаңа тиң булмады. Бабаң миңа көн бирмәде, илемнән качып, сине тудырдым, саклап буйга үстердем. Барсын да сөйләрсең, атаңның кайгылы күңлен табарсың», – дигән.

Көннәрдән беркөн Кондызбикә үлә калган. Яшь Итүкнең күңелен кайгы баскан. Сәелгә[17] чыккан көннәрдә инәсенең астанасына[18] барган, сыктап-сыктап аны исенә алган.

Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме

Ханның ике хатыны булган, олы хатынының Мардал атлы улы булган. Ханның Итәгене яратуына Мардал инәсенең яман эче пошкан. Итүк өстеннән ханга һәрвакыт әләкли торган булган. Итүкне кыерсыткан.

Көннәрнең берендә ханның гаскәре сугыштан бик күп әсирләр алып кайткан. Әсирләр арасында теге «ак йөзле, кара кашлы, кара күзле, озын вә шыклы, киң җилкәле» кеше дә бар икән. Итәге, әсирләр янына килеп, бу кешедән кем икәнлеге турында сораша башлаган. Ул Итәгенең атасы – япанчы Янбай булып чыккан. Шатлыгыннан яшь Итәге сыктап җибәрә язган. Итәге, атасын таныса да, аңа үзенең кем икәнлеген белдермәгән. Шунда хан килеп: «Әй, улым, башың яшь әле, әсирләрмән сөйләшмә, алар илнең дошманы, аларны гомерлек эшкяр ясарбыз. Эшкяр булып тудылар, эшкяр булып үләрләр», – дип, Итәгегә әсирләр янының китәргә кушкан.

Яшь Итүкнең күзләренә кан тулган. Йөрәге уттай янган, ачуыннан иренен тешләгән. Алай да ачуын басып калган.

Көннәр үткән. Йомалар[19] үткән. Айлар үткән. Янбайны сарайга телче ясаганнар. Ханның кәеф-сафа көннәрендә аны ерлатканнар, курай өрдергәннәр, сорнай тарттырганнар, шулай итеп, Янбай сарайның телчесе булып киткән.

Көннәрдән беркөн, Янбайны ауга алып барыйм, дип сораган Итүк. Хан, Итүкнең сүзеннән чыкмый, Янбайны ауга җибәргән. Итүк кара лачынын – бер иңбашына, соры карчыгасын икенче иңбашына утырткан да Янбай белән ауга киткән. Итүк иң башлап инәсенең астанасына барган. Атыннан төшкән дә инәсенең астанасына башын куйган. Күзеннән мелтерәп[20] яшьләр тамган. Янбай сораган: «Әй, улым, бу кем астанасы, ник сыктайсың?» – дигән. Итүк аңа әйткән:

– Ун ай мине күтәргән,
Азапланып тудырып,
Имчәк сөтен имезгән
Сөекле инәм ятагуй, – дигән.

Янбай сораган:

– Сылу бала тудырган,
Асыл нәсел калдырган,
Җир кочагына алган
Сөекле инәң кем булган? – дигән.

Итүк әйткән:

– Инәм чит илдән килде,
Авыр азаплар күрде,
Ханга кәнизәк булды,
Мине сөйде, үстерде, – дигән.

Янбай сораган:

– Атаң кайда, кем булган,
Кайсы ыруда торган? – дигән.

[17] Сәел – күңел ачу.
[18] Астана – кабер.
[19] Йома – атна.
[20] Мелтерәп – мөлдерәп.

Итүк әйткән:
– Атам булган япанчы,
Морза малын багучы,
Ерлап сорнай тартучы,
Морза күңелен ачучы, – дигән.

Аннан соң Янбай инәсенең вә атасының атын сораган.

Итүк әйткән: «Җир кочагында ятучы инәмнең аты – Кондызбикә. Туктамыш ханга яуда әсир төшкән вә янә минең белән бергә инәм астанасы янында торучы атамның аты – Янбай», – дигән. Атасының буенынна кочаклап-кочаклап үпкән. Аннан соң Янбай, Кондызбикәнең астанасын кочаклап, зар иңрәгән. Куенынна аның биргән ефәк яулыгын чыгарып, күз яшен сөрткән. Ул яулыкта «Кондызбикә» дигән язу булган. Аннан Янбай сорнаен тартып ерлаган:

– Көннәр көттем, төннәр
көттем Акбүз атың,
Килмәде чит илләрдән
хәбәр хатың;
Яшьтән сөйгән яшь ярым
Кондызбикәм,
Айдай йөзең тагын бер күрәлмәдем.
Сөенечле көн сөеп биргән яулыгыңны
Алтын чәчең тараган
көн ябалмадым, – дигән.

Аннан соң алар ауга киткәннәр. Бер тау итәгенә утырып, ханга каршы киңәшкәннәр.

Көннәрдән беркөн Итәге, атасы Янбайны сарайда калдырып, 60 әсир белән бергәләп, үз иленә качып киткән. Хан аптыраштa калган. Вәзире, Кыпчакны чакыртып, Итәгене куып җитәргә һәм аны сарайга кайтарып килергә кушкан: «Итүкне табып китер, сиңа биш йөз кеше бирәм; тере булса, тере тот; тере бирелмәсә, канын түк», – дигән. Кыпчак би Итүкне куып киткән, Идел суына барып җиткән. Караса, ни күзе белән күрсен, Итәге бөтен каекларны алып, Иделнең аръягына чыгып киткән була. Итүк үземән качкан әсирләрмән Иделнең аръягында ут яктырып ята икән. Боларны күрәләр.

Кыпчак Идел аркылы тавыш бирә:
– Итәге дустым, кайтсана,
Итәге дустым, кайтсана,
Иделне кире чыксана,
Ханың-ияң чакырды,
Сарай тулы кымыз, сөт,
Аны кайтып эчсәнә!..

Итүк әйткән:
– Дустым, мине чакырма ла,
Дустым, мине чакырма ла;
Иделне кире кичәлмәм,
Сөт-кымыздан эчәлмәм!

Кыпчак әйткән:
– Итәге дустым, кайтсана,
Иделне кире чыксана,
Ханың-ияң чакыра;
Арысландай күкрәкле
Юлбарыстай сөйрәкле[21]*,*
Чапкан чакта җил җитмәс
Ат бирә тор хан-ияң,
Кайтып менеп чапсана!..

Итүк әйткән:
– Иделне кире чыгалмам,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле
Ат бирсә дә хан-ияң,
Аңа кайтып менәлмәм!..

Кыпчак әйткән:
– Итәге дустым, кайтсана,
Иделне кире чыксана,
Саттимер кызы инәңдәй
Ханның сылу кызы бар,
Сиңа була сылу яр.
Кайгысыннан саргаер,
Утырып калып картаер,
Кайтып кияү булсана!

Итәге әйткән:
– Итәге кире чыгалмас,
Ханга кияү булалмас;
Саттимер кызы инәмдәй
Ханның кызы булалмас;
Кайгысыннан саргайсын,
Утырып калып картайсын;
Кайтам туган илемә,

[21] Сөйрәк – бәдән, гәүдә.

Ыруым торган җиремә;
Алтын чәчен тараган,
Нурлы йөзмән караган,
Ыруыма яраган
Илем миңа кыз табар.
Кыпчак әйткән:
– Итәге кире кайтмасаң,
Ханга кияү булмасаң,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле,
Чапкан чакта җил җитмәс
Тулпар атка менмәсәң,
Яуларың аз, тотылырсың,
Алтын чәчен тараган,
Нурлы йөзмән караган
Кызың биреп котылырсың.
Итүк әйткән:
Саттимер атам ат бирер,
Саттимер атам кул бирер,
Саттимер атам биргән ат
Җил җитмәстәй йөгерер.
Саттимер атам биргән яу
Хан яуларын чигерер.
Идел суын кичәрмен,
Илемә аклык бирмәсә,
Ханның канын эчәрмен!
Алтын чәчен тараган,
Нурлы йөзмән караган,
Ыруыма яраган
Илем биргән кызымны
Алдыма алып кочармын...
Кайт син ия-ханыңа,
Әйт син ия-ханыңа:
Яман уен ташласын,
Йортыма аяк басмасын;
Йортыма аклык бирмәсә,
Идел суын кичәрмен,
Сараенда-тәхетендә
Ханның канын эчәрмен!..
Әй син, дустым, Кыпчак бик,
Ханга телче булганчы,
Йортыңа телче булсаңчы.
Агыйделең биргәнче,
Ак итеңне бирсәңче;
Йортың ханга кол булды,
Кунышың ханга пыл[22] булды;
Ханга телче булганчы,
Миңа телче булсаңчы! – дигән.
Кыпчак би кайтып киткән.

Итәге каекларны яргалап утка яктырган да үзенең юлдашларыман китә барган. Бер көн киткән, бер төн киткән. Карасалар, алларында ялан атка атланган йөзләп кеше килеп утыра. Алар да тукталган, болар да тукталган; алар ягыннан да батырлары атын юргалатып алга чыккан, бу яктан да Итүк атын юргалатып алга чыккан. Чыккан да Итүк аннан сораган: «Сез кай илдән килүче юлаучылар?» – дигән.

Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Теге батыр әйткән:
– Мин урыс ханыннан качтым,
Качтым да урыс ханына
кару яу ачтым,
– дигән. Бу Анисим батыр булган икән.
Итәге әйткән:
– Алайса, мин дә ханнан качкан,
Син дә ханнан качкан;
Мин дә ханга кару яу ачкан,
Син дә ханга кару яу ачкан,
Бир кулыңны, дустым арыслан! – дип, урыс батырына кул биргән. Кул кысышканнар да, дуслар булып, бергә китә барганнар. Көннәр киткәннәр, йомалар киткәннәр, олы атасы Саттимер торасына барып җиткәннәр...

Итүк бик күп кеше катнаш киңәш җыйган, аларга, Туктамыш ханга кару яу ачу, аннан котылу өчен, сугышырга кирәклекне сөйләгән:

[22] Пыл – хәзинә.

– Уйлы йортым, куйлы йортым,
Кунышыңны алдылар,
Куеңны кайда багасың?..
Кунышың ханга пыл булды,
Куең ханга дан булды;
Кунышың киткәч,
Куең беткәч,
Күзеңнән яшьләр агар шул...
Ауласаң, авың артмайды,
Иксәң, игенең җитмәйде,
Башың дан түләүдән үтмәйде.
Мондай илнең моңы бар?
Куеңдай куркак булма,
Дошманнарга юл куйма;
Кулыңа кылыч ал,
Атыңа ияр сал;
Кунышың алган,
Йортың талаган
Дошманыңнан үчең ал! – дигән.

Итәге үз тирәсенә бик күп халыкларны туплаган. Туктамыш хан Итәгегә каршы кат-кат гаскәрләр җибәрсә дә, алар һаман җиңелеп кайтып киткәннәр. Итәге ягындагы халыклар Туктамышка лан түләүдән баш тартканнар.

Сугышларның берсендә, әлегә кадәр Итәге белән кулга-кул тотышып ханга каршы көрәштә, батыр Анисим үлгән.

Аның Заря атлы бичәсе тол калган. Акыллы хатын булган. Аны Итүк бик яраткан. Көннәрдән беркөн Итүк ул хатынга өйләнгән. Итүк яулары аңа Сара дип ат кушканнар. Менә шул вакыттан соң Итүкне муллалар, аксакаллар кавир[23], дип, дин дошманы, дип сүгеп сөйләгәннәр. Аны үз ыруыннан булган кешеләргә кавир дигәннәр.

Халыклар Итәгене бик ятратканнар. Ханга кару булган бик күп ырулар Итәгенең канаты астына сыенганнар. Ил акыллысы дип йөрткәннәр икән аны:

Акыл яшьтән булганда, –
Итүк баштан,
Итүккә акыл кунды әүвәл баштан;
Арасын өч мирамның[24] араласаң,
Итүкнең акылыннан кемнәр ашкан? – дигәннәр.

Инде Туктамыш ханга киләек. Мардал, ничәмә-ничәмә кат Итүккә кару сугышка барып, мордар булып кайткач, аптыраган. Хан әйткән:

– Әй, Мардал, Мардал!
Туган чагыңда бишегеңне
Көмештән бөктердем,
Тактасын ефәктән үрдердем,
Бауларын алтыннан чимәйләттем,
Булмады гуй, Итүктән күзем
чыгарттың! – дигән.

Мардал әйткән:

Әй, атам, атам!
Сараеңда йогалчы[25] баласын үстердең,
Аны, сөеп, бездән артык күрдең;
Йогалчы баласы аягыңнан капты,
Үткен күзеңнән яшьләр акты,
Үткен күзләрең томаланса да,
Аның гөнаһысы миннән түгел,
Аның гөнаһысы үзеңнән ятты! – дигән.

Хан уйлаган, уйлаган да әйткән: «Итәге кайчан да минем җанымны ала торган булмасын. Аны ничек тә үлтерүне күрсәтә торган кеше табарга кирәк», – дип, вәзире Ташбиктән сораган. Ташбик әйткән: «Моңа җавап бирердәй кеше Янбай булыр. Ул кавирне тел ялчысы кыйлганчы, ил ялчысы кыйл, ханым-солтаным», – дигән. Аннан Янбайны чакыртканнар. Янбай сарайга кергән. «Ни боерасың, ханым-солтаным?» – дигән. Ташбик әйткән: «Итәгене ничек үлтерүне син беләсең, әйт», – дигән. Янбай, Ташбиккә карап, җавап биргән:

– Торнадаен тешле кол,
Төлкедәен күзле кол,
Әләкләгән әләк кол,
Ыруым аннан булса да,
Синең анда эшең юк, – дигән.

Хан ачуланган, торган да кылычын алган. Янбайга әйткән:

[23] Кавир – кяфер.

[24] Мирам – дәүләт, ил.
[25] Йогалчы – ялчы.

– Ят ияңне мактасаң,
Яхшылык итәрмен, Янбай;
Үз ияңне мактасаң,
Башыңны кисәрмен, Янбай! – дигән.
Янбай әйткән:
– Ят иясен мактасам,
Мин калырмын оятка;
Үз иямне мактасам,
Мин ирермен[26] *моратка,* – дигән.
Хан әйткән:
– Әй, Янбай!
Ыруың аклыкта булыр,
Кунышың аклыкта булыр,
Кесәң алтынман тулыр,
Әйтсәң, илең котылыр, – дигән.
Янбай әйткән:
– Син дә белмәс эш икән,
Мин дә белмәс эш икән,
Белсә белер Кыпчак би,
Миннән килмәс эш икән, – дигән.
Хан Кыпчак бигә карап әйткән:
– Әй, Кыпчак би,
Илең аклыкта калды,
Үзең пакьлектә калдың,
Тәхетемә вәзир булдың;
Син беләсең икән гуй,
Ник яшердең, әйтмәдең? – дигән.
Кыпчак би әйткән:
– Ханым-иям, солтаным!
Мин дә белмәс эш икән,
Син дә белмәс эш икән,
Камадаен башы агарган,
Кондыздаен теше саргайган,
Тимердәен азу теше төшкән,
Йөз егерме яшен яшәгән,
Агыйдел буенда туган,
Урал тавында үскән,
Арыслан, каплан аулаган,
Җитмеш җиде ил гизгән,
Утыз бичәне кочкан –
Сафардау дигән телче бар,
Инде белсә, ул белер, – дигән.
Аннан хан боерган:
– Сафардау да телче икән,
Телче телчене сөяр.
Янбай, атыңа сал ияр,
Сафардау сиңа килер, – дигән.
Янбай әйткән:
– Әй, ханым-иям, солтаным,
Бу эшең белән килмәстер;
Ике акбүз ат тоттыр,
Алтынлы арбага җиктер,
Күннән түшәк ясаттыр,
Мамык ястыклар салдыр,
Ике нүгәрең[27] *ултырт,*
Җитмеш җиде ил гизгән,
Тимердәен азу теше төшкән,
Йөз егерме яше җиткән
Килсә килер Сафардау, – дигән.

Хан Янбай әйткәнне эшләткән. Аннан ике нүгәрен Сафардауга җибәргән.

Нүгәрләр Сафардауга барганнар. Бер нүгәр әйткән:

– Тимердәен азу тешең төшкән,
Йөз егерме яшең җиткән
Җитмеш җиде илне гизгән,
Күпне белгән, күпне күргән,
Кадерләүгә ия карт!
Безне сиңа хан җибәрде,
Кадерләүгә ия карт!
Ханым-түрәм Туктамыш
Өенә сине чакырды,
Кунак булсаң, ни булган,
Ханым белмәгән эштән
Хәбәр бирсәң, ни булган? – дигән.

Сафардау, риза булып, чимәйле арбада ханның сараена киткән. Ул килгәннән соң, хан аны үзе каршы чыгып алган. Сараенда сыйлаган, кымыз эчерткән. Аннан соң хан әйткән:

– Әле минең акбүз атым,
«Акбүз, акбүз» дигәндә,
Йөгән учлап барган иргә,
Әйләнеп карар микән лә?
Әле минең өем-сарай
Асыл таштан салынган.
Киләчәк өем нигезе
Талдан булыр микән лә?
Әле минең күзкәем-сылуым,
Янекәшем-хатыным,
Көнче егет килә калса,

[26] Ирү – җиту (ирешү).

[27] Нүгәр – егет.

Аның булыр микән лә? – дигән.
Сафардау әйткән:
– Кара лачының, соры карчыгаң –
Икесе ике ояның кошы икән;
Өеңдәге ике егетең
Икесе дә бер йортның кешесе икән.
Өеңдәге егетеңнең берсе
Йортыңнан лачындаен
качкан икән...
Ул качканы яхшы талдан
тозак ясар,
Акбүз атың һәм малыңны
каулап качар.
Йортыңда калган аның берсе
Күзекәең-сылуыңны,
Янекәең[28]-хатыныңны
Тиген улча[29] кыйлыр, алып китәр.
Лачындаен качканы
Камчы төяр башыңа,
Кан саргылыр куеныңа;
Ахырында ул егетең
Кылыч белән башың чабар,
Бүректәен башыңны
Үз йортыңда туга[30] асар.
Әй, Туктамыш, Туктамыш!
Сак булмадың, Туктамыш! – дигән.
Хан курка калган да әйткән:
– Сарай колымнан,
Кавир ыруыннан кулымда Янбай
калды,
Тотыгыз аны!..
Йөрәгемә курку салды,
Суеңыз аны! – дигән.

Ләкин бу вакытта инде Янбай барлык колларны һәм әсирләрне ханның яуларына каршы сугышка әзерләгән булган. Шул ук вакытта Итәге дә үзенең яулары белән килеп өлгергән.

[28] Янекәй – җанаш.
[29] Улча – табыш.
[30] Ту – байрак, җинү тантанасы билгесе.

Дәррәү сарайга Итәге килеп кергән. Ханга әйткән:
– Ыруымның канын койдың,
Малын талап, яшен түктең,
Малга туймас мордар булдың,
Туймасаң туй инде! – дип, кулындагы камчысыман Туктамыш ханның башына төйгән[31]. Башыннан куенына кан аккан. Аннан соң кылыч белән ханның башын кискән. Торасының мәйданына чыгарып, ханның башын тауга эләргә боерык биргән.

Шуннан соң Итәге бөтен колларны һәм әсирләрне азат итеп, үз илләренә җибәргән. Халык Итәгене хан итеп сайларга теләсә дә, ул хан булудан баш тарткан: «Мин хан булмыйм, булсам, тугрылык өчен тырышучы башчы булам», – дигән. Итәгене, барлык халык катнашы белән, башчы итеп сайлаганнар. Азмы-күпме вакыт үткәч, Мардал, башка бер илдән килгән илче булып, Итәге янына кергән дә, аны агулы чәнечке белән чәнечкән.

Итәге үләр вакытында халыкка васыять әйткән:
– Җенесе хатын булса да,
Акылы миннән ким түгел;
Чәче озын булса да,
Йөрәге ирдән ким түгел,
Ыруы кавир булса да,
Күңеле олы дәрьядай;
Хан булмасын илемдә,
Сара булсын башчысы, – дигән.

Итәгене зар иңрәп күмгәннәр. Аннан соң аның хатыны Сараны башчы итеп сайлап куйганнар.

[31] Төйгән – кыйнаган.

*Текстны басмага филология фәннәре докторы **Лилия Мөхәммәтҗанова** әзерләде.* ■

Хан Урдасы (Хан Ставкасы) татарлары

Гүлмару Мырзагалиева*

Хан Урдасы – Казакъстан Республикасының Көнбатыш Казакъстан өлкәсендәге Бүкәй районындагы авыл. 1826 елда Бүкәй Урдасы (Эчке Урда, Эчке җүз) ханы Җиһангирнең (Җәңгирнең) ставкасы буларак оеша. Революциягә кадәр – Хан Ставкасы, 1922 елдан – Урда, 2006 елдан хәзерге исеме белән атала.

Татарлар – Казакъстан үсешенә берничә гасыр дәвамында үзләреннән саллы өлеш керткән халык. Идел Буе Болгар дәүләте чорыннан ук Җаек елгасы буйлары, хәзерге Казакъстан җирләре белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнашкан. Шунлыктан кыргыз-казакъ далаларына әлеге мәмләкәттән килүче кешеләрнең сәүдәгәр булуы табигый күренеш. Бүгенге Казакъстан җирләренә күченгән икенче төркем татарлар хак исламга дәгъват кылучылар, ягъни укымышлы муллалар булган. Гомумән, 1552 елда Казан ханлыгы яулап алынган көннәрдән алып, төрле эзәрлекләүләрдән, көчләп чукындырудан, Россия империясенең төрле йөкләмә-салымнарыннан, авыр солдат хезмәтеннән һәм сугышлардан, хәрби конфликтлардан котылу өчен киң казакъ сахрасына качып, сыену урыны тапкан татарлар күп булган. Шулай итеп, бирегә төрле сәбәп белән

Хан Урдасы авылы күренеше. 1910 ел

* **Гүлмару Мырзагалиева** – Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең Хан Урдасы тарих-мәдәният, архитектура-этнография музей-тыюлыгының фәнни хезмәткәре.

күчеп килгән татарлар җирле төрки халыклар, аеруча кыргыз-казакълар белән уртак тел таба, дустанә мөнәсәбәт урнаштыра. XVIII гасырда килүчеләрнең саны бермә-бер арта. Нигездә, татарлар сәүдә эшенә бәйле төрле идарә, приказчик һәм башка административ хезмәтләрне башкарган. XVIII гасырның икенче яртысында патша хөкүмәте, казакъ ханнары һәм солтаннарына ярдәм итү, аларга төрле эш кәгазьләрен алып барырга булышу өчен, укымышлы татар муллаларын җибәрә. Шул килүдән алар бу җирләрдә бөтенләйгә төпләнеп кала. Татарлар казакъ даласында ислам динен тараталар һәм Россия империясенең нигезен ныгытуга хезмәт итәләр. 1785 елда патшабикә Екатерина II барон Игельстромга: *«Кыргыз* (хәзерге казакъ. – ***Ред.***) *ыруларын муллалар белән тәэмин итеп, сез безнең эшкә шактый зур файда китерә аласыз. Сез хезмәткә аеруча казан татарларының иң ышанычлыларын алырга тырышыгыз. Аларга, кыргызларны безгә тугрылыклы итеп тотсыннар һәм дәүләт чиген төрле һөҗүм-талаулардан саклау эшләре алып барсыннар өчен, үгет бирегез»,* – дип, хат-ярлык җибәрә. Шулай итеп, белемле татар муллалары казакъ ханнарының төп таянычына әйләнә.

1787 елда солтан җитәкчелегендәге казакъ старшиналарыннан торган депутация һәм ыру аксөякләре, Санкт-Петербургка барып, патшабикә хозурында булалар. Бу сәфәрдә алар казакъ даласына укымышлы муллаларны, ягъни татарларны җибәрүне үтенәләр.

XIX гасыр башында Бүкәй ханлыгында илне Бүкәй хан, аннары Шыгай солтан җитәкләгән чорда нибары 15 мулла булса, Җиһангир хан илбашы булып торган 1823-1845 елларда аларның саны инде 120дән артып китә. Хан Ставкасындагы мәчеттә ахун, мулла һәм мәзин вазыйфаларын татарлар башкарса, калган барлык мәчетләрне дә казакъ муллалары тоткан. Тарихи мәгълүматларга караганда, бу чорда Хан Урдасында ике мәчет эшләгән. Беренче мәчетне Җиһангир хан салдырган. 1890 елда (1888) ул яңадан төзелә. Икенчесе «Татар мәчете» дип аталган. Ул 1898 елда Урдада яшәүче татарлар акчасына салына, кызгыныч, 1934 елда сүтелә. Әлеге ике гыйбадәтханә дә «Мәчет урамы»нда урнашкан. Хан Урдасының татарлар күбрәк яшәгән өлеше «Татар урамы» дип аталган. Бу урам хәзер күренекле казакъ акыны Т.Жароков исемен йөртә. Бүкәй Урдасында ислам дине таралу турында А.Евреинов «Внутренняя или Букеевская, Киргиз-казачья Орда» исемле китабында: *«Киргизы Букеевской орды, исповедуя магометанство учения Сунни, имели до Джангира не более 15 мулл, весьма ограниченных в религиозных познаниях. Джангир обратил на это строгое внимание и пригласил в Орду несколько мулл из татар, известных ученостью и правилами. Одного из них правительство утвердило ахуном, который, доселе главное духовное лицо в Орде. Им поручил Джангир обучать киргизов вероучению, и тех из приготовленных, которые по экзамену ахуна оказывались достойными, делал муллами, в знак чего давал открытые приказы»,* – дип язган. Мәгълүм ки, хан боерыгы буенча тәгаенләнгән муллалар «указлы муллалар» дип аталган. Алар яңа туган казакъ һәм татар сабыйларына хәерле исемнәр кушу, яшүсмерләргә гыйлем бирү, никах уку, җеназа намазын укып мәрхүмнәрне соңгы юлга озату, метрика кенәгәләрен тутыру, мәчетләр салдыру һәм башка эшләр белән шөгыльләнгән.

Бу чорда татарларның белем дәрәҗәсе башка төрки халыкларныкыннан күпкә югарырак була. Гомумән, татарларда элек-электән белемгә омтылыш кешенең иң яхшы сыйфатларыннан берсе санала. Алар мәктәп-мәдрәсәләрне хөкүматтән алынган финанс ярдәменә түгел, ә үз акчаларына төзеп, андагы уку-укыту процессын, мөгаллимнәргә хезмәт хакын түләү һәм дәреслек алдыру кебек чыгымнарны каплауны тулысынча үзләре кайгырткан. Татарларның укымышлылыгы турында

XIX гасыр рус этнографы Я.Д.Коблов: *«Среди народов, населявших восточную часть России, татары-магометане занимали первое место. Процент грамотности среди них очень высок даже по сравнению с русскими... В России трудно указать народ, у которого была бы так широко распространена грамотность как у казанских татар. Безграмотного татарина можно встретить редко»,* – дип язган.

Татарлар, казакълар арасында ислам динен тарату белән бергә, биредәге халыкны укырга-язарга да өйрәткән. Һәр мал-мөлкәткә ия булган казакъ бае татар мулласының матди ихтыяҗын кайгыртып, авылдагы ир һәм кыз балаларны аңа биреп укыткан, тәрбияләткән. Җирле казакълар татарларга, беренче чиратта, муллаларга йорт салу, мал карау, бакча эшләрендә ярдәм иткән. Татар сәүдәгәрләре Урдага күпләп чәй дә алып килгәннәр. Бу уңайдан галим-этнограф, Рус география җәмгыятенең әгъзасы Мөхәммәд Салык Бабажановның 1861 елда «Северная пчела» журналында басылып чыккан мәкаләсе кызыклы. *«При Жангире в Орде в значительном количестве появилось татар, которые занимались или обучением детей татарской грамоте, или торговлей. Впрочем, и то и другое киргизам оказало пользу: в первом случае распространилась грамотность, в последнем – киргизы, хотя в незначительном числе, занимались торговыми оборотами.*

...Еще одно влияние распространили татары – это значительное употребление чая. Теперь почти половина Орды пила чай. По примеру татар и русских, в окрестностях ставки начинает распространяться курение табака и употребление горячительных напитков», – дип язып калдырган ул.

Урдадагы Җиһангир хан мәчетендә хезмәт итүче имамнар исемлегендә ахун Җәбир Хамадов (1875 елда 93 яшендә вафат булган бу хәзрәтнең төрбәсе хан зиратында), Казан губернасыннан мәзин Гобәйдулла Бәширов, шуннан ук килгән мулла Таҗетдин Гаделҗановларның исемнәре күрсәтелгән. XX гасыр башында биредә ахун булып Гали Гайсин, аның ярдәмчесе Сәлахетдин Шәрәфетдинов, мәзин Мөхәммәдйосыф Таҗетдинов, мәзин ярдәмчесе Мөхәммәдвафа Мифтахетдиновлар эшләгән. Хан канцеляриясендә татар телендәге эш кәгазьләре белән Казан губернасының Ашыт авылыннан килгән Габдесаттар Исхаков (аның кабере сакланган: 1885 елда 49 яшендә вафат була), Оренбург губернасының Эстәрлетамак авылыннан күченгән Ширъяздан Мансуровлар шөгыльләнгән.

Җиһангир хан тәкъдиме белән, Хан Ставкасында 1832 елдан даими рәвештә ярминкә оештырылганлыгы билгеле. Бирегә сәүдәгәрләр Россиянең төрле шәһәрләреннән, Бохара һәм Хивадан килеп сәүдә иткәннәр. Ярминкә булмаган вакытларда алар төрле көнкүреш хезмәтләре күрсәтә башлаганнар, кечкенә генә сәнәгать оешмалары, хәтта сабын кайнату заводына кадәр ачканнар. Нәтиҗәдә, 1840 нчы елларның уртасында Хан Ставкасы сәүдә үзәгенә әйләнеп киткән.

1846 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, биредәге 89 йортның 31ендә сәүдәгәрләр яшәгән. Шул ук елда аларның 46 сәүдә лавкасы һәм 19 товар саклау склады булганлыгы билгеле. 31 сәүдәгәрнең 12се – татар, 4есе – казакъ, 15е – башка милләт вәкиле. Эчке Россиядән килгән татарлар җирле казакълар белән бергә май эретү, сабын кайнату, шәм ясау, күн иләү белән шөгыльләнгән. Казакъ җәйләүләрендә киң таралган «болгари» сүзе дә бирегә затлы татар читекләре белән үтеп кергән булса кирәк. Бүкәй Урдасына татарлар Казан губернасының Зөя, Тәмтез, Балтай, Ашыт, Камай, Спас һәм башка өяз һәм авылларыннан күчеп килгән.

Татарлар Бүкәй Урдасының үзәгенә урнашканнар. XIX гасыр урталарында биредә 346 татар һәм 13 мишәр (шул ук татар!) яшәсә, 1891 елда аларның саны 600гә җитә. Бүкәй Урдасында берничә мең көмеш тәңкәлек товар әйләнеше булган бай татарлар күп яшәгән. 1846 елның 1 ноябрендәге мәгълүматлар буенча, Хан Ставкасындагы иң бай татар сәүдәгәрләренең исемлеген тәкъдим итәбез.

№	Исеме	сан		Нәрсә белән сәүдә итә?	Көмеш белән суммасы
		лавка	складлары		
1	Йомышлы казан татары Хәбиб Хуҗасәетов	1	1	Ефәк, кәгазь товарлар, дөя сукносы, чәй, шикәр, төрле савыт-саба һәм икмәк	3400
2	Йомышлы казан татары Габделмәннәф Гыймранов	1	-	Кәгазь товарлар, юфть, икмәк һәм тары ярмасы	1800
3	Казанлы лашман татары Шәрәф Вәлитов	1	1	Кәгазь товарлар һәм төрле вак-төяк	300
4	Казан губернасының Чистай шәһәре мещаны Ярмөхәммәд Ишмөхәммәтов	1	-	Кәгазь товарлар һәм төрле вак-төяк	300
5	Ясаклы казан татары Габделвахит Мәмәтев	3	-	Төрле вак-төяк һәм икмәк, лавкаларны арендага биреп торган	150

6	Ясаклы казан татары Әхмәд Мортазин	2	2	Төрле вак-төяк һәм икмәк, лавкаларны арендага биреп торган	100
7	Казан губернасының Арча сәүдәгәре Мөхәммәдҗан Яхин	3	-	Төрле вак-төяк, он һәм икмәк, лавкаларны арендага биреп торган	100
8	Әстерханнан килгән юрт татары Габделхалик Йосыпов	1	1	Вак-төяк, тәм-том һәм он	150
9	Казан сәүдәгәре Исмәгыйль Борнаев	2	-	Вак-төяк һәм он	130
10	Казанлы лашман татары Ибәтулла Габделмәҗитов	1	-	Вак-төяк һәм он	50
11	Әстерханнан килгән йомышлы татар Әхмәдшаһ	2	-	Үзе сәүдә итмәгән, лавкаларны гына арендага биреп торган	

Әфләтүн Уразовның каберенә куелган таш

Моннан кала, Тамбов, Сарытау, Әстерхан, Ростов калаларыннан килгән татар сәүдәгәрләре дә казакъның алаша, байбакты, бериш ырулары белән сәүдә иткән. Татарларның бирегә килү географиясенә һәм алар саткан товарларга күз салсак, «Хан жәрмеңкесінде құстың сүтінен өзгенің бәрі болды» («Хан ярминкәсендә кош сөтеннән кала бар нәрсә дә бар») дигән атаклы гыйбарәнең хаклыгына, һичшиксез, ышанасың.

Әфләтүн Уразов – Урдада берничә кибет тоткан атаклы сәүдәгәр. 1885 елгы өй хуҗаларының исемлегендә эшкуарның Хан Ставкасындагы «Торговая» урамында (хәзер Хан Урдасы авылындагы А.Оразбаева урамы) ике агач һәм өч таш өе, су белән яхшы гына тәэмин итә торган бер коесы булуы теркәлгән. Ул Мәскәү һәм Әстерхан калаларыннан көндәлек

кирәк-яракларны кайтарту белән шөгыльләнгән. Хан Урдасына Әфләтүн исеменә килгән хатларның конвертлары хәзерге көндә Көнбатыш Казакъстан өлкә тарих-мәдәният, архитектура-этнография музей-тыюлыгында саклана. Г.Зарипов үзенең истәлекләрендә: *«Иң бай сәүдәгәрләрдән Әфләтүн Уразов була. Аның ике катлы агач өе бар иде. Бу өй Н.Максимов, П.Епифановларның полк штабы булып торганда, 1919 елны янып харап булды. Алар җүздән җүзгә йөреп печкән үгез һәм дөяләр җыеп, туган җирләренә җибәргәннәр, Идел буендагы калалардан төрле товар, төзелеш материаллары алып килгәннәр»,* – дип әйтә. 1905 елда Хан Урдасы аша Саратов-Әстерхан тимер юлы узарга тиеш була. Татар бае, инженерларга шактый зур күләмдә бүләк (хокукый күзлектән карагандa – ришвәт) биреп, тимер юл чуеннарын Сайкынга таба «бөгүгә» ирешә. Бу факт ни дәрәҗәдә дөреслеккә якындыр – без анысын белмибез.

«Татарлар оста ташъязарлар да булганнар. Хан зиратындагы кабер ташларының тексты татар әдәби телендә язылуы моңа дәлил булып тора. Әгәр дә кабер ташындагы язуларны укыйбыз икән, аның авторының гаять укымышлы икәнлегенә, Коръәнне яхшы белгәнлегенә инанабыз.

Ә.Уразовның кабер ташына: *«Казан вилаяте Зөя өязе Танай аулының хаҗи Әфләтүн Габделваһаб углы 87 йәшендә дарелбакая рихләт итте. 1912 нче йыл 30 нчы мартта. Нәүвәраллаһү мәркадәһ»,* – дип язылган.

Әфләтүннең хатыны – Хәсәнетдин мулла кызы Хәдичәбану да хан зиратында җирләнгән. Аның кабер ташына: *«һаза әл-мәрхүм Казан вилаяте Зөя өязе Шырдан аулының Хәдичәбану Хәсәнеддин мулланың кызы мәрхүм Әфләтүн хаҗиның җәмәгате 52 йәшендә 1885 нче йыл 30 нчы сентябрдә дөньядан үтте. Нәүвәраллаһү мәркадәһ»,* – дип язылган.



Татар сәүдәгәре Әфләтүн Уразовка бирелгән визитка

1919 елда Урдада оешкан татар труппасы. Җитәкчесе һәм режиссеры – А.Таҗетдинов

Гомумән алганда, күп кенә бай татар сәүдәгәрләре, биредә гаилә корып, үзләренең сәүдә эшен балаларына калдырып, бакый дөньяга күчкәннәр. Моның дәлиле – хан зиратындагы кабер ташлары. Хан Урдасында яшәгән иң зур сәүдәгәрләрнең берсе (аның товар әйләнеше көмеш тәңкә белән 1800 сум булган) Габделмәннәф Гыймрановның кабер ташына: *«Ошбу кабернең иясе Казан губернасы Ыспас округы Йаңа Чаллы аулының Хан Урдасында сәүдә кылып торгучы Габделмәннәф Гыймран углы вафат булды бирәхмәти илән 49 йәшендә, 1848 нче елда»;* арткы ягына: *«Янә шул көнне вафат булды Бибинәфисә Габделмәннаф кызы бирәхмәти илә 15 йәшендә. Бу ташны куйды балалары Мирза, Мостафа», –* дип язылган.

Г.Гыймрановның улы Мостафаның Хан Урдасындагы «Торговая» урамында бер таш һәм бер агач өе булган.

Хан Ставкасына татарлар Әстерхан губернасыннан да килгән. Габделхалик Йосыпов – Бүкәйдәге медицина үсешенә, халык саулыгын яхшыртуга зур өлеш керткән, илдә таралган чәчәк эпидемиясенә каршы прививка ясаган табиб. Ул, 1826 елда Җиһангир хан чакыруы буенча, Әстерханнан чәчәк авыруына каршы көрәшү өчен, Хан Урдасына килә. Әүвәл Сырлыбай Җанибәков белән хезмәт итә, ә соңрак үзе генә эшли. Ул чирек гасыр дәвамында уңышлы гына эшләп, ун меңнән артык балага прививка ясый һәм бу хезмәте өчен көмеш медаль белән бүләкләнә. Күренекле татар табибы Габделхалик Йосыпов 1858 елда вафат була. Аның каберенә: *«Һаза әлмәрхүм Хаҗитархан шәһәренең табиб, мулла Габделхалик Йосыф углы вафат булды 57 йәш, 1858 нче елда, руми елы», –* дип язылган.

Юрт татары, табиб һәм мулла Габделхалик Йосыповның сәүдә белән дә шөгыльләнеп, вак-төяк, тәм-том һәм он сатуы мәгълүм.

Әстерхан төбәгеннән килгән карагаш (кундырау) татарлары балта осталары буларак танылган, өйләр салу белән шөгыльләнгән. Алар, суык үтмәсен өчен, бүрәнә араларына мүк түшәгәннәр. Моңа Хан Урдасында хәзерге көнгә чаклы сакланып калган өйләр дәлил.

Сарытау губернасының Кузнецк өязеннән килгән Фазлытдин һәм Хәбибулла Акчуриннар да атаклы сәүдәгәрләрдән саналган. Фазлытдин Акчуринның «Торговая» урамында бер агач йорты булган.

Җиһангир хан татарларны бирегә чакырып кына калмаган, алар белән туганлашкан да. Аның хатыны Фатыйма туташ Оренбург Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдҗан Хөсәеновның кызы була. М.Хөсәенов 1785 елда – Оренбург чикара комиссиясе ахуны, ә 1789 елда мөфти итеп тәгаенләнә. Аны берничә мәртәбә казакълар арасына дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен җибәрәләр һәм ул, Кече җүз белән Россия дәүләте арасын якынайтуга керткән өлеше өчен, патша хакимияте тарафыннан бүләкләнә. Мөфти казакълар һәм Кече җүз турында шактый яза. 1824 елда Уфада вафат була. Аның вафатыннан соң, хатыны Кәримә, Җиһангир хан фәрманы нигезендә, кызы янына килеп, бирелә гомер итә. Җиһангир хан төрбәсенең арткы ягындагы соры кабер ташы без әле генә сөйләгәннәргә дәлил булып тора. Ташъязманың алгы ягына: *«Мәрхүмә Кәримә Җамали кызы ислам шәехе Мөхәммәдҗанның хәләле, хан Жиһангирның кайын анасы. Аллаһы Тәгалә, 1835 елда»;* уң ягына: *«Ташны куйдырган Жиһангир хан»;* арткы ягына: *«янә кызы Фатыйма атлы туташ»,* – дип язылган.

Татарлар оста ташъязарлар да булганнар. Хан зиратындагы кабер ташларының тексты татар әдәби телендә язылуы моңа дәлил булып тора. Әгәр дә кабер ташындагы язуларны укыйбыз икән, аның авторының гаять укымышлы икәнлегенә, Коръәнне яхшы белгәнлегенә, нәсех, дивани, сөлес стилендәге гарәби язу төрләрен үзләштергән бик яхшы хаттат булганлыгына инанабыз. Гомумән, татарлар әлеге зиратны карап торган: аның әйләнәсен койма белән уратып алган һәм агачлар утыртканнар.

1933 елда «кызыл» активистлар, хан зиратындагы төрбәне бозып, аны сарай салуда файдаланса, кабер ташларын, ватып, тегермән ташына һәм мунча нигезен салуга тоткан. Хан Урдасы авылында озак еллар яшәгән Бөек Ватан сугышы ветераны Тәүфыйк Хөснетдиновның сүзләренә караганда, 1975 елны Казаннан бирегә Ногман һәм Шәрәфи исемле ике татар килеп, хан зиратының әйләнәсен тәртипкә салып, кабер ташларын сурәткә алып киткән.

Күргәнебезчә, XIX гасырда ук бирегә килгән татар табиблары, мөгаллим, хаттат, төзүче һәм, әлбәттә, сәүдәгәрләре төбәк үсешенә шактый зур өлеш керткән. Үз эшенең остасы булган татарлар, совет чорында Урдада калып, яңа хакимият үсешенә дә саллы өлеш кертеп, төрле өлкәләрдә хезмәт итәләр. Алар арасында Казакъстан ССРның атказанган укытучысы, Урда тарих-революция музеена нигез салучы Әхмәтфәиз Таҗетдинов, беренче типография хезмәткәрләре Габдулла Диңгезбаев, Ибраһим Мүләкәев, бакчачы, карбыз үстерүче, Бөтенсоюз Халык казанышлары күргәзмәләрендә лаеклы урыннар яулаган Хәбиб Шәрәфетдинов, өй салучы бертуган осталар Шамил һәм Мохтар Дуйсалиевлар, элемтә тармагында озак еллар эшләгән Якуб Уразгилдиев, мал табибы Габдулла Шакирҗанов, хат ташучы булып 40 елдан артык хезмәт иткән Галия Котдусова һәм башкалар бар. Хәзерге мөстәкыйль Казакъстан Җөмһүриятендә 250 меңгә якын татар яши. Аларның барысы да суверен республикабыз үсешенә сизелерлек өлеш кертә.

Казакъчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Исемдә калганнар

Габделгазиз Төхфәтуллин

Арча районы Иске Кишет авылының мулласы Салах гаиләсе белән. Арткы рәттә (сулдан) – кызы Сабзебаһар һәм кияве Габделгазиз Төхфәтуллиннар, алар арасында – уллары, булачак язучы Рафаил Төхфәтуллин. 1928 ел

Дәү әтием, ягъни танылган язучы Рафаил Төхфәтуллинның әтисе Габделгазиз хәзерге Татарстан Республикасының Апас районындагы Ябалак авылында мулла Габдрахман гаиләсендә туган. Гаилә традициясенә тугры калып, Габделгазиз дә мулла хезмәтен дәвам итәргә тиеш була. Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан авыл һәм Казан мәдрәсәләрендә укый. Абыйсы Габделхәйнең киңәшен истә тотып, Казан укытучылар мәктәбен тәмамлый.

Туганым, танылган скульптор Асия Миңнуллина белән гаилә архивын барлаганда дәү әтиебез Габделгазизнең ***«Исемдә калганнар. 1917-1957 еллар»*** *дип аталган дәфтәренә юлыктык. Кызганыч, андагы язмалар 1920 нче елларда өзелә.*

Истәлекләрдән күренгәнчә, дәү әтием Габделгазиз хәзерге Арча һәм Әтнә районнарындагы авылларда совет мәктәпләре оештырып йөри. Аны берничә мәртәбә үтерергә дә җыеналар, тиф белән дә авырый. Иске Кишет авылы мулласы Салах хәзрәтнең кызы Сабзебаһар белән гаилә кора. Аларның өч баласы – Роза, Рафаил һәм Чарльз дөньяга килә. Габделгазиз 1955 елга кадәр Яңа Ияваш, Күлле-Киме, Кышкар, Олы Әтнә, Олы Мәңгәр һәм Яңа Кенәр авылларында укытучы булып эшли. 1966 елда туберкулездан вафат була.

Габделгазизнең әтисе Габдрахман мулла һәм Сабзебаһар әбиебезнең әтисе Салах хәзрәт 1930 нчы елларда репрессияләнәләр һәм Беломор каналы төзелешендә һәлак булалар. Ә абыйсы Габделхәйгә Беренче Бөтендөнья сугышыннан әйләнеп кайту насыйп булмый.

Рөстәм Төхфәтуллин

Февраль революциясе

1917 ел. Мин Учительская школаның 3 нче классында укый идем. Школага кергәнче, мәдрәсәдә укыдым. Бу – Беренче Империалистик сугыш вакыты. Сугыш 1914 елда башланган, Россия Германия һәм Австровенгрия белән сугыша иде. Авылда ирләр аз калган иде: хатын-кызлар, бала-чага һәм картлар гына. Ирләр солдатта – сугышта. Бу сугыш бик каты сугыш булды. Күп кеше үлде, гарипләр күбәйде, күп кеше пленга төште; авылда да, шәһәрдә дә хуҗалык җимерелде. Күп завод-фабрикалар эшләми башлады һ.б. Эшләгәннәрендә эшләү шартлары авырайды. Авылда җирләрне чәчеп бетерә алмадылар. Икмәк бәясе күтәрелде. Халык сугыштан бик туйган иде. «Бу патша үз башына котыра торгандыр инде», – дип сөйлиләр иде. Забастовкалар турында күп сөйлиләр иде, ләкин әле газеталарга язмыйлар иде. Февраль килеп җитте. Газеталарда да Петроградтагы забастовкалар турында яза башладылар. Безнең школага еш кына университет студентлары килә башлады. Алар: «Озакламый революция була, патшаны бәреп төшерәләр», – дип, безгә аңлаттылар. (Билгеле, яшерен – уборныйда.)

Озак үтмәде, урамнарда телеграммалар сатып йөри башладылар. Бу телеграммаларда Петроградта патшаның төшерелүе турында язылган иде. Бу Россиядә революция булды дигән сүз иде. Моңар халык бик шатланды.

Казанда урамнарда һәркөн митинглар булып торды. «Патша бетте, хәзер хөррият – свобода!» – дип күп сөйләделәр. Полиция бетте. Трамвайларга билетсез утыралар. «Хәзер хөррият ич!» – диделәр. Мәктәпләрдә дисциплина начарланды, уку вакытында укучылар митингка дип чыгып йөри башладылар. Март аенда мәктәпне яптылар, укучыларны таратып җибәрделәр. Мин авылга кайттым. Авылда да: «Патша төшкән, хөррият!» – дип сөйлиләр иде.

Патша төшкәч нинди хөкүмәт буласын берәү дә белми. «Хәзер хөррият!» – дип кенә әйтәләр. Ләкин озак та үтмәде, Вакытлы хөкүмәт төзелү турында сөйләделәр. Бу хөкүмәт «Учредительное собрание булганга кадәр бер закон да үзгәрми, сугыш Германияне җиңгәнчегә кадәр дәвам итәчәк» дигән приказлар таратты. Бу хөкүмәт буржуаз хөкүмәт иде. Күптөрле газеталар чыга башлады. Болар төрле партияләр тарафыннан чыгарылдылар. Бу газеталарның күбесе Вакытлы хөкүмәтне яклап язды. Ләкин большевиклар тарафыннан чыгарыла торган газеталарда Вакытлы хөкүмәт бетәргә тиеш, яңадан революция булырга тиешлек турында яздылар.

Август аенда мин яңадан Казанга килдем. Гадәттәгечә, сентябрь башында уку башланды. Мин 4 нче класста, ягъни соңгы класста укыдым. Бу вакыт Казанда күптөрле комитетлар төзелгән иде: Мөселман милли комитеты, Мөселман социалистик комитеты, Хәрби шура, Меньшевиклар комитеты, эсерлар, кадетлар һ.б. күптөрле комитетлар. Бу комитет членнарының барысы да дип әйтерлек Вакытлы хөкүмәтне яклый, Учредительное собрание булгач кына законнар үзгәрәчәк, дип сөйлиләр иде. Ләкин Мөселман социалистик комитеты кешеләре генә дөресен әйтәләр иде. Алар, яңадан революция ясамыйча сугыш та бетми, халыкка ирек тә булмый, икмәк тә булмый, дип аңлаттылар. Бу комитет большевиклар программасын аңлата иде. Комитет председателе Мулланур Вахитов иде. Мулланур Вахитов митингларда сөйләгәндә, байлар: «Долой!» – дип кычкыралар иде. Башка кешеләр: «Сөйләсен, ул безгә кирәкне сөйли!» – дип кычкыралар иде.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе

Мәктәптә уку дәвам итте. Октябрь ае килеп җитте. Октябрьнең ахырында без классларда укып ятканда туп тавышлары, снаряд тавышлары ишетелә башлады. Бу көчәйгәннән-көчәя бара: тәрәзәләр чалтырап китә, мәктәп өстенә снаряд төшкән төсле була. Без, моңар кадәр сугышта булмаганлыктан, курка башлыйбыз. Уку туктала. Урамга чыгабыз. Туп һәм пулемет тавышлары һаман кабатланып тора. Урамдагы кешеләрдән сорыйбыз – берәү дә белми. Ә кайберләре ачулана: «Алдыңа кара, синең эшең анда булмасын!» – ди.

Безнең школа Казанда хәзерге Тукай урамында иде. Туп тавышы никадәр көчле булса да, безнең урамга бер снаряд та төшмәде. Ераккарак китеп, Проломный урамына (хәзерге Бауман) барып сораштык. Монда дөресен әйттеләр. Бу рабочийларның юнкерларга каршы сугышы, диделәр. Кайтып, школа түбәсенә менеп карадык. Снарядлар Кремль янына төшәләр иде. Бу Казанда большевиклар партиясе тарафыннан оештырылган сугыш, ягъни Октябрь революциясе ясау өчен сугыш иде. Ул сугыш бер көн, бер төн дәвам итте. Иртәгесен: «Хәзер бөтен власть Советлар кулына күчте!» – дип игълан иттеләр. Һәм шул турыда телеграммалар сатып йөрделәр. Шул көннәрдә Петроградта да революция булган иде. Бу Бөек Октябрь Социалистик революциясе иде. Берничә көннән соң, Советлар Хөкүмәтенең Солых турында һәм Җир турында декреты чыкты.

«Олы Мәңгәр авылы. 1937 елның 19 октябре. *Уңда, күзлекле – Габделгазиз Төхфәтуллин. Аның алдында – әтием Рафаил Төхфәтуллин. Рафаил янында, ак шапкалы – Роза Төхфәтуллина. Роза артында, кара кепкалы – Нәфик Яһудин. Ул – Рафаилнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, язучы. Бу фотога төшкәч, ун көннән аны кулга алалар. Мин узган ел аның улы Марс Яһудинны эзләп таптым. Без Чаллы һәм Әлмәт китапханәләрендә әдәби очрашулар уздырдык, әтиләребез турында сөйләдек. Марс әтисенең 1937 елда язылган «Казакълар» романын, илле елдан соң чормадан табып, «Казан утлары»нда бастыра. Минем әтием Рафаил дә шул ук 1937 елда, төнлә Нәфик абыйның тәрәзәсенә килеп, моның язганын күргән һәм «күңеленә очкын төшкән»: «Мин дә язучы була алам!» – дигән. Болар турында ул «Җиләкле аланнар»да язып калдыра.* ***Бу фотода «Җиләкле аланнар» повестеның дүрт герое бар – Габделгазиз, Нәфик абый, Роза һәм Рафаил...»***

Рөстәм Төхфәтуллин

«Солых» – сугышны туктату турында; «Җир» – алпавыт җирләре түләүсез алына, барлык җир халыкныкы итеп таныла.

Төрле комитетлар бетерелә. Ләкин Казанда әле Мөселман милли комитеты һәм Хәрби Шура берничә ай бетми. Бу комитетлар һаман Казанда байлар властен урнаштырырга тырышалар. Казанда Хәрби Шура оештырган Мөселман полкы була (95 нче полк). Октябрь революциясе булгач, бу полкның солдатлары коралларын, винтовкаларын алып таралалар: авылларга, өйләренә кайтып китәләр. Билгеле, аларның төрлесе була: кайберләре авылда Совет властен ныгыту өчен көрәшә, ә кайберләре авыл кулакларына булышалар, ә кайберләре винтовкаларын яшереп куялар һ.б.

Казанда татарлар арасында Совет власте февраль аенда гына урнаша, ныгый. Хәрби Шура бетерелә.

1918 ел, җәй көне. Гражданнар сугышы

Германия белән сугыш бетте. Тынычлана башлады. Ләкин сугышның нәтиҗәләре әле бетмәгән. Тормыш бик авыр иде. Икмәк бик кыйбат. Туйганчы ашарга туры килми иде. Май аенда мин школаны бетердем. Укытучы правасы алдым. Губерна мәгариф шәгъбәсе оештырган 6 айлык укытучылар курсына кердем һәм Казан өязе мәгариф шәгъбәсенә эшкә кердем. Делопроизводитель булып эшләдем.

Дошманнар Совет властен күралмадылар, Совет властен бетерергә теләделәр, контрреволюция оештырылды – Гражданнар сугышы башланды. Совет иленә чит ил капиталистлары оештырган армияләр басып керде. Аларга эчке дошманнар, ягъни алпавытлар, капиталистлар, патша генераллары, офицерлар, юнкерлар һ.б. булышты.

1918 ел җәй көне, июль аенда, кинәттән генә Казан янында туп тавышлары ишетелә башлады. Каты сугыш булды. 2 көннән соң Казанга аклар армиясе – чехлар керде, Казан урамында сугыш булды. Алар революциядә катнашкан кешеләрне үтереп йөрделәр. Казан байлары, бер дә гаепсез кешеләрне тотып, чехларга үтерттеләр. Казанда байлар власте урнаштырырга тырыштылар. Ләкин Красная гвардия Казаннан еракка китмәде: Красная гвардия Югары Ослан, Красная Горка (хәзер Юдино), Биектау янында гына торып, чехларны Казаннан чыгару өчен сугыш башлады. Яңадан каты сугыш башланды. Өзлексез туп тавышлары ишетелеп торды. Казанда тәртипсезлек башланды: һәркөн чехлар совет кешеләрен үтерәләр, ачлык һ.б. Мобилизация турында приказ чыгардылар. Чехлар кереп 2 көн узгач, мин Казаннан качып киттем, чөнки мине дә үзләре армиясенә алалар иде. Казаннан китү бик читен булды, һәр җирдә чехларның часовойлары тора иде; алар пропуск сорыйлар. Мин, Спас (хәзер Куйбышев) ягыннан икмәк сатарга килгән крестьяннарга утырып һәм, үзем дә авыл кешесе булып киенеп, Казаннан киттем. Часовойлар икмәк сатарга килгән крестьяннарны тотмыйлар иде. Мин дә икмәк сатарга килдем, дидем һ.б. (Ул вакыт авыл кешеләре җәй көне дә кат-кат киенәләр иде: казаки, бишмәт, кәләпүш, бүрек һ.б. Бер катын мин дә кидем – бишмәт, бүрек.)

Юлда күп авырлыклар күрдем. Берничә көннән соң үзебезнең авылга – Тәтеш өязенә (хәзер Апас районындагы Ябалак авылы) кайтып җиттем. Ләкин бу вакыт безнең авылда чехлар власте иде. Озак тормадым, Зөя өязенә (хәзер Кайбыч районы) киттем. Анда чехлар юк, Совет власте иде. Кошман авылында тордым.

1 айдан соң Казаннан чехларны куаладылар. Казанда яңадан Совет власте урнашты. Мин Казанга кайттым. Чехлар Казанны бик талаганнар, күп кешеләрне үтергәннәр иде. Казан байлары, атаклы революционер Мулланур Вахитовны тотып, чехларга биргәннәр һәм аны чехлар җәзалап үтергәннәр иде. Ачлык һәм авырулар…

Мин – укытучы. Гражданнар сугышының дәвамы

1918 елның ноябрь аенда мин Казан өязе (хәзер Арча районы) Иске Кишет авылына I баскыч мәктәпкә (башлангыч мәктәп) укытучы булып килдем. Бу совет мәктәбе иде. Мин килүдән берничә көн генә элек Арча янында сәнәк сугышлары булган иде. Авыл кулаклары: «Без советка икмәк бирмибез!» – дип, авылда фетнә оештыралар һәм, халыкны котыртып, сәнәк, балталар белән коралландырып, Арча янына алып баралар. Бу фетнәчеләрдә беркадәр винтовка да була. Ул Казандагы 95 нче мөселман полкы солдатлары урлап алып кайткан кораллар була. Ләкин бу фетнәчеләр Арчага барып җитә алмыйлар. Арчадагы отряд пулеметтан һәм пушкадан ата башлагач, таралалар. Менә шулар таралганда, Иске Кишет авылына укытучы булып килдем. Мин Арча аркылы килгән идем. Миннән: «Арчада нәрсә?» – дип сорадылар. Мин: «Арчада солдат күп, пушка һәм пулеметлар бик күп», – дидем. «А-а-а... Ярый әле безнең авыл бармады, харап буласы икәнбез», – диделәр. (Яңа Кишетләр барган иде, Иске Кишет бармаган иде). Миңа бик шикләнеп карадылар. «Бу үзе дә большевик түгел микән?» дигән сүзләр ишетелде. Бу, бердән, көлү, икенчедән, курку иде. Ул вакыт авыл кулаклары һәм аларга ияргән башкалар большевиклардан бик куркалар яки куркынычлы кеше итеп карыйлар иде. Мин бу авылда озак тормадым. Моннан тиз китәргә туры килде.

Бу вакыт авылларда әле совет мәктәпләре аз иде. Яңа Кишет волостенда 5 кенә (Яңа Иябашы, Субаш-Аты һәм Югары-Аты авылларында; 2 рус авылында: Хотня, Александровка). Ләкин һәр авылда да дини мәктәп бар иде. Хөкүмәт дини мәктәпләрне бетереп, алар урынына совет мәктәбе оештырырга куша иде.

1919 елның башында миңа, Кышкар авылындагы дини мәктәпләрне бетереп, совет мәктәбе оештыру эше тапшырылды. Моның өчен күп тапкыр җыелышлар җыярга, мөтәвәллиләр сайлатырга һәм күп көрәшергә туры килде. «Кирәкми безгә челтәр мәктәбе», – диделәр. Бу вакыт халык совет мәктәбен «челтәр мәктәбе» дип атый иде. Шулай дип әйтүнең сәбәбе дә бар иде.

Кышкар авылында 2 мәктәп оештырдым: I һәм II баскыч (башлангыч һәм 7 еллык мәктәпләр). Мин II баскычка укытучы һәм заведующий булып билгеләндем.

Мин – укытучы һәм агитатор. Гражданнар сугышының дәвамы

1919 ел башында Гражданнар сугышы тагын да көчәйде. Дошманнар Совет илен һәр яктан чолгап алдылар: Дутов, Краснов, Колчак, Корнилов һәм башка ак гвардия генераллар оештырган армияләр безнең җиребезгә һөҗүм иттеләр. Аларга Америка, Англия, Франция капиталистлары булыштылар: корал, продовольствие һәм солдатлар җибәрделәр.

Дошманны җиңү өчен, Коммунистлар партиясе бөтен эшләрне, бөтен хуҗалыкны сугыш җаена корып җибәрде. «Революция куркыныч астында, барысы да фронт өчен!» – дип язды В.И.Ленин. Бу хәрби коммунизм чоры иде.

Дошманны җиңү өчен, Красная Армияне бигрәк тә икмәк белән тәэмин итү кирәк иде. Икмәкнең күбрәге авыл кулаклары кулында иде. Алар икмәкне бирмәскә, яшерергә тырыштылар. Урта хәлле крестьяннарның да күбесе кулакларны яклыйлар иде. Авылдагы Комитет бедноты членнары да кулаклардан куркалар иде. Волость советы укытучыларга Комитет беднотыга булышырга куша һәм аларга ышаныбрак карый иде. Авылдагы икмәкне хөкүмәткә тапшыру, кулаклардагы икмәкне алу буенча миңа күп эшләргә туры килде. Шуның өчен авыл

Уңда – Сабзебаһар һәм Габделгазиз Төхфәтуллиннар. Күлле-Киме авылында җидееллык мәктәптә укытканда. 1924 елның 10 июле

кулаклары укытучылардан үч алырга һәм кыйнарга йөрделәр. Куркынычлы көннәр күп була иде. «Фәлән авылда фәлән укытучыны кыйнаганнар» дигән хәбәрләр ишетелеп тора иде.

1919 ел яз көне Колчак армиясе Казанга якын килде. Казан губернасының көнчыгыштагы авыллары дошман кулында. Дошман Кукмара, Малмыж янына, Балтач районына килеп җитте. Мин тиф авыруыннан яңа гына терелгән идем. Ашарга җитми иде. Бу вакыт мин укытучы гына түгел, агитатор да идем. Мин халыкка Красная Армиягә, Совет хөкүмәтенә ярдәм итәргә кирәклеге турында, тиздән дошманның җиңеләчәге турында сөйләдем һәм В.И.Ленинның статьяларын аңлаттым. Агитатор булып башка авылларга да бардым. Шул вакытта Кышкар авылындагы кулакларның мине кыйнарга хәзерләнгәннәре беленде. Ярлылар әйтте. Шул төнне мин волостька – Яңа Иябашына киттем һәм хәлне аңлаттым. Кышкардагы башка укытучылар катнашмады: күп укытучылар качып киттеләр. Иртәгесен Волисполком членнары һәм предЦИК Шакир абзый Мортазин белән бергә Кышкарга кайттык. Җыелыш җыйдык, халыкка Колчак турында, ягъни аның халыкка дошман икәнлеге турында аңлаттык. Җыелышта мин сөйләдем. Халык бик шаулады. «Бетте инде сезнең көнегез!» – дип кычкыручылар да булды. Кулаклар Колчакны көтәләр һәм Совет властен бетерергә телиләр иде. Шулвакыт берничә кеше, җикеренеп, минем янга килә башлады. Шулардан берсе: «Ник дин укытмыйсыз? Ник мондый китап укытасыз?!.» – дип, минем алга ике китап ыргытты. Бу «Татар сарыфы» һәм «Татар нәхүе» дигән китаплар иде. («Татар морфологиясе» һәм «Татар синтаксисы».) Ул вакыт китаплар гарәп хәрефе белән языла иде. «Нигә арба, чана укытасыз? Бу китап – мөселманны мыскыл иткән китап! Бу – бисмилласыз китап! Ни өчен бу китапның тышына «Татар сарыфы», «Татар нәхүе» дип язганнар? Бу мыскыл итү түгелмени?! Инде күп түздек, бетсен челтәр мәктәбе!» – дип кычкырдылар. Мине кыйнарга теләгәннәр иде, ләкин Волисполком членнары һәм ярлылар коткарып калды.

Бу май башларында (апрель ахры) иде. Ул елны шуннан соң укытып булмады. Мәктәп ябылып торды. Шуннан соң мин Арчага киттем. Арчада Ревкомитет төзелгән иде. Аннан мине ике кеше белән Малмыж фронтына агитатор итеп җибәрделәр. Авылларда йөрдем. Берничә тапкыр кыйнарга әзерләнделәр. Ләкин Колчак җиңелә башлаган иде һәм тиздән җиңелде дә. Гражданнар сугышы 1920 елда гына бетте. Тынычлык башланды. Сугыш калдырган җимереклек әле озакка барды. 1930 нчы елларга кадәр эчке дошманнар бетеп җитмәде.

*Текстны журналга **Рөстәм Төхфәтуллин** әзерләде.* ■

Фамилияләребез

Гүзәлия Хаҗиева, филология фәннәре докторы


РЕВИЗСКАЯ СКАЗКА

Мужескій полъ.

Итого мужескаго пола на лицо

РЕВИЗСКАЯ СКАЗКА

Женскій полъ.

Итого женскаго пола на лицо

Фамилия латин телендә («familia») гаилә, өй дигәнне аңлата. Ул – кешенең аерым бер гаиләгә караганлыгын белдерә торган атама. Фамилия сүзе рус теленә поляк теле аша кергә. Ул нәсел сүзенә синоним буларак кулланыла, әмма XIX гасырда мәгънәсен үзгәртә һәм «гаилә» төшенчәсен белдерә башлый. Мәгълүм булганча, фамилия термины Төньяк Италиядә XI гасырда кулланылышка керә һәм Италиядән французлар, инглизләр һәм башка Европа халкы арасында киң тарала. Европа халкын «фамилияләштерү» XII-XIX гасырга кадәр дәвам итә. Алманнар арасында «фамилияләшү» күренеше XII гасырда башланып XIX гасырга кадәр дәвам итә. Руслар фамилияне белдерү өчен кушамат, прозвание сүзләрен кулланалар. XVI гасыр урталарында рус фамилияләренең күпчелеге -ов/-ев/-ин кушымчасы ялганып ясала. Русларда фамилия ясауда «крестильный» һәм көнкүреш исемнәре катнаша. Рус антропонимик системасында кенәз һәм бояр фамилияләре – XV-XVII гасырларда, сәүдәгәр фамилияләре – XVI-XIX гасырларда, крестьян фамилияләре XVIII-XIX гасырларда формалашып бетә.

1818 елда Россия империясе Дәүләт Советы фамилия сүзен гаилә, нәсел мәгънәсендә аңларга кирәклекне, әлеге сүзнең «кушамат»ка тәңгәл түгеллеген күрсәтә. Беренче тапкыр фамилия сүзе «Ревизская сказка» кенәгәләрендә 1849 елда теркәлеп, «гаилә кушаматы» терминын алыштырып килә башлый. XX гасырның 30 нчы елларында – паспортлашу чорында СССРда яшәүче барлык халык фамилияне киң кулланышка кертә.

Татар фамилияләре формалашуның беренче этабы борынгы төрки чорда ук башланып китә. Орхон-Енисей чыганакларында ук фамилиянең тәүге яралгылары күренә башлый, ул социаль титулны, нәселне аерып күрсәтү, мирас мәсьәләләрен хәл итү максатында барлыкка килә: Čur Tegin, Beg Čur, Kül Čur Ayluç Tarkan, Altun Tamgan Tarkan, Kegilinç Tarkan һ.б. Өстәмә антропонимик берәмлек буларак, фамилия, ата яки баба исеме, сословие титулы буларак, исем янәшәсендә кулланыла. Мәсәлән, Tutuq – «баш әмер бирүчесе» титулы мондый исемнәрдә фамилия вазыйфасын үти: Adak Tutuq, Alp Tutuq, Budak Tutuq һ.б. Аерым бер гаилә әгъзаларының исемнәре янында, нәселне аеру максатында, бәк, бай, ай, иш, җан кебек сүзләр кулланыла. Димәк, борынгы төрки антропонимик системада фамилия (ата яки баба исеме, кушамат яки сословие титулы) шәхесне идентификацияләү вазыйфасын башкара. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында elči čor kuč bars, atım el toɣan tutuq, bag tarqan ögä tirig һ.б. кебек сүзләрнең фамилияләр ролендә килүе мәгълүм.

Ислам дине кабул ителгәч, Бөек Болгар дәүләтенең башка илләр белән икътисадисәяси, дипломатик элемтәләренең ныгуы, гарәп факиһләре һәм мөгаллимнәре тарафыннан мәктәп-мәдрәсәләрдә ислам диненең укытыла башлавы кешене идентификацияләүдә өстәмә чараларның кирәклеге ихтыяҗын арттыра һәм фамилия гарәп теле закончалыклары нигезендә формалаша. Бөек Болгар дәүләтендә күренекле галимнәрнең, дин әһелләренең исемнәрендә мондый модельләрнең кулланылышын билгеләргә мөмкин: Хуҗа Әхмәд әл-Болгари, Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Якуб бине Ногман әл-Болгари, Сөләйман бине Даут әл-Саксани-Сувари, Борһанетдин Ибраһим әл-Хәнәфи, Ибраһим әл-Казани, Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи. Алтын Урда чорында фамилия функциясен башкара торган берәмлек рәсми атама булмый, чөнки өстәмә атаманың атадан балаларга күчүе киң таралмаган була. Фамилия функциясен үти торган улы/кызы кебек өстәмә антропонимик берәмлекләр Алтын Урда чорына караган каберташ язмаларында, тарихи чыганакларда фамилия вазыйфасын үти: Хәмәд углы Хәсән углы Мәчкә; Әхрәҗ углы Әбхәм углы Әршид углы Мәхмүд; Ильяс углы Исмәгыйль углы Мөхәммәд; Бәчек углы Мәмәк Йувари углы Исхак углы Йосыф хаҗи; Исмәгыйль углы Хәсән углы Муса углы Мөхәммәд; Иләм углы Хаҗи кызы Җәкәр һ.б. Алтын Урда чорына караган хатын-кыз исемнәрен билгеләүдә дә шул ук модель кулланылышта була: Әхмәд хаҗи углы Хәсән Хаҗи кызы Рабига, Иләм углы Хаҗи кызы Җәкәр, Әхмәд Хуҗа углы Хәсән Хуҗа кызы Рәйзу һ.б. Хатын-кызны идентификацияләүдә өстәмә атама булып ирнең исеме кулланыла: Госман әл-Болгари кызы Хөсәен хатыны Җәкәр Әлти, Мур бәй хатыны Йосыф Йувари углы Йосыф Йувари кызы Гафифә Заһидә һ.б. Алтын Урда чыганакларына караган каберташ язмаларында урынга нисбәтле фамилияләрне дә очратырга мөмкин: Садреддин әл-Ширвани, Хуҗа углы Госман углы Ибраһим әл-Сувари, Юныс әл-Болгари һ.б.

Алтын Урда чорында исламның төрле юнәлешләре киң таралган була. Шунысы үзенчәлекле, әлеге юнәлешләр фамилия вазыйфасын үти торган берәмлекләрдә дә чагыла: Борһанетдин Ибраһим Хозыр әл-Хәнәфи. Дини юнәлешләрнең чагылышы Хәнәфи, Шафи, Суфи кебек фамилияләрдә сакланып кала.

Билгеле булганча, ислам дине кабул ителгәннән соң, антропонимик системада да гарәп исем системасына хас сүз модельләре кулланылышка кереп, урта гасырда һәм аннан соңгы чорларда кеше турында өстәмә мәгълүмат бирә торган төшенчәләргә (шәхеснең туган урыны, мәзһәбе, ата-бабасы) -и/-ый изафә кушымчасы нигезендә барлыкка килгән фамилияләр дә кулланылышта йөриләр: Шиһабеддин Мәрҗани, Борһанетдин Ибраһим Хозыр Хәнәфи, Бәчек углы Мәмәк Йувари һ.б. Моннан тыш, урта гасырларда исем белән янәшә ата-баба исеме, бернинди кушымча алмыйча, патронимик фамилия функциясендә дә очрый: Кадыйр Гали-бәк, Таҗетдин Ялчыгол. Казан ханлыгы чорына караган каберташ язмаларында фамилия углы/кызы кебек өстәмә чаралар ярдәмендә белдерелә: Садир углы Идегәй, Исхак углы Мансур, Чура углы Гали Мәрдән, Кунак Хуҗабай углы Җийан Хуҗа һ.б. Атасы исеменнән тыш, хатын-кыз исеменә иренең исеме өстәлә һәм ул да фамилия булып килә: Җәгъфәр кызы Гали хатыны Айбикәч, Әҗем углы Бик-Бау хатыны Акбикәч, Шәех Галинең хатыны Нәүрүзсолтан һ.б.

Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, шәхесне билгеләүдә аерым үзгәрешләр күзәтелә. X-XVI гасыр урталарыннан башлап татар фамилияләре рус фамилияләре нигезендә формалаша башлый. Әлеге чыганакларда кеше исемнәренә -ов/-ев/-ин кушымчалары кушылып фамилия ясалышы күзәтелә. 1565-1568 нче елларда Н.В.Борисов һәм Д.А.Кикин тарафыннан язылган писцовый һәм межлау кенәгәләрендә татар фамилияләренең төрле катлау арасында кулланылышын күзәтергә мөмкин: Көнәй Чакмак (Куней Чикмаков), Уразкилде Акъялов (Разгилдей Акьелов), Мостафа Байчирү (Мустапа Байчиреев) һ.б. 1602-1603 елгы писцовый кенәгәләрдә йомышлы татарлар арасында мондый фамилияләр билгеләнә: Кайбула Карамышев, Айтуган Янчурин, Карай Урусов, Текей Енчурин, Исекей Мусин, Ангильдиш Мусин, Салтанай Салтангулов, Курмыш Абдулов һ.б. 16-17 йөзләрдә хатын-кыз фамилиясе иренең исеме белән күрсәтелә: Кадышевская жена Девленей.

Рус фамилияләре моделе нигезендә формалашкан татар фамилияләре XVI-XVIII йөзләргә караган рус чыганакларында очрый һәм төрле иҗтимагый катлауга караган татарларны идентификацияләү вазыйфасын үти. Кенәз яки алпавыт катлавына караган татарларның шәхесен билгеләгәндә, фамилия белән беррәттән, ярымотчество да кулланыла башлый: Тойгелде князь Уразгелдеев сын, Кучюк Тегишев, Ишей Хозяшев сын Сюндюков, Емамаметка Юнгушев сын Турачиков. Россиянең тарихи процессында яшәргә мәҗбүр ителгән Идел буендагы барлык рус булмаган халыкларның исем системаларында үзгәрешләр билгеләнсә дә, гарәп-фарсы, төрки телләргә хас исем кушу, атау традицияләре, исем модельләре көнкүреш дөньясында яшәешен дәвам итәләр. Моңа ачык дәлил: XVII–XVIII гасырларга караган ташбилгеләрдә традицион милли калыпка нигезләнгән исем модельләрендә күзәтелә: Кадрәк мирза углы Исәнәк мирза, Айыш углы Дусай, Ишман углы Килмөхәммәд, Чирүче углы Килмөхәммәд. 1763 елгы Ревизия кенәгәләрендә мәгълүматлар фамилия + исем моделендә бирелә: «Салиха Хасанова 35 лет взята Казанского уезда деревни Тонсар Татаринов дочь; Муслима Мусалимова 20 лет взята Казанского уезда из деревни Нового Кызыл Яр Татаринов дочь; Ишмамета жена вдова Гуля Нормаметова 19 лет взята из Казанской губернии» [Ревизская сказка, ф.3, оп.2, ед. хр.438]. XVIII гасырга караган эш кәгазьләрендә татар фамилияләре байтак очрый: Сәгыйть Хәлфин, Әхмәт Сөләйманов, Япей Ибраев, Яхъя Арсланов һ.б. 18 йөз ахырында, сәүдә элемтәләрен ныгыту максатында, йомышлы татарларга паспортлар бирелә һәм анда фамилия рәсми атау берәмлеге булып йөри башлый. Казан

Ратушасының 22 нче фондында татарларга бирелгән паспортлар хакында приходной кенәгәләр, шулай ук паспорттагы мәгълүматларны үз эченә туплаган төргәкләр саклана. Шул рәвешле, рәсми документларда фамилияләрнең кулланылышы рус теленә хас, ягъни ата яки баба исеменә -ов (-ова), -ев (-ева), -ин (-ина) кушымчаларын кушу нигезендә барлыкка килеп, XIX гасырның икенче яртысы-XX гасыр башында тәмам формалаша һәм әлеге күренеш татар милли әдәби теленең формалашу чорына туры килә.

«Татарның ярлы катламы гражданлык хокуклары, кануннар, милек белән эш итмәгән, җәмгыять тормышында актив катнашмаган, шуңа күрә алар озак еллар дәвамында фамилия йөртү хокукыннан мәхрүм булганнар.

XIX гасырның «Ревизская сказка» кенәгәләрендә фамилия рус теленә хас антропонимик моделендә үсешен дәвам итә: Рәхмәтулла Ишметов, Рәхмәтулла Ишекеев, Мөхәммәт Исхаков, Рәхмәтулла Мөхәммәтов, Ибәтулла Мөхәммәтрәхимов һ.б. [Ревизская сказка, ф.3, оп.2, ед.хр.138]. XIX гасыр башларында, фамилия белән беррәттән, отчествоның да тәгаенләнүен күрәбез: «Сабухаккулы Бурханова сын Сагитдин, Сабуханкул Бурханов Тумашев, Мурадым Исхаков Уразгелдеев, Абубекир Халитов Уразгелдеев» һ.б.

XX гасыр башында метрика кенәгәләрендә кеше турында мәгълүматлар традицион милли исем калыбы нигезендә бирелә: Әхмәтвафа Сәйфи углы Миңлехәят, Миңлеәхмәт атасы Нигъмәт Вәли углы. 1916 елгы «Оренбург Диния нәзарәте белешмәләре»ндә фамилияләрнең татарлар арасында киң таралмаганлыгы, ләкин рекрутлыкны билгеләүдә кирәклеге турында әйтелә. Нәсел фамилиясе булмаган очракта, рәсми документларда баба исеме кулланыла. Затлы нәселләрдә яки йомышлы катлауда фамилия мирас буларак күчкән һәм метрика кенәгәләрендә дә теркәлгән. Татар фамилияләренең формалашуы төрле катлау вәкилләре арасында төрлечә бара. Татарларда рус антропонимик системасына хас фамилияләр XV-XVI гасырларда югары катлау династияләрендә генә, төрле дәүләт эшләре белән идарә итүчеләрдә барлыкка килә. Фамилия билгеле бер гаиләне берләштергәнгә, нәселдәнлек, аерымлыкны белдергәнгә күрә, ханнар, морзалар арасында киң тарала. Татарның ярлы катламы гражданлык хокуклары, кануннар, милек белән эш итмәгән, җәмгыять тормышында актив катнашмаган, шуңа күрә алар озак еллар дәвамында фамилия йөртү хокукыннан мәхрүм булганнар. Түбән катлау вәкилләренең күпчелек өлеше ерак авылларда яшәгәнгә күрә, аларга фамилия алу мөмкинлеге Октябрь революциясеннән соң гына бирелгән.

Шулай итеп, татар фамилияләренең формалашуы катлаулы юл үткән. Тарихи чыганакларга таянып, шартлы рәвештә татар фамилияләре үсеш-үзгәрешенең мондый этапларын аерып карарга мөмкин: борынгы төрки чор (V-X гасырлар); урта гасырлар чоры (X-XV гасырлар); татар ханнарында, әмир һәм морзаларында формалашу чоры (XIV-XVI гасырлар); йомышлы татарларда һәм татар сәүдәгәрләре арасында таралу чоры (XVII-XVIII гасырлар); урта хәлле шәһәр кешеләре катламында, мөселман руханилары һәм урта хәлле крестьяннар арасында таралу чоры (XVIII-XIX гасырлар); ярлы катлам шәһәр кешеләре һәм крестьяннар арасында фамилияләрнең формалашу чоры (XX гасыр башы). ■

Татар матбугаты тарихы

«Сугыш сафы» газетасы

ТТ 166

صوغش صفى

Сугш-Сафи „фронтъ“

Извѣстія Исполнительнаго комитета воиновъ мусульманъ 5 арміи

«Сугыш сафы» Беренче Бөтендөнья сугышының Төньяк фронтында – Псков шәһәрендә 1917 елның 5 ноябреннән чыга башлаган. Газета 5 нче армия мөселман солдатларының башкарма комитеты басма органы буларак оеша. Шигаре: «Яшәсен милли вә мәдәни мохтәрият! Яшәсен федерация! Яшәсен милли полклар!» «Сугыш сафы» газетасы, хәрби сафтагы укымышлы татар наборщиклары тарафыннан җыелып, «Труд и знамя» матбагасында басылган. Җаваплы мөхәррире – подпоручик **Әхмәдҗан Алмаев**. Дөрес, сугыш шартларында бу вазыйфаны башкаручы еш алмашынып торган. Әмма редколлегия һәм башкарма комитет әгъзалары даими диярлек. Алар – **Мөхәммәдһади Килдебәков**[1] (1881-1949), **Һади Зөфәров, Галимҗан Әюпов, Мәхмүт Алиев, Минһаҗ Конов**[2] (1893-1934).

Газета турында матбугат белгече И.Рәмиев менәниләр яза: «Революция вакытында гаскәриләр тарафыннан чыгарылган гәзитәләрдән фикер ягыннан иң алдынгысы һәм сулырагы шушы гәзит булды. Атнасына бер тапкыр, ак кәгазьдә чыга. Моның турында иң соңгы номерында язучы Г.Ибраһимов болай ди: «Татар дөньясыннан, татарның матбугат мәркәзеннән еракта торган бу шәһәрдә бернечә татар егете акча юклыгына, хәреф китерүнең кыенлыгына карамаганнар: тотканнар да матбага корганнар, зур фидакарьлек белән «Сугыш сафы» гәзитәсен бу көнгә кадәрле дәвам иттергәннәр. Сугыш сафында, татардан, татар матбугатыннан ерак йирдә түгел,

[1] **Мөхәммәдһади Килдебәков** (1881-1949) – журналист, педагог һәм язучы. «Сугыш сафы», «Чулпан» газеталары мөхәррире. 1921-1926 елларда БАССРның Мәгариф, Игенчелек, Юстиция Халык Комиссариатларында хезмәт итә. Свердловск татар педтехникумы директоры. Фәлсәфи-дини темаларга язылган китаплар авторы («Фәлсәфә ноктаи нәзарыннан дин», «Егерменче гасырда безнекеләр», «Ислам һәм музыка» (1911), «Ислам һәм хатын-кызлар» (1928) һ.б.)

[2] **Минһаҗ Конов** (1893-1934) – сәясәтче, мөгаллим һәм журналист. 1915 елдан Төньяк фронтның 5 нче армиясендә. «Сугыш сафы» һәм «Чулпан» газеталарын чыгара. 1918 елның мартында Кызыл Армиянең I нче татар-башкорт батальоны комиссары итеп билгеләнә. 1920 елның гыйнварыннан – Казанда чыга торган «Эшче» газетасының җаваплы мөхәррире. 1920 елның 1 сентябреннән – ТАССР Эшче-крестьян инспекциясе халык комиссары урынбасары.

мәркәзләремездә дә хәзерге вакытта гәзит чыгару эшенең никадәрле күп фидакарьлек теләгәнлеген үз башымда тәҗрибә белән үткәргәнгә, мин бу каһарманлык, бу тырышлык алдында хәйран булдым. Гаскәри иптәшләрнең бу хезмәтләрен һәммә кешегә иҗтиһад нәмунәсе *(тырышлык үрнәге)* итеп күрсәтергә тиеш таптым». Дөрестән дә, бу эш зур батырлык иде. Техникасы ягыннан караганда, бездәге күп гәзитләрдән алда. Басылуы тигез, ачык чыгадыр иде».

Басманың үзендә газетаны чыгаруның максаты турында: «Алдымызда бик мөһим булган милли полклар төзү мәсьәләсе тора. Фәкать гаскәри вә фронтта булганлыкларыбыздан гына килеп чыккан бик күп мәсьәләләребез бар ки, бу мәсьәләләребез фронт өчен аерым гәзитә чыгарырга чакыралар. Мең мәшәкать вә кыенлыклар берлә булса да, үземезгә матбага таптык, хәрефләр алдырып, гаскәрләр арасыннан хәреф җыючылар табып, Ходага тәвәккәл итеп, «Сугыш сафы»н чыгара башладык. «Сугыш сафы»ның тоткан юлы – фронттагы мөселман солдатларын агарту, аларга сәяси вә милли аң кертү, Учредительный собрание мәсьәләләрен вакытында аңлата бару, милли полклар төзү мәсьәләсендә ярдәмче вә юлбашчы булу һәм, сугыш бетеп, таралган вакытта мөселманнарга тиешле төрле ярдәмнәр күрсәтү», – дип язылган.

«Сугыш сафында беренче татар гәзитәсе» исемле мәкаләдә Октябрь революциясеннән соңгы үзгәрешләргә зур өметләр баглана: «Чыдамлы, зур дөяләрдә, ук кебек тиз, матур җурга өсләрендә Кытайдан Ригага, Кара диңгездән Архангельгә кадәр йиткән, кыяматкә кадәр исеме телләрдә сөйләнерлек батырлыгын калдырган, бер чыбыркы шартлату илә илләрне тез чүктергән бабаларыбызның моннан 5 йөз ел борынгы тарихларын карагандa гына каһарман бер өммәт, милли командалы вә милли гаскәрле, сәламәт бер милләт булып күз алдына килеп узган картиналар, хакыйкать буларак, мәйданга чыга башладылар. Революция булу илә без, мөселман гаскәрләре дә,

Окопта газета уку

башкалар кебек сөенеп шатландык, сөйләштек, оештык, сүз дәвере заманы да үтте, иске җимерелде. 5 нче армиядәге мөселман бюросы үзенең нәшер әфкярен *(матбугатын)* булдыруны күптән уйласа да, бәгъзе бер манигълар *(каршылыклар)* сәбәпле, бу көнгә кадәр максатына ирешә алмаган иде. Кулыгызда гәзитәмезнең беренче номеры. Максатыбыз – сезләрне заман берлә бергә алып бару. Тотарга тиешле булган юлны мөселман гаскәрләренә күрергә зарур. Тәңрегә – тәвәккәл, бездән – дәрт, сездән – дәрман, туганнар!»

«Сугыш сафы» газетасында милли-мәдәни мохтәрият, федератив корылыш, милли полклар хупланган, Учредительное собрание турында мәкаләләр дөнья күргән һәм «5 нче армия мөселманнарының башкаручы хәрби комитеты хәбәрләре» даими басылган.

Алман гаскәрләре һөҗүмгә күчкәч, Төньяк фронтның мөселман комитеты әгъзалары Петроградка китә. Шулай итеп, нибары 11 саны чыгарга өлгергән газета эшчәнлеге 1918 елның 19 мартында туктатыла.

Фронт шартларында ислам дине һәм йолалары, милли гаскәри берләшмәләр төзү турындагы кайбер язмаларны сезнең дә игътибарга тәкъдим итәбез.

Гаскәри имамнар җыелышы

20-23 октябрьдә, Шималь *(төньяк)* фронт рухани эшләре бүлегенең чакыруы буенча, 5 нче армия хозурында дивизия, полк вә башка гаскәри кыйсем *(бүлек)* имамнарының киңәш мәҗлесе булды. Мәҗлескә 5 нче армиянең төрле гаскәри кыйсемнәрендә мөселманнарның дини эшләрен үтәп торучы 46 кеше иштиракъ итте *(катнашты)*.

*(Өч көн дәвам иткән бу мәҗлестә «Дивизия имамнарының вазыйфалары», «Отпуск мәсьәләсе», «Имамнарны кую вә тикшерү», «Гарнизон имамнары хакында», «Гаскәри имамнарның хокукы хакында» исемле пунктлардан торган махсус карарлар кабул ителә. – **Ред.**)*

Сугыш сафы. – 1917. – №1. – 5 ноябрь.

Фронт шартларында газета чыгару

5 нче армия мөселманнарының башкаручы комитеты хәбәрләре

3 нче мәҗлес 9 нчы ноябрьдә рәис Мухарский тарафыннан агитациядән кайтучылар хозурында ачылды. Фронттан кайтучыларның аңлатуына бинаән *(караганда)*, соңгы көндә мөселманнарның аерым кыйсемнәргә *(бүлекләргә)* аерылуы гамәлгә куела башлаган. Бәгъзе полкларда *(мөселман. – **Ред.**)* роталар тәшкил кылынган. Комитет әгъзасы Кайтазов барган дивизиядә бер *(мөселман. – **Ред.**)* батальон тәшкил ителү тәшәббесе *(эше)* бара. Дивизия башлыклары моңа үзләренең каршы тормаганлыкларын, кулларыннан килгән кадәр ярдәм итәчәкләрен вәгъдә иткәннәр.

Сугыш сафы. – 1917. – №3. – 21 ноябрь.

1 нче армиядә җыелыш

1 нче ноябрьдә армиядәге башкаручы комитетның чакыруы буенча килгән дивизия имам һәм делегатларның кушма мәҗлесе ачылды. Мәҗлескә рәислеккә подпоручик Габдрахман Рәхимкулов, секретарлыкка русчага Мөхәммәд Йосыф, мөселманчага мелла Кәмалетдин Котлыгилдин сайландылар.

Мәҗлестә каралачак мәсьәләләрнең түбәндәге рәвешчә программасы төзелде: 1) Учр. собрание хакында; 2) Башка милләтләр илә блок ясау хакында; 3) Армиядә мөселман солдатлары организациясе хакында; 4) Комитетка әгъза сайлау, милләт мәҗлесенә вәкил сайлау; 5) Меллалар мәсьәләсе.

Сугыш сафы. – 1917. – №3. – 21 ноябрь.

Мәүлед ән-нәби

12 нче армия карамагында булган дивизия комитетларына һәм бөтен чәстләрдәге имам әфәнделәргә:

12 нче армиядәге хәрби мөселман комитеты хозурындагы рухани комиссия тарафыннан игъламнамә.

Бу ел 13 нче декабрь көнне Мәүлед ән-нәби тугры килә. Шуның өчен, дивизияләрдәге мөселман комитетлары һәм имам әфәнделәр, тиешле роталарга мөрәҗәгать кылып, шул көннәрдә мөселман солдатларын эш һәм занятиеләрдән бушаттырып бәйрәм иттерергә һәм Мәүлед ән-нәби көнне аларны гыйбадәткә җыярга мөсәгадә *(мөмкинлек)* алуларын үтенә.

Рухани комиссиясенең вакытлы рәисе: Күчүмов. Сәркатип: Г.Гыйльметдинов.

***

Диния нәзарәтенең бәйрәмнәр җәдвален төзегән тәкъвимнамәсенә бинаән *(караганда)*, Мәүлед ән-нәби 13 нче декабрьдә чәршәмбе буладыр. Шул сәбәпле, армия имамнары бу көнгә кадәр армия ыштабына аңлатмаган булсалар, тизрәк аңлатып, шул көн мөселманнарны хезмәттән бушату вә гыйбадәт кылуга имкән бирү мәсьәләсен приказда таратырга яки корпуслар вә аерым дивизияләргә телефонограмма илә йибәртергә иҗтиһад итсеннәр. Диния нәзарәтенең мөфтисе: Килдебәков.

Сугыш сафы. – 1917. – №4. – 29 ноябрь.

1 нче армия съезды

11 декабрьдә Шваненбургта 1 нче армия мөселман делегатларының съезды ачыла. Беренче армия мөселманнарының үз чәстләреннән вәкил сайлап йибәрүләрен идарә үтенәдер.

Сугыш сафы. – 1917. – №4. – 29 ноябрь.

*Текстларны басмага **Ленар Гобәйдуллин** һәм **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Мирхәйдәр Фәйзи: *«Күңелем гүя оҗмахка керде»*

М.Фәйзи

(Көндәлек)

1922, июнь. Җәйләү.

Хуҗабыз Исмәгыйль агай ачык, күңелле, фикерле генә бер кеше. Ул безне борчымый. Карт булса да, динле булса да, суфыйланган булып, кәефне җибәрми. Бер җитмеш яшьлек карт кереп утырып, гел кызлар, кызыклар хакында сөйләп, безне кызартып, көнләштереп чыкты.

Исеме әле билгеле булмаган бер пьеса яза башладым. (Автор кулыннан кызыл кара белән өстәлгән: «Адашкан күңел». 1926.) Хәзерге планым белән дүрт пәрдә, биш картинада булырга тиеш. Хәерле эш булсын!



М.Фәйзи көндәлегенең июль (1922 ел) аеннан башланган бите

20сендә көн бер тәртип белән уза. Эчәбез, йөреп киләбез дә эчәбез. Кояш ваннасы принимать итеп кайтабыз да эчәбез. Эчә-эчә язабыз, җырлый-җырлый эчәбез, бер тапкыр йоклап алабыз. Кымыз үз-үзеннән туйдыра тора. Кич белән чәй дә, аш та програмнан төшерелде.

Икебез җәяүләп өч чакрымдагы Измага (нугай авылына) бардык. Мәсҗедләренең манарасын бик яраттык. Кантонлыктагы мин күргән һәммә манаралардан да матур. Гали агайга кереп, кымыз эчтек. Кызыл суының ярында аяк салындырып байтак утырдык. Арып-талып йөреп кайттык.

Кымыз бик һәйбәт. Көн дә бер чирек эчәм. Шуннан арттырмамдыр, шаять. Докторлар кымыз эчүдән, ит ашаудан, күп йөрүдән вә башка күп рәхәтлекләрдән катгый тыялар. Ә бу йөрештә шул сыйфатлар гел алдымда тора. Башкорт гадәте эчендә бу хәлләрдән саклана алу мөмкинме?!

21ендә Солтанскидан Вәкил мулла белән Эстәрледән бер карый килделәр. Бай тәкә суйды. Курайчы Мөхи агай китерелде. Уен, җыр, биюләр белән кызу гына, җанлы гына бер мәҗлес булды. Курайчы уйный да көйнең тарихын сөйли, аннан җырлап җибәрә. Вәкил мулла бик дәртле, күңелле кеше икән. Җырлап та, күңелле әңгәмәләрне сибеп тә мәҗлесне ямьли. Карый да дәртле кеше, ул инде бәетләр, «Мөхәммәдия»ләр белән үзенчә бизәк ясый. Исмәгыйль агайларның агасы – җитмеш яшьлек карт Габбас хәзрәт тә курайлы җыелышта дәрт белән утыра. Мәҗлестә ике хәзрәт, бер карый, берничә ап-ак сакаллы карт бар. Җитмеш яшьлек картлар сикереп төшеп бии, яшь егетләр аларның эзенә төшә. Тартыну, суфилыклар юк. Бу картина мине хәйран итте. Никадәр башымны ватып карасам да, татар картлары, бигрәк тә муллалары белән шундый бер хәл булганны-күргәнне хәтеремә китерә алмадым.

Кунакларга, хуҗа һәм муллаларга, картларга җырлап эчердем. Мөхәррирче дигән исемне алып, үз кеше булып, табында сәяхәт иттем. Садыйк та җырлап эчерде. Байтак мактауларның астында калдык. Биючеләргә акча ташлап тордык.

22сендә иртәнге чәйгә коймак пешерделәр. Сибай авылының Һибәт дигән бер карт углы белән килеп төште. Кунак та кунак. Бу хәл безнең өчен бик мәтлуб булмаса да, тормыш типларын күрү дәрте белән түзелә. Картның улы иптәшлеккә ярардай ямьле егет. Мондый тормышта кызларны өмид тә ителми, әмма шундый егетләр булмау ачуларны китереп куя. Яшьләрчәрәк итеп яшисе иде.

«

Татар илен сагынам мин! Рухымны иркәләгән, табигатемне борчымый торган татар тормышын сагынам. Казан, Татарстан, син кайда?! Ал балаңны үз кулыңа! Куй мине үз туганнарым арасына! Эзләп тапкан гөлләрем белән аларның гына бакчасын бизисем килә...

Садыйк белән Боравычлы тауга барабыз дип чыгып, кызып китеп, бу тирәдәге бердәнбер каенлыкка кадәр бардык. Матур була агачлы җирләр! Каенга язулар яздым, нечкә сабаклар белән чук-чук салынган каен сабаклары алдым, яңа тәм керә башлаган җиләкләрдән авыз иттем. Кәрешкәләр вә башка төрле чәчәкләр белән бизәнгән куе озын үләндә ятып, кояш ваннасы принимать иттек. Йөрешләребез күңелле чыга. Көн бер дә ялыктырмый узып тора.

29ында эчүне үрчетә алмыйм, ярамавын хис итәм. Расходланып ятуымның мәгънәсен тапмый башладым. Бу халыкның тормышы белән минем арамда үтеп чыгу мөмкин булмаслык бер аерма барын сынадым. Аларның гадәт-җоласы белән табигатемнең дус була алмавын сиздем. Ашау-эчү тәртипләре үземне авыруга сабыштырачагын белдем. Шулар сәбәпле тормыш белән җырак танышу, гадәт-җолаларын өйрәнү, халык әдәбиятын җыю дигән теләкләремне дә мәйданга куюдан гаҗиз калдым һәм, рухлана алмагач, файдасыз да таптым. Ваз кичтем.

Ах... Татар илен сагынам мин! Рухымны иркәләгән, табигатемне борчымый торган татар тормышын сагынам. Казан, Татарстан, син кайда?! Ал балаңны үз кулыңа! Куй мине үз туганнарым арасына! Алар белән бергә яшисем килә. Эзләп тапкан гөлләрем белән аларның гына бакчасын бизисем килә...

1922, июль.

1ендә кояш чыкканнан торып, чәй кайнатып эчтек. Исмәгыйль агайлар килгәч тә, ат җиктереп, Мортазиннар утарына карап чыгып киттек. Яткан җиребездән җиде чакрымлык Сиртински исемле казачий авылы янында Урал суын кичеп чыктык. Урал суын күрү җаныма ямь, бәхет, тирән хисләр, эчке сизенүләр бирде. Илләремне, йөргән җирләремне, туганнарымны уйладым. Бер изге байлыкка ирешкәндәй, йомшак түшәккә яткандай булып киттем. Үтеп чыкканда, арбабызга су кереп, нәрсәләребез белән бергә үзебез дә азрак чыландык. Чиркәүле, зур Сиртинскиның үләннәр белән күмелгән урамнарын күреп хәйран булдым. Менә нинди җирләрне нинди итте бу ачлык!

Гел Урал буйлап киттек. Өч ятажлы бер шәп тегермәнне үтеп, көндез сәгать бердә нугайдан 23 чакрым торган Мортазиннар утарына җиттек.

Моңа кадәр артель булып, хәзер төп хуҗалары Мортазиннарга ун елга арендага бирелгән бу матур, бай утарда кадерле генә кунаклар булып кабул ителдек. Әтиләрнең якын аралашкан дус кешеләре булып, Габдерәүф миңа дус һәм кордаш та булганга, без ихлас чакырылган идек. Садыйк та – зур гына түрә һәм таныш кеше, шунлыктан, без монда уңайсызлык сизеп килмәдек.

Шундук Мортазиннар белән уртак буа биләүче казакъның баласы үлү хәсрәтеннән ясалган бата мәҗлесенә чакырылып, тирмәгә киттек. Гел кыргыз *(казакъ. – **Ред.**)* кунаклар белән тулган бу мәҗлеснең түренә менеп утырып, яңа гына башкорт тормышындагы кешеләр, казакъ тормышы эченә чумдык. Бөркәнчек, урамал, эрчәк

салган, асыл киемнәр, көмешләр белән ясалган апайлар тулган. Күзләр бай, милли киемнәр һәм кызыклы картиналар күрә.

Аштан соң бакчада йөреп килеп, кымыз эчтек. Бу вакыт азрак кунак кимегән иде. Тагы бер йөреп килеп эчкәндә, тагы азрагы кимеде. Шулай итеп кими-кими, без генә калдык. Әллә ничә рәт йөреп килеп эчтек. Эчү вакытында казакъча үләк әйтүләр булды. Нәҗип скрипка уйнады. Шафикъ абзый җырлады. Фатиха, Мәрьям, Маһитап туташлар хор белән җырладылар. Садыйк Шафикъ абзыйга җырлап эчерде. Мин элек бөтен мәҗлескә, аннан Шафикъ абзыйга, Габдерәүфкә җырлап эчердем. Бер комиссар декламация сөйләде. Безнең өчен яңа һәм күңелле генә мәҗлес булды.

Ишектән чык дисәң – бакча, анда кат-кат йөрелә, әле дә матурлыгын югалта алмаган зур, монтазам утыртылган агачлы бакчаның юлларында йөрибез. Туташлар ямьле, күңелле булып чыкты. Йортның җиткән кызы Фатиха туташ кыюлыгы, матур кыланышы, ямьле рәвеше, җагымлы мөнәсәбәте, хөрмәтләп торуы белән күңелләрне сихерләде. Бергә йөрдек, сөйләштек, үзләштек. Минем җәйләүдә басылган күңелем гүя оҗмахка керде. Рәхәтләнеп, куанып, рухланып киттем.

Кояш баеган вакытта Нәҗип скрипка уйнап, мин җырлап бакчадан чыгып, күл буйлап киттек. Көн гаять матур. Күренеш гаҗәп һәм серле. Җырлап, уйнап, йөреп кайттык.

Туташлар тормый торган, артель вакытында коммунарлар биләгән өйләрен күрсәтеп йөрделәр. Өйләрнең зурлыгы, бүлмәләрнең санап бетергесезлеге, салыну рәвешенең матурлыгы, әллә нинди күңелле терраса һәм балконнар, хуҗаларының чын бер помещик булганлыкларын икърар иттерде. Пароход туктый торган пристаньнәрне хәтерләткән нәфис беседкаларын да карап чыктык.

Кичке чәйне Шафикъ абзыйлар бүлмәсендә аларның кунагы булып эчтек. Зиннәтле бүлмә, зур орган уйнап тора. Зиннәт ханым чәй ясый. Орски кызларын күреп, үзем дә бер якынлык сизеп киттем. Былтыр июль берендә Орскига кайтып, әнием белән күрешеп, куанып йөргән идем. Әни, апай янында иркәләнәдер идем. Бу ел якташлар, ямьле җирләр, күңелле кешеләр арасына килеп кереп рухландым. Шөкер. Тик әнием кабердә, аның үлүенә ел тула, былтыр бу вакытларда актык көннәрен яшидер иде, байгыш…

Кич кеше ята башлады. Без, мин, Садыйк, Нәҗип, Фатиха, Мәрьям, Маһитап туташлар, скрипка алып, бакчага чыктык. Аллея буенча йөрдек. Туташлар «Таһир-Зөһрә» көенә җырлап бардылар. Аннан, агач ботаклары белән түбәләнгән эскәмияләргә утырып, яшьлек көннәренә матур хатирәләр калдырдык, сөйләштек, көлештек, шаярдык. Туташлар «Казан сөлгесе» көенә җырладылар. Садыйк белән мин бергә дә җырладык, ялгыз да җырладык. Хор белән «Сандугач-күгәрчен»не әйттердек. Нәҗип скрипканы матур уйный. Ай чыккач, аңа хас җырлар табыштык. Күңелле булды. Таң алдыннан гына кереп яттык.

2сендә чәйдән соң кызлар белән көймәдә йөрергә барыйк дигән идек, алар, кичкәрәк, диделәр. Бакчага су сибү аларны биләде. Безнең янга Маһитап туташны гына калдырдылар да, һәммәсе эшкә киттеләр. Без Маһитап туташ белән күл буена киттек. Көймәдә йөрдек. Мин, кеше белән утырырга куркып, үзем генә йөрдем. Их, күңелле! Нинди ямьле, нинди кадерле бер рәхәт! Җырлый-җырлый йөрдем. Су сибүчеләрне тыңлатып торып җырладым. Соңынтын Фатиха туташ тарафыннан макталу шәрәфенә ирештем. Кичкә балыкка китеп калмасак, кызлар белән киләбез әле.

Пар ат җигеп, без, Шафикъ, Зәки абзыйлар, Җәүдәт, балыкка Урал буена киттек. Ат арбасын күмеп килгән шәп үләнле тугайдан кояш баер алдындагы ямьле һавада

заулатып киттек. Бу да бер күңелле хәл. Ике-өч чакрымдай китеп, бер җиргә барып урнаштык та, кармаклар алып, һәрберебез бер җиргә урнаштык. Бүген мин биш кенә балык тотып калдым. Черки үтереп талый, еш-еш тәмәке тартам. Балыкны тынычлап тотарга черки һич ирек бирми. Минем кебек артык охотник булмаган кешегә җитә кала инде.

3сендә, таңнан торып, балыкка тотындык. Черки төнлә дә укытты, хәзер дә кояш чыкканчы тынычлык бирмәде. Урал балыгын тоту гыйлемен белмим, ахры, барысы сигез балык тоттым. Соңынтын, иренеп, кармакны ташлап, арбага бардым да җырлап утырдым. Башкалар зур-зур балыклар тотып килделәр – 2 поттай балык булды. Сәгать уннарда кайттык.

Беседкада җиләк ашый-ашый, апайга хат яздым. Бераз язгач, бакчага чыгып, туташлар янына бардым. Вәгъдә буенча, өч туташ, бер мин – дүртәүләп кырга, печән чапкан җиргә киттек. Мин шушы идея белән үк калган идем дә, печән чабу күренеше күңелемә кәгъбә иде. Менә хәзер, кызларны ияртеп, кәгъбәмне, аның алласын зиярәт итәргә киттем.

Күңелле кызлар белән барыш. Күңелгә бетмәс-төкәнмәс шатлыклар тудыра. Хосусан, Фатиха туташ миңа әллә нинди котдуси тәэсир ясый. Элек печән җыйган җиргә бардык. Ике тырма җыеп йөри. Аннан бер косилка янына бардык, җиләк җыеп ашадык.

Косилканың мөкатдәс серле тавышы әллә кайдан каршы алды. Ах, бу тавыш миңа нинди серләр сөйли. Тәмле печән исе, машина тавышы, үземнең печән чабып йөргәнемдәге хәлләрне күз алдыма китерде. Бу сәгатьләрдә бәхетемнең чиге булмады.

Бераздан яныбызга җиләк эзләп йөргән Нәҗип килде. Нәҗип – яшь, мин ярата торган хосусиятләргә ия бер егет. Бай баласы, ләкин үзе эшләүне сөюче, шунда гына ямь табучы бер крестьян. Көне буе кырда булып, малайлары белән бергә печән күбәли. Бөтен эшнең өстендә булып, үзе эшләшә. Ул бер идейный крестьян, минем юлымны гамәләт яшәтүче бер яшь, дәртле көч. Аны иркәләдем. Яхшы тәмәкемне бирдем. Кыр өстендә күңелле итеп ятып, без кайтып киттек.

Кайткач, тагы хатымны дәвам итәргә утырган идем, Габдерәүф килеп, йөрергә дип алып китте. Тирмәгә барып, кымыз эчеп йөреп кайттык. Туташларны иркәләгән кебек, ямьле эшчене дә иркәләдем.

Фатиха туташ бөтен рәвеше, килеш-килбәте, сыны-сыягы, төсе-бите, йөрешторышы белән күңелемне җәлеп итте. Нинде матур итеп йөри, нинди матур итеп сөйли, нинди җитез хәрәкәт итә! Аның җилтерәп чәйләр әзерләп йөрүе, җуына башласаң: «Су бармы?» – дип килеп җитүе, бер кулына сөлге, берсенә исле сабын тотып чыгуы, хозяйкалык итеп, китмәгез, кунак булыгыз, дип йөрүе кыйммәтле бер сыйфат. Бүген аның бик сөйкемле илтифатларына наил булып, балаларча куандым. «Бәйрәмдә безгә килегез, Темәскә кайтмагыз. Гел килеп торыгыз!» – ди. Матур сүзләр бит! Хозяйкалыкка хәзерләнүче бер кыз өчен күңелле сыйфат, аның белән берләшәчәк ил баласы өчен зур табыш бит. Яшә, иркәм!

Чәйдән соң өч туташ, Нәҗип белән мин бакчага чыктык. Скрипка уйнап ай калыкканчы утырдык. Көчләп мине дә җырлаттылар. Фатиха туташның тавышы астында тирбәлдем. Яшьләрчә генә кыланып, таңга якынлап кереп яттык. Нәҗип белән кундым бүген.

4есендә, туташларның бакчада мандолина уйнап йөргәнен ишеткәч, сикереп торды малаең! Тору белән Каспулатовның юлаяк ашына эләктем. Тагы кыргызлар

(казакълар. – ***Ред.****)* тулган. Араларына утырып болганудан котылдым, алай да казакъта башкорттагы кебек эрәтсез кыстау юк бит, җәймә куеп, өстәлгә утырттылар. Бер милиционер белән икәү урысча ашадык.

11ендә үпкәм авыртып тора. Азрак йөткертә дә. Чахотка була башладымы икән дип курыктым. Бу хәсрәтләр, бу уйлар, сагышлар чахотка итсә дә, гаҗәп түгел. Син генә җитешмәгән идең, рәхим ит! Тап-тар күкрәк, бер ягында чахоткалы үпкә, бер ягында пароклы йөрәк, бүтән тагы ни кирәк?! Гуляй, барин!

Ансыз саусыз йөрәк, хәсрәтем күп бигрәк;
Күп уйлану файда бирмәс, инде куярга кирәк...

Тирмәдә ялгыз кымыз эчеп утырам. Исмәгыйль агайлар печәнчеләр янына китте. Җиңгәй янына бичәләр, кызлар җыелып, җырлап, кымыз эчә башладылар. Бу тирмәдә мин җырлый башладым. Алар һәрвакыттагы гадәтләре буенча тыңларга килделәр. Бер тишектән карыйлар да, җылт итеп югалалар, качканда ялгыш кына тирмәгә бәрелгән булалар, бер-берсе белән кытыклашалар, берсен-берсе ишеккә таба этеп җибәрәләр. Тыңлаганнарын белдерергә теләп, ләкин белдермәскә тырышкан кебек кыланып, алар тирәмдә чуала. Мин отыры тозлырак җырларны сайлап сиптерә бирәм. *«Карап күзләр талдырганчы, ник чакырып алмыйсыз?»* дигән җыр да ычкынып китте, аңа башкалар ялганды. *«Челтер-челтер тәңкәләр челтери, җылтыр-җылтыр күзләр җалтырый...»* – дип бәйләндем. Бер-бер артлы кереп, икәве җырлап эчерде. Савытларына тәңкә салып кайтардым. Тирмәм, ишек кызлар, бичәләр белән тулып китте...

Күренекле дәүләт эшлеклесе Садыйк Чанышев

Бүген бик спирт эчәсем килде, ай, спирт булса! Шаулап аккан арыкның баганаларына утырып, иң яраткан көемә, иң яраткан җырларымны җырлап җуандым. Тауга менеп кояшта яттым.

12сендә кичкә таба җылга буенда, тирәк төбендә утырганымда Гобәйдулла дигән егет белән ямьле генә хатирә калды.

Ах, яткан җиребез матур! Кара инде бу кичке тын манзараны! Җәннәт бит, җәннәттән дә һәйбәт бит! Кояшның агач яфраклары белән шаяра-шаяра түбәнләп бару күренеше хәйран булып тамаша итеп торганда, җырактан җил белән килгән җыр тавышын ишетеп, сихерләнгән кеше рәвешенә кердем. Матур, саф, яшь тавыш белән: *«Ак ука мишура, хәсрәт эченә төшерә...»* – дип сызылган җырның кайдан ишетелгәнен белү шәүкы белән ары чабып, бире йөгереп эзләнеп йөрүемне күрүчеләр тилергән дип уйласалар уйлаганнардыр, әмма шул җырчыны күрә алмый калу «тиле» диюне йөкләүдән авыррак иде миңа. Тегермәнгә киттем. Буа буйлап җырның һаваны җырып, көмеш кебек шыңгырдап килгән ягына юл тоттым. Арык

ягында кодрәт иясен табып, рухан бер бәйрәм иттем. Аргы җәйләүнең бер башкорт баласы икән! Ул миңа җиләк бирде, мин аңа тәмәке бирдем. Кояшның сөзек таулар артына соңгы сары нурлары белән бөтен тирәне иркәләгән чагында мин егетнең музыкальный тавышы астында тирбәләдер идем. Бу миңа ниһаясез *(чиксез)* бер бәхет иде…

14ендә иртүк тордым. Нугайдан чыккач та, берәр стакан спиртны кагып алдык. Шуның шәфагате белән егетләнеп, җилләнеп алдык, малай, низнай, их, күңелле! Күңелдә шатлыктан башка уй юк. Тирә – җәннәт, утырганыбыз – пәрак… «Җиребездә яшәсен спирт!» – дип кычкырабыз. Колбактының урамына дуэт иттереп барып кердек.

Хәлилгә килгәндә дә җүнәтеп айнымаган идек әле. Корбангалиевларга төштек. Гайшә белән Гарифҗан каршыладылар. Гарифҗан, кунак итәргә дип, китми көтеп торган идем, дип чынлап үкенә. Ул мине, ни өчендер, яраткан икән. «Крестьян баласын мин дә яратам», – дидем. Гайшә дә: «Тиз киттең, кунак итә алмадык», – дип калды. Матур, җагымлы сүзләр ишетеп, минем белән күрешергә теләп тә, өйдә булмый калган Зиннәт ханымга сәлам әйтеп, Тәвелбаев, Петров – өчебез, кучерлы шәп пар атка утырып, заулатып Темәскә таба киттек. Садыйк аерылып калды. Матур тәэсир итеп, күңелем каршында сөйкемле Гайшә, мулла Мөхәммәт, Гарифҗаннар да калдылар. Ямьле тоелган Хәлил урамыннан бөтенесе белән тагы күрешүләрне тели-тели бардым.

Юлчылар шәп туры килде, барыш күңелле. Биш-алты чакрым йөреш ясап, Солтан күленә бардык. Картада да күрсәтелә торган бу зур күлдә Тәвелбаевлар үрдәкләр өчен үрмәкләп йөрделәр. Аннан юлга дәвам иттек. Иртүк тауның итәгендәге мәшһүр Солтански приискасында байтак туктап тордык. Охотниклар күлдә йөргәндә, мин элек эшчеләре – зимагурлары белән шаулап торган приисканы мөтәэссир сәйран иттем. Зәүкыма муафыйк картиналар гәүдәләндереп, тын гына торган гыймарәттән тарихи серләр укыдым. Бу җирләр күңелемә җылы тоелды.

Ирәндек тавын менә башлаганда гына Күсем авылын үттек. Тау биек, күренешләр матур, дәһшәтле, бик күңелле урыннардан, тирәкләр арасындагы күперләрдән үтелә, чылтырап кечкенә җылгалар кала. Чияләр, җиләкләр, кызыл бөрлегәннәр җыеп ашадык. Петров җиләк пирогы белән сыйлады. Тау башына менеп җиттек. Җанкүзәү ташын янынннан күрергә, Колак, Күсем ташларын якыннан гына күрергә муаффәкъ булдым. Җырактан гына Талкач күлен дә күреп үттем.

Инде таудан түбән Темәскә таба очабыз. Сусалып, кымызны сагынып, кадерле нигъмәттән аерылганлыгымны сизеп, кайгырып барам.

Кайтып җиттек. Извозчикка ике миллион биреп, өйгә кердем. Өй салкын, җыйнак икән, рәхәтләнеп киттем. Җиләк кагы белән рәхәтләнеп чәй эчтем. Өйдәгеләр мине, симергәнсең, дип каршыладылар. Симерү кайда? Ай буена булганы биш кадак арттым.

Ай, үткән икән рәхәт чаклар! Кайда калды тирмәдә рәхәтләнеп йоклаган чаклар? Өй бөркү, эссе тоелып, төнне тынычсыз үткәрдем.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

безнең мирас №6 июнь 2020

Буыннар бәйләнеше

Клара Тукаева



Имай Насыйриның нәсел шәҗәрәсе

Ата-бабаларыбыз борын заманнардан ук үзләренең шәҗәрәләрен дүрткел яки башка формада язганнар. ШӘҖӘРӘ күбесенчә агач рәвешендә төзелгән. Агач ул һаваны, җирне һәм җир астын берләштерүче билге булып саналган. Табигать кануннары буенча, һәр кеше бу дөньядан кайчан да булса китә. Әмма дөньядан киткәннәр дә, шушы җирдә яшәп калганнар да, яңа туган сабый балалар да үзара тыгыз бәйләнештә кала.

Шәҗәрә – нәсел тамырларыбыз. Ул – гаилә тарихы, авыл тарихы. Олуг шәхес – Башкортстанның күренекле язучы-прозаигы, башкорт совет әдәбиятының классигы, бер үк вакытта ифрат катлаулы елларда милиция хезмәткәре, Күзәй кантон милиция начальнигы, Башкорт АССРның милиция политкомиссары, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Имай Насыйри – минем кан кардәшем. Туган җиребез – Стәрлетамак районының Түбәнге Усылы авылы. Борынгы заманнарда бу авыл Усылытамак дип аталган. Авылга 1700 нче елда нигез салынган. Туган авылым Усылыда 1998 елның көзендә узган Имай Насыйриның 100 еллык юбилей тантанасы күңелемдә яңа кичерешләр уятты. Шул көннән башлап шигырьләр яза башладым. Юбилей тантанасы үтүгә, тирәнгәрәк төшеп, үземнең нәсел тамырларымны, кан кардәшемнең тормыш һәм иҗат юлын җентекләбрәк өйрәнү теләге туды. Якын-тирәдәге шәһәр һәм авылларда яшәүче иң өлкән яшьтәге кардәшләребез, Имай Насыйрины күреп белгән туганнарыбыз белән очрашып сөйләшүләр алда үтеләсе юлларымны як-

тыртып җибәргәндәй булды. Язучының тормыш һәм иҗат юлын өйрәнәсем килеп, гомеремдә беренче тапкыр эзләнү эшләренә тотындым. Бик кызыксынып, бу эшнең эченә үк кереп киттем. Шушы теләк мине Башкортстан Республикасы Үзәк Дәүләт тарихи архивына алып килде. Монда мин үзем өчен бөтенләй таныш булмаган икенче бер дөньяга килеп кергәндәй булдым. Гасырлар буена архив киштәләрендә сакланып килгән язмаларны кулыма алып, алар белән таныша башлагач, бу эшнең гади укытучы өчен ни дәрәҗәдә авыр һәм күп чыгымнар таләп ителә торган эш икәнлеген аңладым. Бер көндә, бер айда, бер елда гына тәмамланасы эшләр түгел икән! Башкаладан 180 чакрым ераклыкта булган үзең яшәгән авылдан җәяүләп чыгып китеп, шушы юлларда еллар буена очраклы машиналарга утырып йөрүләре генә дә (ашау һәм торак мәсьәләләрен исәпкә алмыйча) ни тора! Әнә белән кое казыган сымаграк эш икән бу… Ревизия язмаларын һәм башка төрле тарихи язмаларны укыр өчен белгеч булырга да кирәк икән. Әмма тукталып калмадым. Бер үк вакытта нәсел тамырларымның тарихын өйрәнү эше белән дә мавыгып киттем. Айлар, еллар буена йөрелде… Бу эшне үзем генә ерып чыгарлык түгел иде. Шәҗәрәбезне өйрәнү барышында миңа Русия Фәннәр Академиясе Уфа гыйльми үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институтында шәхси заказымны ачарга да туры килде. Бөтен мәгълүматларның дөрес һәм тулырак булуы минем өчен иң мөһиме иде. Һәм, ниһаять, шәҗәрәбез еллар үткәч кенә әзер булды! Язучы Имай Насыйриның ШӘҖӘРӘСЕ иде ул. Низаметдин улы Имаметдин Насыйров белән кардәш икәнлегебезне гаиләдә кече яшьтән үк барыбыз да белә идек. Ләкин ничек һәм ничәнче буын аша нәселдән икәнлегебез билгеле түгел иде. Безнең гаиләбез һәм бөтен нәсел-ыруыбыз өчен зур ачыш та булды бу хезмәтем. Уфа шәһәренә йөреп, бер үк вакытта, озак еллар буена, Имай Насыйриның тормышын һәм иҗатын өйрәнеп, Ф.Э.Дзержинский исемендәге типографиядә «Йөрәкләрдә – Имай Насыйри» дигән китабымны нәшер итүгә әзерләп йөргән чор иде ул. Бу ул вакытта минем өчен бөтенләй булдыра алмаган ят эш иде. Нәшриятның генераль директоры һәм техник редакторы Ринат Вахит улы Шакуров һәм Ләйлә Галәветдин кызы Вәлиевалар, китабымның редакторы, Башкортстанның халык шагыйре Марат Нәби улы Кәримовларның эчкерсез ярдәме, кешелеклелеге, сабырлыгы нәтиҗәсендә, ун ел дигәндә, бу хезмәтем китап булып өлгерде! Шушы тәүге китабымны производствога кертер вакыт килеп җиткәндә, шәҗәрәбез дә әзер иде! Тормышымдагы шушы вакыйганың очраклы булуы мөмкин түгел! Мөкиббән китеп, шушы эшләр белән мәшгуль булып йөргән әлеге чорда үзем дә аптырап калган гаҗәеп хәлләргә очрадым… Аллаһы Тәгаләнең ярдәмен адым саен тойдым. Бабакаемның изге рухы да бу чорда минем янымда гына йөрде бугай. Югыйсә, шундый зур эшне гади бер укытучы җиңеп чыгарлык түгел иде. Анда – язучының тормышы, иҗаты, сайланма әсәрләре. Бер мең данә тираж белән чыккан «Йөрәкләрдә – Имай Насыйри» дигән шушы китабымны Имай Насыйриның 110 еллык юбилей көннәрендә кулыма алдым! Анысы да очраклы булмагандыр…

«Бөтен мәгълүматларның дөрес һәм тулырак булуы минем өчен иң мөһиме иде. Һәм, ниһаять, шәҗәрәбез еллар үткәч кенә әзер булды! Язучы Имай Насыйриның ШӘҖӘРӘСЕ иде ул.

Китапка нәсел-ыруымның 12 буынын бергә бәйләгән шәҗәрәбез дә урнаштырылды. (Еракта калган 2008

елда 12 буыннан торган шәҗәрә иде ул.) Әйтергә кирәк, шул шәҗәрәне әзерләгән шушы чорда «шәҗәрә», «шәҗәрәләр төзү» дигән сүзләр әле бик сирәк ишетелә иде. Шәҗәрәләр турында күңелемдә шигырьләр туды. Ун елдан соң гына, 2008 елның октябрь аенда, бу хезмәтем иҗатымның тәүге җимеше булып өлгерде. Бер айдан соң, үзнәшер ысулы белән, язучы турындагы язмаларым, «Йөрәкләрдә – Имай Насыйри» дигән исем белән, китап булып чыкты. Тәүге китабым иде ул минем! Гомеремнең шушы кечкенә генә бер өлеше эш арасында алып барылган, иҗат дип аталган яңа юнәлеше иде.

Берникадәр вакыт үтүгә, әнием яклап картәнием Гөлҗимеш Мусакаеваның нәсел тамырларын өйрәнү эшенә тотындым. Эш барышында үзем өчен тагын бер ачыш ясадым. Данлыклы якташларым – Тәлгат, Мидхәт һәм Нияз Мусакаевлар белән без бер тамырдан булып чыктык. Нәсел очыбыз Бикбау улы Муса Бикбавовның (1739-1789) тамырларына тоташты. Бик күп көч һәм чыгымнар таләп ителгән өч тармактан торган шәҗәрә булды ул. Туган авылым Усылыда оештырылган Имай Насыйриның 115 еллык чираттагы юбилеена (2013 елда) әтием яклап та, әнием яклап та төзелгән шәҗәрәләребезне, баннерларга да эшләтеп, туган авылыма бәйрәмгә алып бардым. Юбилей көненә шәхси заказым белән архивта эшләнгән Уразмәт, Үрге һәм Түбәнге Усылы авылларының тарихы һәм минем сүзләремә Вәкил Мурзин язган «Усылы – туган ягым», «Бәбкә үләннәре» дигән җырларым да өлгергән иде. Юбилей алдыннан гына үзнәшер ысулы белән чыгарган «Эзләремне салдым бу җиргә» дигән өченче китабымны кулыма алган идем. Шулай ук, беркемнең ярдәменә дә өмет итмичә, Эстәрлетамак нәшрият йортында, икешәр генә данә итеп булса да, әтием Ярулла Насыйровның фронтта язган шигырьләрен, Башкортстанның күренекле шәхесе, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Башкортстан Рәссамнәр берлеге әгъзасы, Нефтекама шәһәрендә яшәп иҗат итүче талантлы рәссам, сөекле абыем Юнер Насыйровның тормышы һәм иҗаты турында фотоальбом нәшер иттем.

Ул көнне мин Шәҗәрә-2011, Шәҗәрә-2013 Республика конкурсларының җиңүчесе дә идем. Имай Насыйриның 115 еллык юбилеен да, әлхәмдүлилләһ, менә шундый зур бүләкләр белән каршы алырга насыйп булды миңа...

Билгеле булганча, Русиядә 1719-1859 елларда ун ревизия уздырылган. 1816 елдагы җиденче ревизия язмалары буенча, Уразмәт авылын нигезләүче Уразмәт Исәнбәтевнең (1696-1786) ул елны өч улы теркәлгән: Рәҗәп (66 яшь), Ходайбирде (54 яшь), Ходайназар (53 яшь). Шушы мәгълүмат уразмәтлеләрнең нәсел тамырлары тарихын өйрәнү эшен башлап җибәрүдә миңа зур этәргеч бирде. Иң башта авыл тарихына юкка гына тотынмаганмын икән. Иң кирәге – авыл тарихыннан алынган шушы мәгълүмат, шушы исемнәр булып чыкты. Күңелемә күп еллар элек сөйләнгән сүзләр килә: «Авылның борынгы зиратында элек Уразмәт исемле кешенең кабер ташы бар иде. Ап-ак булып шул таш ерактан ук күренеп торды...» Үзләре исән чакларында шул ташның урыны кайдарак ятканын да әйтеп, бу сүзләрне авыл аксакаллары Иншар абый Зиннәтуллин белән Гали абый Рафиковлар җиткергән иде миңа. Их, диясе генә кала... Шул чакта бу агайлар белән бергәләп анда барып, эзләп табасы булган да бит ул ташны... Ул вакытта да, соңрак та авыл халкы бу кешенең алар өчен кем булганлыгын белми иде шул әле. Авылдан еракта урнашкан борынгы бу зират мин әлеге авылга килеп урнашкан елларда, ятимсерәп, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган иде. Дистә еллар буена ул шулай утыра бирде. Зиратның шундый ихатасы күп урыннарда җиргә үк сеңеп беткән иде... Яланнарга җиләккә яки печәнгә йөргән чакларда гына күрә идем мин ул зиратны. Башкалар да борынгы зиратны үтеп-сүтеп йөргәндә генә күрделәр.

Клара Тукаева үзе оештырган музейда

Шушы борынгы зиратка яңа койма кору мәсьәләсен күтәреп, мин 2006 елда якташыбыз Ә.М.Сәмирхановка мөрәҗәгать иттем. Эшләр тиз арада башланып та китте. Шул елны ук авылның борынгы зиратына яңа койма корылды. Ике елдан соң шул ук яланда көчле янгын чыкты. Җәй уртасының эссе һәм давыллы бер көнендә ут өермәсе зират өстендәге үләннәрне генә түгел, яңа төзеп куйган коймаларны да, эш кораллары саклана торган корылманы да, күз-ачып йомганчы дигәндәй, көлгә әйләндерде.

Авыл белән архив арасында йөри торгач, бу эшне дәвам итәрлек мөмкинлек бер мәлдә төрле яклап чикләнде. Ә туктыйсым килми... Бер көнне мин Уфа шәһәрендә яшәүче якташым Владимир Александрович (Вәли Әнвәр улы) һәм аның тормыш иптәше Венера Гәрәй кызы Табаевлар белән очрашып сөйләштем. Бергәләп архив юлларында йөрелде. Һәм!.. Табаевлар белән бергәләп тапкан тәүге ачышыбыз: Вәли Әнвәр улы Табаевның нәсел җепләре Уразмәт Исәнбәтевнең Ходайбирде исемле улының нәсел тамырларына тоташа икән бит! Авыл зиратына күмелгән Уразмәт Табаевларның ерак бабасы булып чыкты. Тагын эзләнүләр... Күп тә үтми, авылда яшәүче Шәвәлиев, Зиннәтуллин, Хөснетдинов, Нургалиев, Сәмирханов, Латыйпов, Әхмәрев, Нурмөхәммәтов, Камалиев, Шәрифуллин, Әхмәтҗанов, Нәкиев, Котлыбаев һәм башка бик күп фамилияләрне, архив залларында утыра торгач, Уразмәт Исәнбәтевнең Ходайназар, Әхмәр һәм Габбас исемле улларының тамырларына тоташтырдым. Һәрберсенең нәсел җепләре, 10-12 буын аша, ерак кан бабалары Уразмәтнең тамырларына үрелде!

Күптән түгел Рәҗәп Уразмәтовның йөзләгән исемне, шушы авылда яшәүчеләрнең бик күп фамилияләрен үз эченә алган шәҗәрәсе төзеп куелды.

Рәҗәп Уразмәт улы Уразмәтов Фәизов, Басыйров, Муллагалиев, Халиков, Хафизов, Газизов, Җәмилов һәм бик күп башка авылдашларымның да ерак бабасы булып чыкты. Авылдашларыбыз Вафир, Насыйр һәм Гали абыйларның фамилияләре – Әхмәтгәрәев. Бу фамилиянең тамырлары кай тирәдәрәк булыр икән дип уйланам. Элекке күршеләрем Наҗия белән Гали Әхмәтгәрәевләрнең теленнән мин еш кына «Әхмәр», «Әхмәрләр» дигән сүзләр ишетә идем. Әхмәтгәрәевләр нәселе Уразмәт бабабызның Әхмәр исемле улыннан таралган булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килеп, башкалага кабат-кабат барып, архив язмаларын актарам. Ләкин бәйләнешне

таба алмыйм. Бер көнне мин, Сәмирхановларның шәҗәрәсен тотып, Вафир абыйның кызы Зөлфирә Исламовага киттем. «Менә шушы шәҗәрәне җентекләп кара әле, Зөлфирә, – дим. – Әхмәтгәрәевләр кайдадыр шушында булырга тиеш. Андагы исемнәр сиңа нидер сөйләр төсле тоела миңа». Бераздан аның йөзе нурланып балкып китте. Зөлфирәм, анда язылган бер исемгә тукталып: «Безнең әтиебез: «Фамилиябез Шәрәфетдинов булырга тиеш булган», – дип сөйли иде», – димәсенме! Шуннан соң ул шәҗәрәмдәге дәвамы тукталып калган Шәрәфетдин исемен кадерләп сыйпап ук куйды. Күп уйлап тормыйча, Зөлфирә, архив чыгымнарын берүзе күтәреп, Русия Фәннәр Академиясе Уфа гыйльми үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институтына мөрәҗәгать итте. Шулай итеп, үз нәсел-ыруының шәҗәрәсен Зөлфирәбез үз исәбенә эшләтеп алды. Әхмәр нәселеннән булган Шәрәфетдин дигән кеше Зөлфирәнең ерак бабасы булып чыкты һәм Уразмәтнең Әхмәр исемле улына тоташты.

«Шушы борынгы зиратка яңа койма кору мәсьәләсен күтәреп, мин 2006 елда якташыбыз Ә.М.Сәмирхановка мөрәҗәгать иттем. Эшләр тиз арада башланып та китте. Шул елны ук авылның борынгы зиратына яңа койма корылды. Ике елдан соң шул ук яланда көчле янгын чыкты.

Шул рәвешле, авыл халкының төп өлеше шәҗәрәле булды.

Шәҗәрә төзү чорында тагын бер зур ачыш ясалды: уразмәтлеләрнең ерак бабасы Уразмәт Исәнбәтев 1786 елда Уразмәт авылының борынгы зиратында җирләнгән икән.

Уразмәт – минем туган авылым түгел. Әмма мин бу җирдә шушы авыл һәм анда яшәүче кешеләр хакында кайгыртып гомер кичерәм. Авылдашларымның шәҗәрәләрен төзегән шушы чорда гына да авыл халкы өчен нәсел тамырларының тарихы буенча күп ачышлар ясалды.

Төрле елларда уздырылган ревизия язмалары буенча, юбилей якынлашып килгән көннәрдә Уразмәт Исәнбәтевнең ТУГЫЗ баласы – 8 улы һәм бер кызы булганлыгы ачыкланды. Менә алар:

Сәфәр (1717)
Габбас (1747)
Рәҗәп (1750)
Әхмәр (1752)
Сәхибә (1752)
Рәфикъ (1753)
Ходайбирде (1762)
Ходайназар (1763)
Ибрай (1763)

Уразмәт Исәнбәтевнең биш баласы – Габбас, Әхмәр, Ходайбирде, Ходайназар, Рәҗәп исемле улларының тамырлары бүген арабызда яшәүче авылдашларыбызның нәсел очларына тоташтырылды.

Яңакларым буйлап, ирексездән, тозлы күз яшьләре тәгәри. Кайгы түгел, ә шатлык яшьләре алар. Уразмәт авылы беркайчан да сүнмәячәк, чөнки бүген бу авылда күңелләрне илаһи нур белән чистартып торучы изге азан тавышы яңгырый! ■

Тарих көзгесендә Кыр Бикшиге авылы

Нәкыйп Каштан



Сембер губернасының Буа өязе картасында Кыр Бикшиге (уртада) һәм башка татар авыллары. 1808 ел

Хәзерге Чуаштанның Батыр районына караган Кыр Бикшиге (Кыр-Бикшик) элек-электән мишәр авылы санала. Ул беренче тапкыр Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» хезмәтендә үк (галимнәр аны 1796 елдан соң язылган дип фаразлый) телгә алына. Шул ук хезмәттә кайбер табигыйннәрнең[1] исемнәре дә күрсәтелеп уза: Тимеш Хаҗи Солтанморат углы, Илһам Ибраһим углы, Симеш Килдебай углы. 1694 елгы ошбу каберлек һәм кабер ташлары әлегәчә исән-имин саклана. Кыр Бикшиге үзе 1647 елда нигезләнгән һәм инкыйлабка кадәр Сембер губернасының Буа өязенә кергән.

Шулай да, авыл ничек оешкан соң? Нигә аны мишәр авылы дип атыйлар?

Бу сорауларга җавап эзләп, миңа шактый архив материалларын барларга туры килде.

1578 елда Явыз Иван ил чикләрен ныгытыр өчен «засека сызыклары» булдыру һәм анда, биләмә белән акча биреп, йомышлы татарларны урнаштыру турындагы указ чыгара. Нәтиҗәдә, татарлар, дулкын-дулкын булып, берничә дистә еллар дәвамында, ул вакыттагы ил чикләренә барып төпләнә. Мещерадан көнчыгышка таба күченгән бер

---

[1] Табигыйннәр – сәхабәләрнең шәкертләре.

дулкынның юлын гына күздән кичерик: Кадым – Арзамас – Алатыр – Курмыш (шунда ук Кыр Бикшиге) – Сембер...

1678 һәм 1679 елларга караган Зөя җанисәп кенәгәләрендә (Свияжские переписные книги) *Бикшик* авылы күрсәтелгән, анда: *«Казан өязеннән чыккан 39 алпавыты бар, калган халкы – йомышлы мишәрләр (мещеряки), крәстияннәре һәм буйдаклары юк»*, – диелгән. (Минемчә, бу алпавытлар Сәләй Сүлиевнең торыннары булса кирәк. Ул безнең якларда бик күп җир биләгән – Кыр Бикшигендә генә дә 142 гектары булган, төбәкнең иң бай кешесе саналган.)

Мещеряклар (мишәрләр). Фр.Кнорре рәсеме. XIX гасырның беренче яртысы

Кыр Бикшиге буш җирдә (пустошь) урнашкан. (Мондый җирләрне йортмазар салмыйча гына эшкәрткәннәр һәм алар өчен имана салымы түләнмәгән. Аннары бөтенләй ташлап киткәннәр.) Бу туфрак Кыргый кырның бер кисәге булып торган. Авылга нигез салучыларга, әлеге җирлек белән бергә, Кыргый кырдан да өлеш чыккан. Архив документлары бу хакта мондый мәгълүмат саклый: *«За неверстанные татары – Курманолейком Алмаметовым, за Урозмаметком Сююндюковым, за Ерлыганком Ногаевым, за Жданком Елдашевым, за Урусланком Бахтыгильдином, за Досаиком Бузаковым, за Чинбулатком Каибишевым, за Бармалейком Бузаковым, за Мамеделейком Бурнашевым, за Янгилдою Емикеевым, за Тохтарком Илашевым, за Кучюкаиком Елдашевым, за Алышком Урустаевым, за Тяребердеиком Чинаевым, за Ивашком Толубаевым, за Токаиком Байбулатовым, за Бурундучком Байбулатовым, за Давлеткильдеиком Борашевым, за Тингильдеиком Тогаевым, за Ангильдкою Булатовым, за Аибулатком Байсубином, за Итяшком Улюкашевым, за Ждяком Новиковым, за Маметком Мамешевым – всего за двадцать четыре человека – в поместье и на оброке пустошь на Диком поле по реке по Буле да по речке Ерыкле, по обе стороны, что была та пустошь прежде сего на оброке деревни Бекшиховы за чувашею за Токсубаиком Тегешевым с товарищи. А в нем пашни паханые добрые земли пятьдесят чети да Дикого поля четыреста тридцать чети, обоего в месте – пашни, паханные и Дикого поля – добрые земли четыреста восемьдесят чети в поле, то есть по 20 чети каждому и ещё 2400 копен – сена. А оброку им с того поместья платить в государеву казну старого по рублю по девятнадцати алтын за деньгою, да новые наддачи по три рубля по семи алтын по три деньги, обево платить им в государеву казну старого оброку и с новою наддачею по чытере рубли по двадцати, по шти алтын, по четыре деньги в год. Да им же с тои земли служить государеву службу».*

Күренгәнчә, бу татарлар моңарчы инде күпмедер вакыт йомышлы булып торган, аннары аларны яңадан дәүләт хезмәтенә чакырып алганнар, биләмә бүлеп

биргәннәр. (Мәмәт Мәмәшевнең гаиләсе булмый, вафатыннан соң аның җире яңадан дәүләткә кайтарыла.)

Терәлеп торган җирләрне татарларга «өләшү» хәзерге Канаш районына кергән Зур Бикшик авылы чуашларын пошаманга калдыра. Алар бу җирләрне янә үзләренә кайтаруны дәгъвалый. Ләкин мондый җавап алалар: *«...Били челом отцы их, Великому Государю и Царю и Великому князю Алексею Михаиловичу, всея Великая и Малыя и Белыя России Самодержцу. И писцу Ивану Францебекову, как он был в Свияжском, брат его Адарков Курманалейка съ товарищи 24 человеками, а той оброчной земель и о сенных покосах подали челобитную, чтобы ту пустошь: землю и сенные покосы отдать им*[2]*, Курманалейкъ, на оброк... Брат его Адарковъ, Курманалейка съ товарищи, по той земле построились дворами и назвали ту деревню Полевой Бикшик. И этими землями и сенными покосами брат его Адарков, Курманалейка съ товарищии владели и их Великих Государей, службу служили и оброк платили во все годы, а после брата его владеют они, Адарка с товарищии, и службу служить безпристанно и оброк платить по все годы, а чуваше, да живут отъ той их деревни версть 50 и владеють своими ясачными землями. И ныне де те земли за ними Адаркою съ товарищи, справлена и ихъ, Великих Государей, грамота въ Свияжск послана»...*

Бу язмамда архив текстларын оригиналдагыча калдырырга булдым. Алай да, аңлатып китүне кирәк саныйм: мишәрләр (мещеряклар) – Мещера җирлегеннән килеп урнашкан йомышлы татарлар ул, ә үзгә халык-мазар түгел. Тора-бара, күрәсең, төрле сәбәпләр аркасында, бөтен йомышлы татарларны (Мещерадан чыкмаса да) мишәрләр дип атый башлаганнар.

Һәрхәлдә, архив документлары бу яктагы авылларга кешеләрнең төрле җирләрдән килеп төпләнүен күрсәтә. Әйтик, 1780 елгы *«Ведомость Синбирского наместничества»* исемле хисапны карасак, Буа өязе халкы ошбу өязләрдән оешкан (өземтә генә китерәм):

Сембер өязенән – 15763;
Казан өязеннән – 2454;
Зөя өязеннән – 3358;
Чабаксар өязеннән – 87;
Чуел (Цивильск) өязеннән – 17...

Кыр Бикшиге авылы, нигездә, Зөя һәм Казан өязләреннән күченеп килгән йомышлы татарлардан барлыкка килгән. Документлар болай ди: җирле 16 гаилә керәшен татары, Казан өязеннән – 29 гаилә йомышлы татар (алар арасында алпавыт Сәләй Сүлиев һәм сотник Айсә улы Абдрахим гаиләләре дә бар); Зөя өязеннән – 67 гаилә йомышлы татар (хәзерге Бурнашевлар шуннан). Мишәр дип аталсак та, Мещерадан килеп төпләнүчеләр бездә юк диярлек (нибары 4 гаилә). Авылның төп өлеше – Сәләй Сүлиев һәм Айсә нәселләреннән. Шулай ук, Ярахановлар, Җәмдихановлар, Бурнашевлар нәселе күчле. Авылыбыз белән «цы»кылдап сөйләшәбез. (Татар мәдәнияте үзәгеннән читкәрәк тибәрелгәнгә күрә генә, бу як татарларның телендә, гореф-гадәтләрендә үзгәрешләр бар. Ләкин асылы һәм үзаңы шул ук – татарныкы!)

Күрше *Шыгырдан* авылына күз салыйк. Аны нигезләүчеләр – Казан өязеннән күченгән 226 гаилә йомышлы татар һәм 19 гаилә керәшен татары. Архив материалларына ышансаң, алар арасында морзалар да юк түгел.

Кече Шыгырдан Зөя өязеннән күченгән 40 һәм Казан өязеннән күченгән 35 гаилә йомышлы татардан оешкан.

---

[2] Ягъни татарларның җире булмый һәм алар, «баш орып», буш җирләрне үзләренә сорап ала. – ***Редакция.***

Сембер губернасының Буа өязе картасы. 1808 ел

«Татар авылларының байтагы кеше исеменнән ясалганын исәпкә алсаң, безнең авылны да Бәкшәехкә тоташтырырга мөмкин.

Тимәш авылына Казан өязенең 10 гаилә йомышлы татары нигез салган. Гәрчә алар үзләрен Касыймнан дип күрергә һәм күрсәтергә теләсә дә, документлар башкача сөйли. Дөрес, бу авыл кешеләре беркадәр үзгәчәрәк сөйләшә.

Татар Согыты авылы: Казан өязеннән күченгән 179 гаилә йомышлы татар һәм 6 гаилә керәшен татары.

Шуның белән бергә, *Кече Согыт* авылы Казан өязеннән күченгән 5 гаилә йомышлы татардан башлангыч ала.

Кырык Сайдак авылы: Сембер өязеннән – 17 гаилә керәшен татары һәм 46 гаилә йомышлы татар, Казан өязеннән – 52 гаилә йомышлы татар һәм 6 гаилә керәшен татары.

Кыр Бикшигенең атамасы турында да кызыклы тарихи материаллар бар. Е.И.Чернышевның *«Селения Казанского ханства»* хезмәтендә ул берничә вариантта языла: *Бейшихово, Бекшейхово*... (Чуашлар «б» хәрефен бигүк өнәп бетерми, алар аны «п»га алыштыра: Пикших, ди.)

XV гасырда Мәскәү кенәзлегендә Бекшик (оригинал чыганакта шулай языла) исемле Олуг Олыс илчесе утыра. Ихтимал, татарча ул Бикшәех (яисә Бәкшәех) булгандыр. Татар авылларының байтагы кеше исеменнән ясалганын исәпкә алсаң, безнең авылны



Кыр Бикшигенең асыл улы Фәтхи Бурнаш. 1920-1930 нчы еллар

да теге яисә бу Бәкшәехкә тоташтырырга мөмкин. Чуаш телендәге вариантның азагында сакланып калган «х» хәрефе дә моны куәтли кебек. Җөмләдән, Канаш районында Зур һәм Кече Бикшик (Пикших) авыллары да бар. Анда чуашлар яши...

Һәр туфрак асыл затлары белән кадерле. Безнең Кыр Бикшигеннән дә бик күп күренекле кешеләр чыккан. Алар арасында татар халкы өчен иң мәгълүме, иң кадерлесе, мөгаен, танылган шагыйрь, драматург, нашир, әдип һәм җәмәгать эшлеклесе ***Фәтхи Бурнаш*** булыр (авылга нигез салучылар исемлегендә (текст буенча алдарак) аның ерак бабасы ***Мәмәдәлик Бурнашев*** та бар иде). Шулай ук, бөтен дөньяга мәгълүм химик, академик ***Хәбибулла Миначев*** та шушы авылдан. Авыл яшьләре арасында узган җиңел атлетика ярышларында бик күп бүләкләр яулаган спортчы, СССР, Россия һәм Чуашстан Республикасы чемпионы ***Расих Камалетдинов*** та Кыр Бикшигенеке. Җөмләдән, алар икесе дә Сәләй Сүлиев нәселеннән. Авылда үз һөнәрен буыннан-буынга тапшырып килгән дин әһелләре, прокурорлар, эшкуарлар, фермерлар шактый. Бүген Кыр Бикшигендә 300дән артык йорт исәпләнә, һәрберсенең тәрәзәсендә уты бар, зур, мәһабәт клуб, халык театры, урта мәктәп эшли.

Кулланылган әдәбият:

1. Әхмәтҗанов Р.Г. Кайда син, Мишәрстан? – «Мирас» ж. – 2000 ел. – №4. – 84-91 б.
2. Гафаров И.А. Мишары. История и язык. – Казань: «Идел-ПРЕСС», 2011. – 256 с.
3. Зиятдинов Р.Ш., Зиятдинов К.Ш., Халиуллин И.Х. Алькеевский сувенир. – 2011 г. – 222 с.
4. Муслими «Таварих-и Булгария». История, овеянная легендами. Литературно-исторические памятники XVII-XIX веков. – Казань: Татарское книжное издательство, 2011 г. – 331 с.
5. Мухамедова Р.Г. К вопросу о расселении татар-мишарей. МТД. – Казань, 1962 г. – 86 с.
6. Мухамедова Р.Г. Татары-мишары: историко-этнографическое исследование. – Казань: Магариф, 2008 г. – 295 с.
7. Насыйров Х. Кулаткы морзалары. – «Безнең мирас» ж. – 2016 ел. – №5. – 41-43 б.
8. Орлов А.М. Нижегородские татары: этнические корни и исторические судьбы (очерки). – Нижний Новгород: Издательство Нижегородского университета, 2001 г. – 220 с.
9. Халиков А.Х. Первое государство. – Татарское книжное издательство, 1991 г. – 216 с.
10. Перечневая книга Свияжского уезда 1646-1652 г. Подготовлено Д.А.Мустафиной. – Казань: Издательство Казанского государственного университета, 2004 г. – 168 с. ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Токио. XX гасыр башы

Токио төрмәсе

Бирегә килгәч, тагын чәйләр эчтек. Йамагами җәнаплары белән бер сәгать тирәсе сөйләшеп утырдык. Дин әһеле дә безнең белән иде, ул миңа болай диде:

– Мин Сезнең хакта газеталарда бик күп укыдым, хәтта адресыгызны да эзләттем, барып күрешергә теләгән идем. Бик яхшы очраклылык булды әле бу, үзегез рәхим итеп килдегез. Мин бик шат. Сездән кайбер нәрсәләр турында сорашып белергә тели идем, әгәр вакытыгыз булса, әлбәттә.

– Бик яхшы. Кайсы вакытта, кайсы җирдә – әйтегез генә, мин әзер.

– Вакытыгыз булса, менә хәзер, биредә булмасмы? Безгә уңайлы булыр иде.

Шулай дигәннән соң, Таките җәнаплары миңа сорау бирде:

– Безгә Мөхәммәднең (с.г.в.) дине, аның нигезләре турында бераз мәгълүмат бирә алмассызмы? Мөхәммәдчелек нидән гыйбарәт?

– Мөхәммәднең (с.г.в.) дине гаять гади, саф дин, бөтен нигезе тәүхид һәм пәйгамбәрлектән гыйбарәт. Бөек пәйгамбәрләр нәрсәгә өйрәткән булса – шул. Мөселман булыр өчен, адәм баласы Хак Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген танырга тиеш. Моннан тыш, адәм угылларының һәр эштә мөгаллимгә ихтыяҗы булган кебек, дин эшләрендә дә, һичшиксез, өйрәтүчегә ихтыяҗы бар. Менә шул өйрәтүче – пәйгамбәр дә инде. Безнең Мөхәммәд (с.г.в.) динендә бернинди яшерен нәрсә юк. Шәригать кушкан киңәшләрнең саны – дүрт. Менә Ислам диненең нигезләре шуннан гыйбарәт.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

– Мөхәммәднең (с.г.в.) дине ничә мәзһәпкә аерыла?

– Бездә төп мәзһәп берәү, тармакларга бүленеп, бер-берсенә каршы тору бездә алай бик көчле түгел. Аллаһыны бер дип белеп, Мөхәммәднең (с.г.в.) пәйгамбәр икәненә иман китергән кеше мөселман була. Инану буенча икегә аерылган булсалар да, нигезе буенча барыбер берәү, чөнки ул аерма соңыннан барлыкка килгән һәм кечкенә генә бер төрлелектән гыйбарәт.

– Безнең Япониядә будда диненең 13 юнәлеше бар. Кытайда аннан да күбрәк һәм болар берсе икенчесеннән бик нык аерыла. Һәрберсе үзенең буддист булуына инанса да, берсе икенчесенә буддист дими. Әгәр Сез, галиҗәнап әфәнде, буддизм турында мәгълүмат алырга теләсәгез, мин Сезне бер бик зур кеше белән таныштырырмын, ул Сезгә, буддизм турында ни белергә теләсәгез, шуны аңлатып бирер.

– Бик шат булырмын, мин үзем дә шундый бер кеше эзли идем. Кайчан хәбәр бирерсез икән?

– Мин Сезгә телефоннан хәбәр итәрмен. Яшәгән җирегезнең телефон номерын әйтегезче, теркәп куйыйм.

Таките җәнапларына, шул рәвешле, телефон номерымны бирдем. Аннары ул саубуллашып китеп барды.

Төрмә башлыгы Йамагами җәнаплары, миңа төрмәнең планын һәм фоторәсемнәрен биреп, болай диде:

– Безнең төрмәбез ул кадәр бик әһәмиятле урын түгел, килмәгән җиребез күп, шәһәр хакимиятенең акчасы юк, шул сәбәпле, төзәтеп, яхшыртып җиткерә алмадык. Шулай булса да, кимчелекләребезне акрын-акрын төзәтергә уйлыйбыз.

– Төрмәгезнең кереме никадәр була?

– Ике йөз мең йен тирәсе була. Керемебезне тулысынча безгә калдырсалар, төрмәне тиешенчә төзәтә, яхшырта алыр идек, ләкин шәһәр хакимияте үз мәнфәгатьләрен беренче урынга куя.

– Бөтен Япониядә төрмәдә утыручыларның саны күпмегә тула икән?

– Ике ел элек кырык меңгә якын иде, хәзерге вакытта, әлбәттә, ул кадәр түгел, күпкә ким булырга тиеш.

– Сәяси тоткыннарыгыз бармы?

– Бездә сәяси тоткын юк дәрәҗәсендә аз, бер журналист бар. Ул да бер кешене хурлаган өчен хөкем ителгән.

Шулай итеп, Япония төрмәләре турында күргән-белгәннәремне язуда бу кадәре белән чикләнәчәкмен.

Университет карарга бару

Япониядә төп һәм иң зур университет булып хөкүмәт һәм Мәгариф министрлыгы ачкан дәүләт университеты санала. Бу университетның шәһәрчеге һәм бинасы шулкадәр зур ки, биредә җиде меңнән артык, бәлки, сигез меңгә якын студент белем ала. Моннан тыш, биредә гаять зур хастаханә, музей, китапханә дә бар.

Уку йортының бөтен җирен карап йөри алыр өчен, миңа Мәгариф министрлыгы тарафыннан махсус рөхсәт бирелгән иде. Мин ул рөхсәт буенча теләгән вакытымда килеп карап йөри ала идем. Ә, гомумән алганда, дәрес вакытларында дәрес бүлмәләренең күбесенә һәм анатомия бүлекләренә керү тыелган икән.

Мин рөхсәт язуы белән килә идем, кайсы җирен кереп карарга теләсәм, башта шул бүлеккә юнәлә, шунда ук бер «Хуш килдең» артыннан ияреп, күрәсем килгән бүлеккә бара һәм шуны карап йөри идем. Беренче тапкыр университетның химия

бүлеген күрдем, тик биредә бары тик дүрт сәгать кенә йөри алдым. Фән белән әллә ни бәйләнешем булмаса да, тәҗрибәләр ясаучы студент әфәнделәрнең тикшерү алып бара торган эшләрен күзәтү өчен генә дә шулкадәр күп вакыт сарыф итәргә туры килде. Минем бирегә килеп йөрүем берничә көнгә сузылды, һәркөн килеп, өч-дүрт сәгать вакыт үткәрә идем. Шулай булуга карамастан, бөтен җирне күреп бетерү насыйп булмады.

Мин күргән бүлекләрнең иң әһәмиятлеләре шулар: химия бүлеге, анатомия бүлеге, анатомия музее, хастаханә. Болар бик югары дәрәҗәдә оештырылган иде, бигрәк тә анатомия бүлеге, андагы хирургия әсбаплары искиткеч иде. Һәр төр анатомия өчен һәм, моннан тыш, операцияләр өчен аерым бүлекләр бар.

Мин бу бүлекләрне бик җентекләп карап йөрдем, кисүләрен, турауларын берәм-берәм карап күзәттем. Андагы арулык һәм андагы тәртип исең китәрлек иде. Студент әфәнделәрнең дәресләрдә, эш башкарганда үз-үзләрен тотышлары гаҗәеп иде, минем кебек үзгә-сәер кыяфәтле кунакның яннарында вакытлы-вакытсыз йөрүенә карау түгел, мин, килеп, күпме генә карап торсам да, күбесе яннарында торуымны да абайламый иде хәтта. Шулай дип уйлыйм, чөнки шул дәрәҗәдә күңел биреп эшлиләр иде. Әлбәттә, мин биредә күргәннәремнең барысы турында да сөйләп-аңлатып бетерә алмаячакмын, бары тик мине үтә гаҗәпкә калдырган җәһәтләрне искә алып китү белән чикләнәчәкмен. Биредә игътибарымны җәлеп иткән нәрсә шул булды: бактериология бүлеген карап йөргәндә, мөдир әфәнде пыяла витрина эчендәге бер җәсәдне күрсәтте дә болай диде:

– Менә бу җәсәдкә игътибар белән карагыз әле, тулысынча сакланган, бары тик уң беләгенең мускулы гына черегән. Утырып торышына да игътибар итегез әле: ничек утыра, ә?! Без моны моннан бер атна-ун көн элек каберлектә табып китерттек. Бу – безгә мәгълүм, моннан 44 ел элек вафат булган бер мәшһүр кешенең җәсәде. Вафат булганда, 60 яшендә иде. Варислары әлегә аның исеменең беленүен теләмиләр, югыйсә, без дә таный идек бу кешене.

– Исеме, кем булуы да мәгълүм, димәк, миңа әйтә алмассызмы?

Доктор Зиҗо җәнаплары болай дип җавап бирде:

– Безнең уку йортының кануны шундый: идарә тарафыннан берәр нәрсәнең сер булып сакланасына карар бирелгән булса, аны ачып салу тыела. Моның фән өчен әһәмияте бөтенләй булмаса да, әгәр университет идарәсе, варисларның таләбе буенча, яшертен тотарга карар кылган булса, аны әйтү, сөйләү мөмкин түгел.

– Мин – чит илдән килгән кунак кеше, мин дә сер итеп саклармын. Шәхсән миңа исемен әйтсәгез, бик канәгать калыр идем.

– Юк, карар катгый, исемне әйтә алмыйм. Гафу итегез! Әлбәттә, бу кешенең исеме Япония тарихына, һичшиксез, керәчәк.

Мин пыяла шкаф эчендәге бу җәсәдкә шаккатып карадым, бик игътибар белән кабат-кабат карадым. Һәр әгъзасын берәм-берәм күздән кичердем, һәркайсы, ничек бар, шулай тора иде. Доктор Зиҗо җәнапларына кабат мөрәҗәгать итеп, болай дидем:

– Мин – чит илдән килгән кунак кеше, бу затның исемен яшереп саклауда мин дә Сезгә кушылыйм. Ул исем биредәге җирле халыктан яшереп сакланырга тиеш, шулай да, әгәр бер каршылык булмаса, чит ил кешесе булуымны истә тотып, миңа әйтсәгез, мин бик канәгать калыр идем.

– Әйе, бернинди каршылык та юк анысы, фәкать бу уку йорты кануннарына каршы гына төшә, шул сәбәпле, әйтә алмыйм. Университет канунына каршы бара алмыйм, гафу итәрсез.

Токио. ХХ гасыр башы

Аннары соң болай дип тә өстәде:

– Университет канунына каршы бару минем кулымнан килми. Бары тик шуны гына әйтә алам: бу зат безнең Токиода мәшһүр һәм халык арасында танылган намуслы бер кеше иде, исәнендә тугрылыгы, ышанычлылыгы белән танылган иде һәм шул сыйфаты белән милләткә үрнәк булды. Бу юлы, ихтимал, фәнни тикшеренүләр өчен дә зур ярдәме тияр, җәсәде фәнгә файда китерер. Димәк, бу кеше вафатыннан соң да милләтенә хезмәт итә булып чыга.

Сүз арасындагы фикерләрем

Безнең мөселманнарда мондый черемәгән берәр җәсәд табылса, шунда ук үзенә берәр өстенлек бирелеп, кабере табыну урынына әйләнер, йөзләрчә-меңнәрчә кеше каберен карарга агылыр иде.

Христиан дөньясында мондый бер хәл булса, шунда ук илаһилеге танылыр иде. Моннан биш еллап элек, Русиянең Тамбов өязендә руслар бер җәсәднең череми калган бер кисәген тапканнар иде. Шулвакыт ниләр генә уйлап чыгармадылар, Николай II үзе шәхсән Петербургтан шул җирләргә кадәр барды. Дөньяны ышандырыр өчен миллионнар сарыф ителде. Ниһаять, христиан дөньясында бу кешенең илаһилеген танырга дигән карар бирелде.

Мәҗүси японнар исә алда сүз алып барылган җәсәдне, фәнни тикшеренү үткәрер өчен, университетка китергәннәр.

Университет китапханәсе

Мин башта китапханәнең уку залына кердем. Алты йөздән артык студент уку белән мәшгуль иде. Биредә бераз карап йөргәннән соң, китапханә хезмәткәреннән болай дип сорадым:

– Һәркөн бу кадәр кеше киләме?

– Бүген азрак, 600 тирәсе булыр. Кайбер көннәрне меңнән артып китә, 1400ләп кеше булганы да бар.

Аннары көнлек килүче һәм китүчеләр, хәбәрләр теркәлеп барыла торган дәфтәрне күрсәтте. Биредә унлап яшь кеше хезмәт күрсәтә иде. Болар да студент икән. Шул рәвешле, студентлар нәүбәт белән китапханәдә эшлиләр.

Бу уку залында игътибарымны җәлеп иткән нәрсәләр турында язып үтәчәкмен. Уку, эзләнү белән шөгыльләнүче әлеге кешеләрнең барысы да студент икән. Барысы да милли кием кигәннәр. Бары тик бер генә әфәнде рәсми кием кигән иде. Мин залда ярты сәгать чамасы йөрендем. Шул гыйлем эстәүче әфәнделәрнең ник берсе минем йөземә күтәрелеп карасын?! Һәммәсе дә укуына күңел биргән. Бары

тик рәсми киемле әфәнде генә миннән күзен алмый иде. Бу кеше, японнар кебек каратут йөзле булса да, японнарга һич охшамаган иде. Ул кешенең кем икәнен беләсем килеп, сорау бирдем:

– Бу әфәнде кем?

– Рус.

– Ә-ә?! Университетта руслар да бармы?

– Бер кеше бар, башка юк. Һәр милләттән берничә кеше бар. Кытайлар бик күп, берничә йөз кеше булыр. Аннары америкалылар да шактый. Әйткәнемчә, күп милләтләрдән дә берничә кеше бар, тик руслардан берәү генә. ИншәАллаһ, моннан соң төрек һәм татар милләтеннән дә килүчеләр булыр, – дип елмайды.

Тагын шул бар: университет студентлары бар да милли кием кигән, аяк киемнәрен ишек төбендә калдырганнар, яланаякларына артсыз башмак кигәннәр. Шул аңлашыла: мәгариф, белем бирү өчен кием алыштыруның һич кирәге юк икән.

Бераздан китапханә хезмәткәре алдыбызга чыкты да, без китаплар торган якка юнәлдек. Хезмәткәр болай диде:

– Китапханәбездә кырык сигез меңнән артыграк китап бар. Башта япон телендә һәм японнар тарафыннан язылган китапларны карарбыз. Болар да ике өлешкә бүленә: иске китаплар һәм яңа китаплар.

Тәртибе белән күрсәтә барды. Аннары инглиз телендәге китапларны карадык. Язучылары инглиз булган китапларны, инглизчәдән французчага, немецчәгә, японча тәрҗемә ителгән китапларны аерым-аерым күрсәтте.

Китапханәнең ахырына килеп җиттек һәм мин болай дидем:

– Мин бик канәгать калдым, тик бер нәрсәдән күңелем төште: төрле милләтләрнеке булган бу кадәр китап бар, ләкин дөньяда киң кабул ителгән гарәп телендә генә бер китап та юк, ахрысы.

– Ул да бар, – диде дә бер гарәп теле сүзлеге алып килде. – Бу китапны безнең китапханәбезгә китерелгәннән бирле берәү дә алып карамаган. Сез, алып, берничә юлын гына булса да укыгызчы?

Китапны кулыма алып, очраклы рәвештә генә ачылган битендә язылган «Иннәмә’л-мәр’ү би-асгариби» хәдисенә күзем төште. Укыдым, тәрҗемә иттем. Китапханә хезмәткәре: «Зинһар, япмагыз ул битне!» – диде.

Шунда безгә ияреп йөргән яшь әфәндегә нидер әйтте, ул йөгереп китеп барды. Бераздан язу карасы белән каләм китерде. Китапханә хезмәткәре китапның бер читенә япон язуы белән нидер язды, аннан соң миңа:

– Менә шунда гарәп язуы белән имзагызны куегызчы, зинһар, – диде.

Мин, имзамны куеп, шул көнне һәм елны да теркәп куйдым. Аннары хезмәткәргә сорау бирдем:

– Китапның читенә Сез нәрсә яздыгыз?

– Сез бу китаптан укыган хәдиснең мәгънәсен яздым һәм Сезнең исемегезне күрсәтеп, бирегә килгән көнне укып, шул рәвешле тәрҗемә итүегезне, астагы имзаның Сезнеке булуын яздым. Безнең Япония тарихы өчен кыйммәтле ядкәр булачак бу. Сезнең бу уку йортына килүегезне һәм карап йөргән чакта әйткән фикерләрегезне, милләтебез турында сөйләгән сүзләрегезне университет тарихына теркәячәкбез.

Аннары бер дәфтәр китерделәр. Ул дәфтәргә дә имзамны куюымны сорадылар һәм мин куйдым.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Исфәндияр Ишгай шигырьләре



Журнал укучыларына Исфәндияр Ишгайның Төркиядә 1956 елда дөнья күргән җыентыгыннан аерым шигырьләрен тәкъдим итәбез. Урын тар булу сәбәпле, нигездә, кечерәк күләмле шигырьләр алынды. «Җәһәннәмнән котылганнар» поэмасы, күләме зур булу (12 бит) аркасында, хәзергә читтә калдырылды. Алдарак әйтелгәнчә, кайбер әсәрләр бераз кыскартыбрак бирелә. Латинча хәрефләр белән язылган бу җыентыктагы төрекчә аерым сүзләр, элементлар авторның төп язу телендәгечә тәкъдим ителде.

Кайбер хосусый үзгәреш-төзәтмәләрне исәпкә алмаганда, гомумән, оригиналга тугрылык сакланды. Иң ахырда, гәрчә алар 1956 елгы китапта булмасалар да, Исфәндияр Ишгайның 1964 елда язылган «Чын дус» шигырен һәм аңа җавап рәвешендә Минһаҗ Исмәгыйли иҗат иткән «Дустым шагыйрь Исфәндияргә» парчасын бирүне дә кирәк дип таптык. Чөнки аларда бу ике затның үзара мөнәсәбәтләре, язмышлары, әхлакый һәм инсани сыйфатлары, шигъри сүз турындагы уй-кичерешләре билгеле бер чагылыш тапкан.

Хатыйп Миңнегулов

Ватан сагышы (9 б.)

Үткән көннәремне кызганып,
Йөрәккәем тибә сызланып:
«Читтә күмгән гомереңнән файда –
Милләтеңә хөррият кайда?»
Һәркөн шулай уйга таламсың?
Таң атса да, йөрәк янамсың?
Хатирәләр сабый чагымның
Кочкан аулым, өркеп каласын.
Хатирәләр ата-анамның,
Балаларым, бәгърем хатынымның,
Аглап *(елап. –* ***Х.М.****)* озатканын сугышка
Арасында әсир халкымның!
Хәтерләтеп анда аларның
Яшәүләрен куян күк посып,
Кара икмәккә дә туймыйча,
Эшләүләрен сыкрап, теш кысып…
Җитәр, хәсрәт йотма, талпынма!
Үз-үзеңне йолкып сагынма.
Өметле бул, эшлә, ялынма!
Көрәш юлың ачык, абынма!..

Нисан – апрель, 1948.
Ной-Ульм

Дулкынланган яшьлек диңгезендә (26 б.)

Аңлап җитсәң ярны, керсез ярат!
Никах аша бәйләп соңыннан.
Тату яшә, нәслең үрчет, тарат,
Аерылмый милли юлыңнан.

Исфәндияр Ишгай

«Мәче узмады» *(өзек. –* ***Х.М.****)* (29-30 б.)

…Төштә алдансам, өндә алданмадым,
Шөкер, гомрем эзсез тузмады…
Хатын уңды, алты бала үстердек,
Арабыздан мәче узмады.
Тугры булдык, гайбәт кабартмадык,
Тату тордык, эшне яраттык;
Күркәм холык, белем азыкларын
Мәктәп гөлләренә тараттык.
Ата-анага, ятим, карт-корыга
Хөрмәт аша гына карадык.
Мохтаҗларга ярдәм кызганмадык,
Яхшылыкны туган санадык.
Явызлыкны кудык, тазалыкны
Хуҗа иттек һәрбер урынга.
Нәфрәтләндек карак, уйнашчыдан
Микроб ташучыдан буенга *(? –* ***Х.М.****)*.

07.13.09. 1944. Берлин

Көтелмәгән аһлар (27 б.)

Өнемдә дә, төшемдә дә,
Гаиләм, бик сагындырдың.
Күкрәгемдә аерылышуның
Хәсрәт утын кабындырдың.
Нишләсәм дә, сүнмәс ул ут…
Күз алдымнан һич китмисез,
Кулым сузып исәнләшәм
Дисәм – килеп ник җитмисез?
Күрештер, Тәңрем, аларга
Читтә йөртеп абындырмый.
Бу аерылу үлемеңнән дә
Ачы булып бәгърем тырный.

12.05.1944. Берлин

Күмелгән калебнең эзе (31-32 б.)

Бик көттем, килмәде. Үпкәләп, соңыннан
Хат салдым. Аяныч, ул барып,
Ул барып җитмәгән.

Актарылып каегы чал Идел суыннан
Чыгалмый, чәчәктәй саф гомрен,
Саф гомрен чикләгән...

Әй, гүзәл күбәләк, күңелемне киртәләп,
Мин яккан учакны әйләнеп,
Әйләнеп син очып.

Аерылгач, көтмәгән бер чакта иркәләп,
Еламый нишлим ак яулыгың,
Ак яулыгың кочып?

Гыйшкымнан ядгарен бизәкләп
кабереңә
Язсам, сакланмас, яшьләрем дә,
Яшьләрем дә кибәр.

Синдәй үк яр сөеп, тик синең кадреңә
Өйләнеп бәхетле көн итсәм,
Көн итсәм, ул әйтер.

18.03.1948. Neu-Ulm

Күзләрдән яшеренгән чынбарлыклар (50 б.)

Туган илдә сине, күңел сазым,
Уйнатмасам, куркып таш капчыктан,
Әрәм үтсә анда гомер язым,
Котылалмый михнәт, зар-ачлыктан.
Хәзер читтә чиртеп, үрләп чорна,
Бәйсезлеккә өндәп үз халкымны.
Сүндерергә кызыл ут-ялкынны
Кама бүрек киеп шүрләп торма!
Күтәр башың, яңгырасын таушың,
Хөррият булсын мәңге юлдашың!

Дөнья – шул дөнья (65 б.)

Көз килгәндә – сары яфраклар,
Кыш килгәндә – карлар-бураннар,
Яз килгәндә – җимнәр-орлыклар,
Җәй килгәндә – комнар-тузаннар.
Ташып чаба җилләр һаман да,
Урамнарда вакыт уздырып,
Бомбаланган, янган йортлар һәм
Кешеләр көлен казып, туздырып...
Тынар җилләр, туктар тузаннар,
Өем булып җиргә ятарлар;
Эчләреннән таза орлыклар,
Кабат борнап, чәчәк атарлар.

5.9.1947. Ной-Ульм



BOLŞEVİZM TAR-MAR EDİLECEK

Ol — çir, zindan, açlık,
Kızıl isyanlarnıng
Sürmün başlap ceygen çağından;
Baskan yeri — sazlık,
Sansız insanlarnıng
Göz yaşları blen kanından.

«Җәһәннәмнән котылганнар» җыентыгыннан. Анкара, 1956

Чын дус

Синдә күреп батыр милләтчене,
囊Эштә тугрылыклы илдәшне,
Сөенәм мин, Минһаҗ, чит илдә дә
Тапканыма дусны, тиңдәшне.

Беләсеңдер, сугыш барган чакта
Берлинда без башлап таныштык.
Кайгыларны бүлешеп, күңелләргә
Өмет утын бергә кабыздык.

...Хәтерлимсең, кулны артка куеп,
Ульм *(Германиядәге Ной-Ульм шәһәре. – **Х.М.**)* болынында йөргәнне,
Кайгы-хәсрәт йотып, лагерьларда
Качып-посып гомер сөргәнне?..

...Юлымда күп булды танышларым:
Кайберләре җырак баралмый
Туктадылар, аннан хат та язмый,
Ышанычлы дус та саналмый.

Ә син үзгәртмәдең дуслыгыңны,
Дөнья эшенә күмелеп калмадың.
Кичектерми хәл сорашып тордың,
Хатларыма хатлар ялгадың.

Мондый дусны ничек онытырга?
Искә төшереп, кайчак уемда
Җөрим гүя синең белән бергә
Сөйләшкәләп Дунай буенда.

Үлгәнче без, уйлыйм, дус калырбыз,
Исән булсак, хатлар язышырбыз,
Бер-беребездән фикер алышырбыз,
Җыракларга китсәк, табышырбыз.

Шушы шигъырем сиңа – ядкәр итеп,
Дуслык саклап килгәнең өчен,
Хаклык даулап көрәшкәнең өчен,
Яшәтергә милләтем көчен.

Синдә күреп батыр милләтчене,
Эштә тугрылыклы илдәшне,
Сөенәм мин, Минһаҗ, чит илдә дә
Тапканыма дусны, диндәшне.

1964

«Җырла, дустым Ишгай, матур итеп,
Җырла кычкырып татар җырларын.
Мактап Сарай, Кашлык шәһәрләрен,
Ак Идел һәм Җаек буйларын.

Җырла, дустым
(Дустым шагыйрь Исфәндиярга)

Җырла, дустым Ишгай, матур итеп,
Җырла кычкырып татар җырларын.
Мактап Сарай, Кашлык шәһәрләрен,
Ак Идел һәм Җаек буйларын.

Ишетсеннәр урман, киң яланнар,
Ишетсеннәр җырак далалар.
Тыңласыннар матур тавышыңны
Илебездәге авыл-калалар.

Яңгырап торсын Себер далалары,
Дулкынлансын Байкал күлләре.
Ишетсеннәр дәртле җырларыңны
Казакъстан сахра-чүлләре.

Син җырлыйсың хөр, иркенлек чорын,
Син әйдисең алга атларга,
Чакырасың мескен татарларны
Коллык богауларын ташларга.

Шулай кирәк, дустым Исфәндияр,
Курыкмый җырла ирек җырларын.
Мактап илнең матур җегетләрен,
Эш сөючән матур кызларын.

Минһаҗ Исмәгыйли

*Шигырьләрне журналга филология фәннәре докторы, КФУ профессоры **Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Мәскәүгә – Миргазиян абыйга

Ләбиб Лерон

Миргазиян Юныс

Һәр яңа ел башында архивымны барлап алам: көндәлекләрне тәртипкә китерәм, хатларны бер тирәгә туплыйм, фоторәсемнәрне аерып куям... 2010 елда, шул эшләр белән мәшгуль булып утырганда, бер кечкенә генә блокнотка һәм андагы язуларга күзем төште. Мин анда 1980 нче еллар уртасында Нури ага Арсланов һәм Барлас абый Камалов белән – «Татарстан яшьләре», шулай ук Миргазиян абый Юныс белән «Яшь ленинчы» газеталары редакцияләрендә очрашуыбыз турында теркәп куйганмын. Шул блокноттагы язулар тәэсирендә булса кирәк, Миргазиян абый Юныска хат язарга булдым һәм, озын-озакка сузмыйча, шушындый эчтәлектәге хатымны Мәскәүгә – хөрмәтле язучыбызга юлладым:

«Миргазиян абый, исәнмесез!

Яңа ел бәйрәме белән чын күңелемнән котлыйм үзегезне. Сау-сәламәт вә озын гомерле булуыгызны телим. Бар хыял-теләкләрегез тормышка ашсын!

Борчыганым өчен алдан ук гафу үтенәм. Күптәннән инде Сезгә берничә китабымны җибәрәсем килә иде. Җай-вакыт тапсагыз, бәлкем, күз салып алырсыз.

Бу арада архивым белән мәш килеп утыра идем. Бер блокнотта Сезнең белән очрашу хакында язылган язмама тап булдым. 1984 елның 24 маенда Сезнең белән «Яшь ленинчы» редакциясе очрашу үткәргән иде. Шул чакта Сезнең кайбер фикер-сүзләрегезне әлеге блокнотыма төшереп барганмын. Менә кайберләре:

– Яңа исем – саф чәчәк күргән шикелле ул...

– Балаларны дәүләт башына куйсаң, гел гаделлек булыр иде...

– Ат яратам. Минем өй ат белән тулы. Рәсемнәре белән, дип әйтүем...

– Адаптация. Бер атна татарча сөйли алмый азапланам... һ.б., һ.б...

Миргазиян абый!

Хәл-әхвәлләрегез ничек? Мин Сезне бик хөрмәт итәм. «Занзибар зәңгәр болытлар артында» дигән китабыгызны мәктәп елларында бик яратып укыган идем. Әле дә хәтеремдә. «Тозлы җил»не соңыннанрак укыдым. Шулай ук бик яраттым. Башка китапларыгыз да күңелемә бик хуш килде. Рәхмәт Сезгә!

Сүзем озынгарак китте шикелле. Борчыганым өчен янә бер кат гафу үтенәм. Ихтирам белән, Ләбиб энекәшегез. 5 гыйнвар, 2010 сәнә. Казан.

P.S. Сезгә Язучылар кенәгәсендәге телефон номерыгыз буенча шылтыраткан идем, эләгеп булмады. Ләбиб».

Озак та үтмәде, Миргазиян абыйдан җавап хаты килеп төште:

«Хөрмәтле Ләбиб энем!

Сәләм (авторның орфографиясе сакланды. – ***Л.Л.***) *Сиңа ак теләкләр, иҗат уңышлыклары. Гаиләңә, дусларыңа һәм, ...тан кала, барлык каләм кыймылдатучыларга мин, урысча фикерләп, татарча яза торган үги язучы, иҗат ләззәтләре, халкыма тел ачкычлары теләп калам.*

Рәхмәт яусын Синләргә хат, җыентыкларың, «Мәйдан» өчен. Хат алышу бетте дип торганда, Син сүнә башлаган өметләремә җан өрдең.

Энем Вахит Сине ярата иде. Безнең бит Актанышта бергә йөргәнебез дә бар. Кич утырырга чакыргач, бүлмәңә керә алмавыма үкенәм. Ул көнне мин артык комсызланып күзәтеп йөрегәнлектән, үлеп арыган идем.

Иҗатыңа килгәндә...

«Җүләр малайның әтисе». Режиссер булсам, мин аны, һичшиксез, куяр идем. Әмма... Бу өлкәдә син Туфаннан да, Зөлфәт Хәкимнән дә ераграк төкерә алмагансың. Аларның өстенлеге – З.Х. дә, Т.М. да танылган драматурглар, ә сиңа танылыр өчен вакыт кирәк. Вакыт ул, дускаем, гаҗәп оста төп башына утыртып куя торган нәрсә.

Проза өлкәсендә дә шул чамадарак. Дөрес, күпләрнең, дистәләгән күпләрнең синдәге осталык төшләренә дә керми, әмма Мөхәммәт Мәһдиев атлы бер кеше Синнән остарак яза. Рәнҗемә.

Поэзия калды. Бу өлкәдә... Бу өлкәдә, әшнәкәем, Син татар шагыйрьләренең барысыннан да ераграк төкерә аласың шикелле. Бигрәк тә юмор өлкәсендә. Мәсәлән, «...Безнең ил ул – алга карап, артка таба барган ил» – бу фикерне Петр Чаадаевтан урлаган очракта да Син кыскарак, үтемлерәк, әрнеткечрәк итеп әйтә алгансың.

Мин фәкыйрь асылынасым килгән чакларда Гамил Афзалның җыентыгын алып өнемә кереп бөкләнәм дә яшисе килә башлаганчы укыйм. Дөрес, Гамилдә масштаб зурырак шикелле, әмма синең «Телен йота язган татарым...», «Ник дәшмәскә? Дәшәлмибез! Без бит инде күптән яшәмибез...», «Дәрес» шигырен мин, татарның гимны итеп, Дәүләт Советыннан раслатыр идем.

Әйттем бит, вакыт тиз үтә, дип. Ашыгыр, шушы юнәлештә көне-төне эшләр идем мин, шундый шигырьләр тудыра алсам.

Безнең мирас №6 июнь 2020

Кызганычка каршы... безнең яшь композиторларыбыз ярым урысча, чирек европейчә, чирек кытайча һәм күпмедер дәрәҗәдә мукшыча язалар (чыгаралар). Укыганда мин Синең шигырьләреңнең көйләрен ишетеп торам. Аларны мөнәҗәт әйткән шикелле итеп сәхнәдән уку чиктән тыш

«

P.P.S. «Рукописи не горят», – дигән Михаил Булгаков. Учак помойкадан мәрхәмәтлерәк икән!

отышлы булыр иде шикелле. Китап уку бетеп килә. Бәлки, без, татарларны клубларга биклəп, әсәрләребезне сәхнәдән укырга тиештербез. (Бу урында Миргазиян абый: «Битнең артын кара!» – дип, ассызыклап, язып куйган. – ***Л.Л.***)

Аяз мәрхүм еш кына яшь язучыларга начар (скепсис) тәэсир ясый иде. Әгәр Марсель Галиев белән бергә Испаниядә мин йөрегән булсам, Марсельнең «Догалы еллары» бөтенләй башкача яңгыраган, күргәннәре дә бөтенләй икенче төрле булыр иде шикелле. Марсельнең дегустация процессын сүрәтләвен укыганда мин: «Нигә бу талант иясе Испанияне Гыйләҗевчә күрә?» – дип, йодрыкларымны кысып йомарладым.

Менә хәзер Синең белән Италияне, Испанияне, Яңа Зеландияне һәм... һәм... һәм бергәләп карап йөрисем килә.

(Ике кешедән) кала, барлык каләм колларына минем фатихамны тапшыр. М.Юныс. 17.01.10. Мәскәү. Лачын тавы.

P.S. Мәскәүгә килсәң, кермичә китмә, яме».

Миргазиян абый, әлеге хат белән бергә, кайчандыр «Идел»дә (1997 елда булса кирәк) басылган «Безнең өй өянкеләр астында иде» хикәясен дә, ксерокстан чыгарып, җибәргән һәм шул хикәя басылган кәгазьнең артына карандаш белән мондый сүзләр язган иде:

«Мин дә шапырынып алыйм әле!

Йөзгән чакта мин һәр сәяхәттә күргәннәремне, вак шакмаклы дәфтәрләргә язып, Вахиткә җибәрә идем. Шуларның берсеннән ул шушы хикәямне күчереп алган да «Совет әдәбияты» журналы редакторы Газиз Мөхәмматшингә җибәргән.

Ә калганнары?

Вахит эшкә барган җиреннән, квартирасына кайтмыйча, яшь хатыны Алия янында калды. Аның киемнәрен алырга баргач, энемнең беренче хатыны Зәйнәбтән шул дәфтәрләрне һәм Вахитның архивын сорадым.

– Они все в помойке, – булды җавабы.

Госсовет каләм тибрәтүче татарга марҗага һәм татарча укый белмәгән татар марҗасына өйләнүнең тыелуы турында закон чыгарырга тиештер, бәлки?

P.S. Зәйнәб мәрхүмә – ИСААның төрек бүлегендә төрек телен, ике ел Дәмәшкъта гарәп телен өйрәнеп, китап нәшриятында Жириновский белән берничә ел бер бүлмәдә эшләгән хатын. Шуңа өстәп, ул минем хәләл җефетемнең бертуган апасы да иде. Менә нәрсәләр бар бу дөньяда!

P.P.S. «Рукописи не горят», – дигән Михаил Булгаков. Учак помойкадан мәрхәмәтлерәк икән!» ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Әдипнең тәүге әсәре

Безнең өй өянкеләр астында иде...

Хикәя

Миргазиян Юныс



Н.Хаҗиәхмәт рәсеме

Аз гына вакытлы, һич көтелмәгән кайбер очрашулар да бик озакка хәтергә кереп кала икән. Ике генә тапкыр күргән бер карчыкны гомергә оныта алмам шикелле.

...Пароходыбыз Генуя портында торган чакта, без Италиянең халык герое – Рязань тимерчесе Федор Полетаевның каберенә чәчәкләр куярга барган идек. Үзебез теләп түгел, мәҗбүри, пропаганда өчен куйдырталар иде чәчәкләрне. Урыс солдатының батырлыгын дөньяга таратыр өчен. Телисеңме-юкмы барырга кирәк иде Генуя зиратына. Зират тау битендә. Өстә таулар. Алар Швейцариягә барып җиткәнче тезелеп киткәннәр. Зиратны төньяктан искән салкын җилләрдән саклап торучы тау сырты Канто Лупа — Бүре җыры дип атала. Галимнәр ачыклаплар әле татарлар белән борынгы римлыларның totemнары[1] уртак булуын. Кем башлап изгеләштергән бүрене: безме, борынгы римлыларны?

Аста диңгез. Лигур диңгезен көньяктан Корсика һәм Сардиния атаулары каплап торганлыктан, монда давыл сирәк була. Генуяның атаклы Стальено зиратына керсәң, тәэсирләнми чыга алмыйсың. Зираттагы мәрмәр һәйкәлләр дә кеше кайгысына кушылып елыйлар, вакланмаска, адәм баласынча яшәргә өндиләр шикелле.

– Нигә кирәк инде мондый кыйммәтле матурлык? Үлгән кешегә нинди кабер дә барыбер түгелмени? – ди кочегар Трак.

[1] Totem – борынгы дини ышанулар буенча: билгеле бер төркем кешеләр белән туганлыкта булган һәм шул кешеләр табына торган хайван, үсемлек, әйбер яки табигать күренеше (мәсәлән, эт, бүре, ат, яшен).

Штурман Маркин аның фикере белән килешми:

– Надан кеше син, Трак. Кабер бизәү — кеше заты үлгәч тә кадерен югалтмый дигән сүз ул. Гуманизм кагыйдәсе җир йөзендә безгә кадәр яшәгән кешеләрне дә хөрмәтләргә куша. Адәм баласы исән чакта гына түгел, дөнья куйгач та бәясен югалтмый дигән сүз бу.

«Поэтан» батырның каберендә яңа чәчәкләр бер дә бетеп тормый. Генуя портында якорь ташлаган һәр судно экипажы диярлек бу кабергә чәчәкләр салып китә. Советлар Союзыннан килеп Италия азатлыгы өчен гомерен биргән бу партизанга Генуя халкы да ихтирам күрсәтә. Хәтта ваемсыз турист халкыннан да чәчәкләр булгалый.

Кабергә чәчәкләр куйгач, бераз сүзсез калып, тын гына басып тордык. Кая гына ташламый адәм баласын язмыш дигәнең... Кешенең теләк-хыяллары бер якта кала, ә вакыйгалар аны икенче якка очыртып алып китә. Язмыш, дибез... Ә язмышны кем хәрәкәткә китерә? Хәрәкәткә китерүче көч каян туа? Җавап эзләп, без Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәбез.

Каберләр арасында йөргәндә, сүзнең көче юкка чыга. Гади сүзгә сыймаслык тынгысыз тойгылар сырыша күңелгә. Шуңа күрәдер, чыгар юлга борылгач та, без бик озак сүзсез атлыйбыз.

– Галереяны урап чыкмыйбызмы? – ди Маркин.

– Андагы таштан ясалган кешеләрне күргәнем бар минем, кайтыйк инде, – ди кочегар Трак.

– Мәҗүси[2] син, Трак, кыргый кеше, – диде штурман Маркин, баруыннан туктап. – Мондагы һәйкәлләрне күрер өчен культуралы затлар, акчаларын, вакытларын кызганмыйча, әллә нинди ерак илләрдән киләләр. Син үзеңнең каралыгыңа ябышып ятасың.

Өчәүләп галерея буйлап һәйкәлләр арасыннан барабыз. Менә чалгы күтәргән скелет – Үлем яшь кызны алырга килгән. Кызның күзләрендә – курку, ә күңелендә – яшәү өмете, тереклекнең мәңгелегенә ышану. Максим Горький «Кыз һәм үлем» поэмасын шушы һәйкәл тәэсирендә язган, диләр.

Кочегар Трак һәйкәлләргә карамыйча гына бара иде, җилкәнле көймәгә баскан бер малай скульптурасы янына җиткәч, туктап калды:

– Габдрахман Бәкерович, укыгыз әле, нәрсә язылган анда?

Һәйкәлнең постаментына Торквато Тассоның атаклы поэмасыннан ике юл шигырь язылган иде.

«Кешенең гомере давыллы тормыш диңгезендә бер катрә[3] генә.

Киләчәкнең иминлек китерүенә ышаныч кына саклап килә аны...» – дип тәрҗемә итәм мин бу язуны.

– Мин аны диңгезгә батып үлгән малайга куелган һәйкәлдер дип уйлаган идем, – ди Трак.

Бу егет аллегория белән исәпләшеп вакланмый, кул белән тотып карарлык нәрсәне генә сизә, аңлый ала. Трак галерея эченнән гамьсез генә бара. Ул тагын бер һәйкәл янына туктады. Бусы башкалардан үзенең натурализмга әйләнгән гапгади чынлыгы белән аерылып тора иде. Һәйкәлнең тарихы болай икән: бер карчык гомер буена, Генуяның Гарбо исемле ярлылар кварталында вак-төяк нәрсә сатып, үзенә һәйкәл салдыру өчен акча җыйган. Ләкин җыйган акчасы барыбер монументка җитмәгән. Калган өлешен Рим папасы түләгән.

---

[2] Мәҗүсилек – айга, кояшка, утка, потка һ.б. табынучанлык.

[3] Катрә – тамчы.

Шул карчык һәйкәленә карап торганда, безнең янга өлкән яшьләрдәге бер хатын килеп туктады да, кулын селти-селти, бездән нәрсәдер сорый башлады. Аның артыннан шулай ук нигәдер бик борчылган яшь кенә бер ханым да килеп кушылды.

– Итальянча сөйләшә беләсезме? – дип сорыйм мин яшь хатыннан.

– Әйе... – дигәч, яшь хатын елап ук җибәрде.

– Ни булды сезгә?

– Улыбызны югалттык.

Мин аның сүзләрен иптәшләремә тәрҗемә иттем.

– Әйдәгез, эзлибез, – диде Маркин.

Югалган малайның исемен сорап белгәч, шушы һәйкәл янында очрашырга сүз куештык та, өчебез өч якка таралдык.

– Пьетро-о-о! – дип кычкыра яшь хатын. Сүзенең азагында тавышы үксегән кебек ишетелә. Тыныч зиратта бу тавыш бигрәк тә аяусыз, каты яңгырый. Тик хатынның эндәшүенә каршы беркем җавап бирми. Каберләр тын. Тирән тынлык чорнап алган зиратны. Кайдадыр чикерткә чырылдаган сыман тавыш ишетелеп китә. Ләкин, нигәдер, бу тавыш тынычлыкны бозмый. Киресенчә, бөҗәк тавышы зиратны табигыйләндерә, мәңгелеккә бәйли. Йоклыйлар астагылар. Ыгы-зыгы өстә, җирдә калган. Мал да, дан-шөһрәт тә, өстенлек тә кирәкми аларга. Йоклыйлар. Тыныч. Мәңгелек куенында. Аларның йокыларын яшел кипарислар, мәрмәр ташлар саклый.

> **«Кабергә чәчәкләр куйгач, бераз сүзсез калып, тын гына басып тордык. Кая гына ташламый адәм баласын язмыш дигәнең...**

Рисорджименто хәрәкәтенең юлбашчысы Мадзини мавзолеена менә торган юлга чыккач, нарат чикләвекләре җыеп йөрүче бер малайны очраттым.

– Пьетро, – дим аңа. Ул минем якка борылып карый.

– Синең исемең Пьетромы? – дип сорыйм аңардан итальянча.

– Әйе. Сез мине каян беләсез?

– Әйдә, әниең янына. Ул сине эзләп йөри.

Малай карыша. Кулыннан тотып алып бара башлагач, еларга ук тотынды. Иелеп кулны тешләргә тели. Мин аны күтәрәм дә теге крендель сатучы карчык һәйкәле янына таба атлыйм.

Галерея янында безне карчык куып җитте.

– Пьетро! – диде карчык, кочагын җәеп. Карчыкны күргәч, малай җиргә сикереп төште дә аның итәгенә барып ябышты.

– Нәни разбойник, – дим карчыкка малай турында. Ул дәшми.

– Итальянча сөйләшә беләсезме? – дип аптырап сорыйм карчыктан. Әбисе өчен малай җавап бирә:

– Белми. Ул грекча гына сөйләшә белә.

Карчык малайдан нәрсәдер сорый.

– Ә сез кем соң? – ди Пьетро, карчыкның соравын тәрҗемә итеп.

– Мин – диңгезче. Советлар Союзыннан.

– Руски? – ди карчык, кинәт кенә. – Я руски понимайт мала-мала.

– Откуда вы знаете по-русски?

– Моя из Рәчәй, давна Рәчәй.

Таныш акцент яшен тизлеге белән татар авылы картларының русча сөйләшүләрен хәтерләтеп җибәрде.



«Чолым» корабының өлкән офицерлары: (уңнан) капитан Е.М.Дегерменджи (татарча Тедечтәпсе), капитанның беренче ярдәмчесе М.З.Юнысов, өлкән механик В.П.Путилин. Генуя порты. 1962 ел. («Безнең өй өянкеләр астында иде...» сюжетына юлыккан рейс).

– Әби, сез татар түгелме?

– Татар... И Ходаем, әллә саташам инде!

Карчык бөтенләй югалып калды. Ни әйтергә, нәрсә эшләргә белми, хәлсез куллары белән күлмәк итәген сыпыра.

– И Ходаем... и Ходаем...

– Сез ничек монда килеп эләктегез соң?

– Язмыш, улым, язмыш... Әйтмә инде, и Ходаем...

Карчыкның күзләреннән ике бөртек яшь тәгәрәп чыкты да җыерчык буйлап битенә таралды. Пьетро аптырап калды. Аңлашылмый торган телдә сөйләшүебез ошамады аңа – әбисен читкә сөйри башлады.

– Әйтмә инде, улым, әйтмә... Мин Карамалыныкы. Самар губернасыннан. – Карчык учы белән тамак төбен уа. Күзләреннән һаман мөлдерәп яшь ага.

– Хәзерге Татарстандагы Карамалы булса, мин аны беләм. Безнең Караярдан егерме чакрым гына. Мин, әби, Баулы районыннан.

– Без Бөгелмә өязендә тора идек. И Ходаем... и Раббым...

Шулай сөйләшеп торганда, Маркин белән Трак әйләнеп кайтты.

– Югалган малай шушы шпанамыни? – ди Трак, Пьетрога күрсәтеп.

– Әйе, шушы, – мин әйтәм. – Малайның әбисе минем якташ булып чыкты... Әби, сау булыгыз. Без вахтага ашыгабыз. Безнең пароход Лантерна маягы янында гына тора. Эфиопия причалы. Вакытыгыз булса, килеп чыгыгыз.

– Үзегез кунакка килегез, улым. Кызымның торуы Сестри дигән җирдә. Грамши урамы, ундүртенче йорт, траттория[4] янында.

Саубуллашып, йөз метр чамасы киткән идек, карчык, кулын болгый-болгый, арттан килә башлады.

[4] Траттория – кайбер Көнбатыш Аурупа илләрендә ресторан.

– Улым, корабыгызда туган җир туфрагы юкмы? Иснәп кенә тотар идем.

Пароходта туфрак булмый инде ул. Кайдан аласың аны? Юк, тукта әле, пожар сүндерү өчен тота торган ком искә төште:

– Табарбыз, әби. Килегез. Кирәк кадәр алып китәрсез.

Икенче көнне айлык отчетны төзеп утыра идем, телефон шылтырады.

– Вахтадагы штурман тыңлый.

«Таныш акцент яшен тизлеге белән татар авылы картларының русча сөйләшүләрен хәтерләтеп җибәрде.
– Әби, сез татар түгелме?
– Татар... И Ходаем, әллә саташам инде!

– Габдрахман Бәкерович, ниндидер карчык пароходка керергә тели. Бераз русча да сөйләшә белә кебек үзе. Ләкин нәрсә сораганын аңлап булмый.

– Минем каютага озатыгыз.

Буфетчы хатынга шылтыратып, чәй китерергә кушып кына өлгергән идем, ишектән кечкенә карчык килеп керде.

– Түрдән узыгыз, әби.

– Рәхмәт, улым. Шушында гына утырып дога кылып алыйм әле. – Карчык дога кылып алды. – Бүлмәң бик әйбәт икән. Кыйммәтле җиһазлар. Син башлыкмыни, улым?

– Шулайрак.

Яшь чагында бик чибәр булгандыр бу карчык. Әле дә хәрәкәте салмак, гәүдәсе җиңел һәм килешле. Коңгырт-кара күзләрендә, элекке шаян очкыннар урынында, аналарча кайгыртучан сөйкемлелек.

– Пароходта туган ил туфрагы юк икән, әби. Икенче килүдә алып килермен. Без монда килгәләп йөрибез.

– Хәерле булсын инде. Саклап кына тотармын дигән идем. Бүген төне буе Карамалымны күреп саташтым.

– Авылыгызны һаман онытмагансыз икән.

– Оныта ди. Картайган саен ныграк җирсендерә. Безнең өй өянкеләр астында иде. Тәрәзәдән карасаң, Ык тугаенда ап-ак булып шомырт чәчкә атар иде... Анда керне һаман бәләкләп чайкыйлармы әле?

– Белмим. Ял вакытларында бер дә күргәнем булмады. Мин бит Одессада яшим, әби. Туган авылыма инде өч ел кайтканым юк.

– Бәләк тавышлары су буеннан моңлы булып яңгырый иде. Язын Сабан туена, җыенга, көзен каз өмәсенә җыела идек... Өй бүрәнәләрен эчке яктан кырып юа идек. Гәрәбә шикелле сап-сары булып китә иде... И Ходаем, ничек үлмәдем икән бу кадәр сагынуымнан!..

Буфетчы хатын каютага чәй кертте.

– Ашап кына эчегез, әби. Бу икмәк, бәлки, Ык буенда, безнең туган җиребездә үскәндер.

Карчык ашавыннан шып туктады. Учы белән тамак астын уа. Иреннәре дерелди. Нидер әйтергә тели, ләкин авызыннан сүзе чыкмый.

– Әби, ник ашамыйсыз?

– Рәхмәт, улым... Бу сыныкны төйним әле...

– Ничек бу илгә килеп чыктыгыз соң, әби?

– Әйтмә инде, улым... Ходай Тәгалә шулай язгандыр инде... Ирем сатучы иде. Карамалыда кибет тота идек. Рәвлүция чыккач, Кырымга киттек. Анда иремнең

кардәшләре бар иде. Кырымга бәлшәвикләр килә дип ишеткәч, Истанбулга күчеп килдек. Анда да танышларыбыз бар иде. Төрек җирендә сәүдәләр уңмады. Грециягә килдек. Грециядә ачлы-туклы гына яши идек, бәхетсезгә җил каршы, дигәндәй, сугыштан соң ирем үлеп китте. Ике кызым, бер улым белән тол калдым.

Олы кызым әмерек кешесенә кияүгә чыкты. Башта бай, тату яшибез дип язган хаты килгән иде, өч ел инде хәбәре юк. Кечесе монда, Генуяда. Ире диңгездә йөзә. Елына бер-ике мәртәбә кайтып күренгәли: әллә бар, әллә юк... Карамалымны сагынам... Үләм инде, улым... Җирсенәм.

Карчыкның күзләреннән чыккан яшь бөртекләре җыерчык буйлап битенә ага. Иреннәре дерелди. Үзе бармаклары белән яулык очын бөтерә.

– Карамалымны сагынып еласам, кызларым ачуланалар. Туган илне белмиләр бит алар: берсе – төрек җирендә, икенчесе Грециядә туды. Малаем татарча белә иде, инде елдан артык хәбәре юк: бергә заводта эшләүче эшчеләрне каршылыкка котырта дип төрмәгә яптылар... Авылда минем әткәй калган иде, исәнме икән? Безнең өй өянке астында иде. Ык яры буенда... Өянкеләр төбендә иде өебез... Карамалыда...

– Елама, әби. Безнең консулга язарга кирәк, бәлки, кайтырга рөхсәт итәрләр.

– Ирем, мәрхүм, исән чагында язып караган иде, эш чыкмады. Өермәгә эләккән тузганаклар шикелле таратып ташлады безне язмыш... И Раббым... Өебез генә исәнме икән? Өянкеләре... Аларны кисмәделәрме икән? Шаулап үсәләр иде рвәлүциягә хәтле...

– Ялга кайткач, Карамалыга барып сораштырырмын әле. Әтиегез ни исемле иде?

– Шәмсулла исемле. Сатучы Шәмси дип йөртәләр иде. Ике энем, кияүдәге бер сеңлем бар иде. Алар исәннәрме икән? Бик нык кырдылар бит кешене, байларны бетерәбез дип...

– Алар турында да белешеп карармын. Без Генуяга еш йөрибез. Италия белән илебезнең мөнәсәбәте яхшы бит.

Минем сүзләремә карчык бигүк ышанып та бетми кебек иде. Әллә күп еллар өметсез яшәгәнгә, бу хәлгә күнегә алмый иде, ахры. Ул дәвам итте:

– Мин бит монда кунакта гына. Сагынуыма чыдый алмыйча, кызым янына килдем. Үзем улым белән бергә Ливадия шәһәрендә тора идем, аны төрмәгә япканчы... Хәзер инде күке шикелле чит ояда кунып йөрим. И Ходаем... Сак-Сокларга әйләнеп беттек инде...

Карчык тагын бераз зарланып утырды да кайтырга җыена башлады. Ишек露 тоткасына ябышкач, кинәт кенә маңгае белән ишек яңагына терәлеп үксеп елый башлады:

– И Ходаем... Алып кайт син мине, улым. Кая булса да яшер... Нинди җәзага да риза. Алып кайт! Карамалымны күрәсем килә. Ык буен, өянкеләрне... Карга тавышларын ишетәсем килә... Бәләкләп кер чайкаган тавышларны... Алып кайт, яме?.. Калдырма монда...

Карчыкны тынычландырырга тырышам. Консульствога язарга вәгъдә бирәм. Ул тыңламый.

– Өебез булмаса да, өянкеләребез исәндер әле. Алып кайт, яме? Кайтсам, ичмасам, туган илемдә үләр идем. Сөякләрем туган ил туфрагында ятар иде... Монда бит кабер казырлык туфрагы да юк. Җире гел таш... Алып кайт, яме?..

«
Алып кайт, яме? Кайтсам, ичмасам, туган илемдә үләр идем. Сөякләрем туган ил туфрагында ятар иде... Монда бит кабер казырлык туфрагы да юк. Җире гел таш...

Траптан[5] төшкәч, карчык пароходка озак итеп карап торды. Бераздан аның ябык гәүдәсе маяк астындагы кыя артына китеп күмелде.

Кич белән бик озак йоклый алмый яттым. Төшемдә әни карчыкны күрдем. Уянгач, әнием, ялгыз булса да, туган илендә яши әле дип куанып куйдым. Без дә бит шулай таралып беттек. Кайсыбыз кайда. Нигә туган җирдә генә яшәп булмый икән? Нинди көч гаиләләрне туздырып, туганнарны әллә кайларга таратып ташлый икән? Татар кешесе үз иркеннән китми бит туган җиреннән. Татарлар туган туфракларыннан бәхет эзләргә китәләр. Туган нигезендә бәхеткә ирешеп булмый микәнни? Кая киткән татар яши торган җирдәге бәхет? Кем куган аны? Нигә?

Иртәннән бирле башым авыртып тора иде, шуңа күрә, бераз йөреп кайтыйм дип, шәһәргә чыктым. Колумб йортына, Паганини музеена кергәнлектән, төштән соң гына кайтылды.

– Теге карчык тагын пароходка килгән иде, полисмен кертмәде, куып җибәрде, – дип каршы алды мине вахтада торучы матрос.

– Кайчан килгән иде?

– Иртүк. Сезне көтеп, көн буе причалда утырды. Әле яңарак кына куып җибәрделәр үзен.

Кич белән пароходны төяп бетерделәр. Сәгать кичке унда якорьны күтәрдек тә кайту ягына юнәлдек. Тәүлек ярым дигәндә без Мессина бугазында идек инде. Лигурия һәм Тиррен диңгезләре безне тыныч кына үткәреп җибәрде. Йоний диңгезе вак, җитез дулкыннар белән каршы алды. Ә кичкә таба җил, көчәйгәннән-көчәеп, давылга әйләнде.

Дулкыннар, гөрселдәп, пароходка ташланалар. Җил ыжгыра. Тирә-як су тамчылары белән тоташ томанга әверелгән. Җир белән күкне аерып булмый. Диңгез өстендә ак яллы шашкын дулкыннар куышып йөри. Һавада су тамчылары оча. Пароход калтырый, менә-менә таралып китәр кебек тоела. Металл тавышы чыгарып мачталар ыңгыраша.

Мин, вахтамны тапшырып, ял итәргә яттым. Кораб янтайганда, караваттан тәгәрәтеп төшерә. Диванга күчәм. Өстәлдәге әйберләр шапылдап палубага коела. Аларны җыеп, рундукка тутырам.

«Дүртенче трюм капкачының резинкасы бик тузган иде, трюмга су үтмәсә ярар иде», – дип уйлап ятам. Төшеп тикшерер идең, палубага чыгып булмый – палуба өстен дулкын ялый. Чыгу белән дулкын юып алып китүе мөмкин. Идәндә аунап яткан телефон трубкасын күтәреп, вахтадагы механикка шылтыратам:

– Льяль насослары төзекме?

– Төзек, Габдрахман Бәкерович. Сәгать механизмы кебек эшли.

– Вакыты-вакыты белән насосларны җибәреп, суны суыртып торыгыз, яме. Льяльләрне үлчәп булмый, горловиналар су астында.

– Тыныч булыгыз, Габдрахман Бәкерович, суыртып торабыз.

Пелопоннес ярымтавының көньяк очын – Малея борынын үткәч, шторм бераз басыла төште. Матапанны узып, Эгей диңгезенә чыккач, вак, хәлсез дулкыннар салмак кына тәгәриләр иде. Ә Мәрмәр диңгезе безне мәрхәмәтле тыныч штиле белән каршылады. Корабка җан керде. Шторм алып килгән зыяннарны тикшерергә тотындык.

Мин кесә фонарен алдым да трюмнарны тикшерергә киттем. Беренче трюм копкоры иде. Икенче трюмга да су үтмәгән. Өченче трюм дымлырак, ачып җилләтергә

[5] Трап – корабтагы теләсә нинди баскыч.

Океан киңлекләрендә. М.Юнысов ял вакытында китап укый. Атлантик Көнбатыш Африка ярлары буенда. «Чолым» пароходы. 1963 ел

туры килер. Безнең йөк юешне яратмый – бозылуы бар. Дүртенче трюмга төшү белән, аягым юешкә батты. Күңелем сизгән икән. Хәзер үк менеп капитан белән киңәшергә кирәк. Диңгез протесты[6] язмыйча булмас. Күпме юешләнде икән, буйдан-буйга әйләнеп чыгыйм әле, дип, йөк өстеннән атлап киттем.

Трюмның койрык ягы почмагына җитеп, борылып килә генә башлаган идем, аягым бер йомшак нәрсәгә басты. Фонарь белән яктыртып карадым... Нәрсә бу? Кеше түгелме соң? Иелеп капшап карадым да тораташ булып урынымда катып калдым. Тәнемә чымырдап ток йөгергәндәй булды. Аркама салкын тир бәреп чыкты. Мәет. Тәне кап-каты, салкын.

Рубкага ничек менгәнемне сизми дә калдым. Җыелып төштек тә трюмга люстра астык. Мәетне күтәргәч, тагын бер мәртәбә ток суккан кебек сиздем үземне: Генуяда очраткан теге татар карчыгы. Әллә тыны бетеп, әллә шторм вакытында чайкалуга йөрәге чыдамыйча үлгән, мескен. Мин биргән ипи сыныгын учына йомарлап тоткан.

Күрәсең, безнең пароход Генуяда соңгы кичне торганда, карчык, вахтадагы матросның швартов бауларын карарга киткәнен сагалап торып, пароходка кергән, сиздерми генә палубага үтеп, трюмга кереп яшеренгән.

...Без аны Феодосия портында соңгы юлга озаттык. Мәрхүмә үзенең теләгенә иреште: аның сөякләре бабаларыбыз яшәгән туган ил туфрагында ята, Кырым җирендә.

Генуя, «Чолым» пароходы, 1964 ■

[6] Диңгез протесты – шторм вакытында чыланган йөкне аклар өчен төзелгән документ. Нотариуста раслана.

Безнең мирас №6 июнь 2020

Хушлашмый да китеп бардың

Сәйдә Зыялы



Фәннур Сафин

Шагыйрьнең вафатын мин хастаханәдә ишеттем. Башым әйләнеп китте, караватым белән бергә каядыр еракка, билгесезлеккә очам шикелле тоелды. Кукмара, Мамадыш, Саба якларында укучылар белән очрашулар оештырган Фәннур арабыздан мәңгегә киткәнмени?

«Яшь ленинчы» редакциясендә эшләгәндә, Казан мәктәпләрен йөреп чыктык. Балаларны, ата-аналарны «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») гәзитенә язылырга өндәдек. Туган телебезнең олылыгы, аның аһәңе, матурлыгы турында сөйләдек. Үз туган телен, үз халкының тарихын белгән, аны олылаган кеше генә тәрбияле кеше була, дидек. Әйе, тик урыс телен генә тел иткән елларда мәктәпләрнең бер классыннан икенчесенә керә-керә аңлаттык. Мәкаләләр яздык... Шул көрәшче, шул моңлы шагыйрь бүген арабызда юкмыни? Салкын үлемнең ачы фаҗигасен акыл аңласа да, йөрәк ризалашырга теләмәде – бәргәләнде, сулкылдады. Телемә Фәннурның үз сүзләре килде:

Хушлаштың да китеп бардың,
Аерылышу авыр бит...

Аңа минем аваз кушылды:

Хушлашмый да китеп бардың...
Киттең инде, киттең мәңгегә...
Шигъриятнең олы югалтуын
Тоймыйбыздыр кебек әлегә.

Тоймыйбыздыр...
Бездә күп күңелләр
Каешланган инде, каралган;
Җәмгыятьне баскан кешесезлек
Микроб булып канга таралган.

Моны күреп үрсәләнгән шагыйрь
Үз хәлләрен үзе белгәндер...
Бәлки, шуңа күрә кешелеккә:
«Сез кемнәр?» – дип сорау биргәндер.

Без кемнәр соң? Үзгәрмәдек микән,
Фикер иреге катгый тыелгач?!.
Хак әйтелгән сүзнең баш өстендә
Меңләп җәллад булды, йөз тылмач.

Ул хак сүзне башлап шагыйрь әйтә,
Китә канатлы сүз җир иңләп!
Сүзе эзләренә баса-баса, Фәннур
Килеп чыгар сыман җилфердәп.

Гомер бакый шулай: шагыйрь җаны
Үкенечле булып янадыр;
Шигърияткә кара кайгы салып,
Килеп керде быел Яңа ел...

Фәннурның үлеменә багышлап 1993 елның 1 гыйнвар көнендә мин шушы шигырьне язып куйганмын.

Шул елның декабрь башында талантлы шагыйребез Фәннур Сафин рухы белән очрашкандай булдым – аның архивы белән таныштым. Без шагыйрь итеп кенә белгән Фәннур хикәяләр дә, пьесалар да язган икән бит! Өч пәрдәлек «Ләйсән җыры» пьесасы, «Аучы белән Алтынай» либреттосы, поэмалар, шигырьләр... Шагыйрьнең күз нурлары түгелгән, сүзләрен сеңдергән кульязмалар... Онытылмасын иде алар.

Тыйнак кеше иде Фәннур. Бәлки, шуңа да аның китаплары аз чыккандыр. Таләпчән талант иде. Чыккан әсәрләре – әдәбиятыбызның энҗе бөртекләре. Калган әсәрләре дә китап булып укучылар кулына керсә иде. Дөньялар да гел болай шыксыз, өметсез булмас – төзәлер, рәтләнер. «Дөнья – куласа», – ди халык. Бәлки, дөнья, әйләнә торгач, татар шигыренә, татар китабына да битен күрсәтер. Өметтә калыйк.

Нечкә күңелле кеше иде Фәннур. Күңел кылларыннан өзелгән моң-сагышы, уйхисләре – шигырьләрендә, җырларында...

Фәннур Сафин шигырьләре

Дөнья...

Кемдер дәшми шәһит китә
Тугры калыр өчен.
Кемдер яши тугры сүзне
Ярып салыр өчен.

Кемдер яши, тынычлыкта
Гомер үтсен, дип.
Яки минем алда дөнья
Тездән чүксен, дип.

Кемдер яши «Сөям...» дигән
Бердәнбере өчен.
Һәм кемгәдер күкрәгеннән
Ялкын өрер өчен...

Шул кемнәрдер өчен бу җир
Борчыла, сөенә.
...Бер карадан киенә ул,
Бер актан киенә.

***

Назлар да юк, чәчәкләр дә,
Кошларның сайравы да.
Ялгыз гына китеп барам
Иң якты язларыма.

Моңланма да, кайгырма да,
Бик сөенмә дә, күңел;
Агымсуда – ак болытлар,
Шуларга гына үрел.

Шатлык та юк, сагышлар да
Күңелем чатларында.
Китеп барам хыялдагы
Бәхетле чакларыма.

Яшәү дәрте

Имәннәрнең башы күккә тисә,
Кисә икән яшен кылычы.
Көлләренә күз яшьләрен түккән
Гөлләрдә бар йөрәк җылысы.

Яшәү дәрте, безнең хыяллар күк,
Ул үзәктән, төптән киләдер;
Иңрәп ауган саллы имән язын
Яшел яфрак ярды, нигәдер...

Соңгы сутын яфрак итеп имән
Бу хәятне кала кадерләп.
Яу кырына ауган солдат сыман,
Узган гомерен ята хәтерләп.

Ядкәр

Кызыл алма ак чәчәктән
Истәлек булып калган...
Синең өчен мин дә чәчәк,
И, киләчәк – күзалмам!

Синең өчен дә бер чәчәк –
Минем гомер, и, каләм!
Син булганга, шатлыгымны
Җиргә күмми китәләм.

Алмаларым калыр җирдә –
Кызыл ярда кызарып.
(Кемдер өзәр гамьсез генә,
Кемдер узар кызганып...)

Калыр бәхет, якты сагыш...
(Калмас бит кара ялган?)
Ул алмалар минем яздан
Бер ядкәр булып калган. ■

Мәхмүт Хөсәен вафаты

Ләбиб Лерон

Миңа калса, кызыклы факт бу: шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең гомер елларында 3 саны бик еш кабатлана. Сүземне раслау өчен дәлилләр китерәм: 1923 елда туган; 1943 елның гыйнварында, әле егерме яше дә тулмаган егет, взвод командиры булып, тәүге сугышка керә; 1963, 1973 һәм 1983 елларда «Чор һәм җыр», «Ләйсән», «Мәхәббәт һәм моң» дигән шигъри җыентыклары дөнья күрә; 1973 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә; 1983 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә; 1993 елның мартында вафат була.

Язучылар берлегенә кабул ителгән вакытта шагыйрь илле яшендә була инде. Заманында «Артек»та булган, мәктәптә укыганда ук шигырь-такмазалар һәм хәбәрләр язган, Абдулла Алиш белән хатлар язышкан, сугыш вакытында урысның атаклы язучысы Константин Симонов белән очрашкан (Симонов аның турында очерк язган), берничә тапкыр яраланган, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Байрак һәм Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән, 1945 елда Ленинградта тәүге китабын бастырып чыгарган, сугыштан кайткач, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган, озак еллар Татарстан китап нәшриятында редактор (1952-1954), матур әдәбият редакциясе мөдире (1954-1957) һәм өлкән редактор (1957-1975) булып эшләгән шагыйрьне нишләп берлеккә әгъза итеп бик соң алганнар? Моның бер һәм бердәнбер сәбәбе: берничә аксакал әдипнең М.Хөсәенгә уңай караштa тормавы, дөресрәге, тәмуг газапларын кичкән бер мәшһүребез белән Мәхмүт Хөсәен

арасында булган үтә җитди аңлашылмаучылык. Белүемчә, монда Мәхмүт аганың бер гаебе дә юк. Әлеге шәхесләребез һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр турында бер китап, һичьюгы, берәр мәкалә-истәлек язарга була. Анысы, кем әйтмешли, киләчәк эше – Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсә, язылыр…

Сүз башым бит Шүрәле иде, дигәндәй…

1993 елда «Салават күпере» журналының март санында Мәхмүт Хөсәеннең «Үрмәгөл» дигән шигырен бастырырга ниятләдек. Редакциябезгә үтешли генә кергән Мөдәррис Әгъләмовтан кереш сүз дә яздырып алдык: «Авыллар күп безнең татар илендә. Мәхмүт абый шуларның һәрберсендә диярлек булган, шигырьләрен укыган. Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – ышанмагыз, Мәхмүт абый Хөсәенгә 70 яшь тула. Аны бу олы бәйрәме белән, без котламый, кем котласын! Бәйрәм белән, Мәхмүт абый!»

Журналны типографиягә иртәгә-берсекөнгә тапшырабыз дип торган көннәрнең берсендә редакциядә телефон шылтырады. Трубканы алуга, Мәхмүт абыйның көр тавышы яңгырады:

– Саумы, Ләбиб! Ничек анда минем шигырьнең хәлләре? Чыгамы инде журналыгыз? Шигырь янына минем сурәтне дә куймыйсызмы?

Мин җавап бирәм, көлешә-көлешә сөйләшәбез:

– Журналга моңарчы бер фото да бирмәдек, Мәхмүт абый. Фотоны махсус кулланмыйбыз, художниклар ясаган рәсемнәрне генә файдаланабыз, – дим. – Фото урынына Мөдәррис абый Әгъләмнең сезнең турыда бик матур итеп язган кереш сүзен бирәбез!

– Ну-ну, үзегез беләсездер инде. Мөдәррис язгач, бөтенләй булган инде бу! Минем шигырьне бастырып тормасагыз да була…

Көлешәбез.

– Тавышың бик яхшы ишетелә. Кайдан шылтыратасың, Мәхмүт абый? – дим.

– Обком бүлнисендә ятам әле мин. Чехов базары янында. Сездән ерак түгел.

– Авырып киттеңме әллә, Мәхмүт абый?

– Юк, авырмыйм. Болай гына, юбилей алдыннан профилактика үтәргә кергән идем. Озаклап ятарга исәп юк…

Икенче көнне…

Икенче көнне инде без, берничә яшь каләм әһеле һәм Мәхмүт абыйның ике-өч туганы, бергәләп, алмаш-тилмәш килеп, Дәрвишләр бистәсе зиратында кабер казый идек…

Мин белә-белгәннән бирле гел кәләпүштән йөрде Мәхмүт абый. Үз-үзеннән көлеп, мондый икеюллык та язган иде ул:

Урысның бар Александр Пушкины,
Татарның бар Мәхмүт Кәләпүшкине!

Мәхмүт абыйның «Салават күпере»ндә басылган шигыре болай дип башланган иде:

Матур булып килде яз:
Көннәр җылы, күк аяз...

Мөдәррис Әгъләмовның кереш сүзе астына дүрт җөмлә өстәлде: *«Өлгерми калдык. Мәхмүт абый сабыйлар журналының котлавына сабыйларча сөенә алмый калды. Ул кинәт вафат булды. Инде хөрмәтле шагыйребезгә соңгы сәламебезне күндерәбез: тыныч йокла, Мәхмүт ага, урының оҗмахта булсын!»*

1993 елның язы матур булып килмәде. Көннәре, киресенчә, суык иде.

15 апрельдә туган шагыйрь, күркәм бәйрәменә нәкъ бер ай калгач, 15 март көнне гүргә – туң җиргә кереп ятты. Урыны оҗмах түрләрендәдер, шәт. ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Яңа Татар бистәсе мирасы

Барудиның кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Галимҗан Баруди (1857-1921) – мәшһүр дин галиме, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, нашир, журналист. Ул 1921 елның 6 декабрендә Мәскәү шәһәрендә вафат булган. Аның җәсәден, Казанга алып кайтып, Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләгәннәр. Каберенә якынча ике метрлы бер таш яздырып куйган булганнар.

Ул ташның тексты мондый:

1) «Мәшһәдүл-гаалим-
2) ил-фәәдыйли
3) хаадимил-гыйльми
4) Вәд-диини
5) Галимҗан
6) бине Мөхәммәдҗан
7) әл-Баруди
8) рахимәһүмәәллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ
10) 1340 сәнә 6 нчы рабигыль-әүвәлдә
11) 64 йәшендә вафат булды
12) 1921 йыл 6 нчы дикәбердә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Хөрмәтле галим,
2) гыйлем һәм
3) дин хадиме
4) Галимҗан
5) бине Мөхәммәдҗан
6) Баруди
7) кабере.
8) Аллаһ аларның икесен дә киң
9) рәхмәте белән рәхим кылсын.
10) 1340 елның 6 рабигыль-әүвәлендә,
11) 1921 елның 6 декабрендә
12) 64 яшендә вафат булды».

Ахыргы 3 юлы ташның постаментында язылган. Бераз ялгышыпмы, буталыпмы, 1921 елның 6 декабре, һиҗри ел исәбе белән 6 рабигыль-әүвәле дип күрсәтелгән. Чынлыкта үлгән ае рабигыль-ахир булырга тиеш иде. Р.Фәхреддин Г.Барудиның 67 яшендә вафат булуын язып калдырган, ләкин ул аның яшен һиҗри ел исәбе белән санаган.

Вакытлар узу белән таш, ватылып, постаменттан аерылып җиргә ауган. Шуннан соң постаментыниндидер сәбәпләр белән бөтенләй югалган һәм ул байтак еллар постаментсыз гына торган. Шуңа күрә Барудиның кабер ташы бик кечкенә булып күренгән. 2017 елда Татарстан Диния нәзарәте аны яңага алыштырды. Иске таш исә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә музеена саклауга куелды. Шулай итеп, Барудиның каберенә мәрмәрдән эшләнгән яшькелт төстәге кечкенә генә яңа кабер ташы куелып, анда мондый сүзләр язылган:

1) «1857/1273-1921/1340
2) Галимҗан хәзрәт Мөхәммәдҗан углы
3) әл-Баруди (Галийыф)
4) мәшһүр дин галиме, ишан, җәмәгать эшлеклесе
5) Мөхәммәдийә мәдрәсәсенә нигез салучы күренекле мөдәррис
6) Русийә мөселманларының Динийә нәзарәте мөфти».

Ахыргы өч юлы ташның аскуймасында язылган. ■

Прокурор

(Хатирә)

Фарук Нәфиев

Сәйфихан Нәфиев

Әтисе Хәбибулла абый – авылыбызның беренче шоферы – 1941 елның җәендә үзе йөртә торган «полуторка» машинасы белән Бөек Ватан сугышына китеп немец илбасарлары белән көрәшкәндә, ноябрь азагында туды Сәйфихан. Мин, аңардан 5 яшькә олырак малай, Сафиулла бабайның матча өрлегенә махсус беркетеп куйган сыгылмалы яшь каен курасы очына җайлап куйган бишеген тирбәтүләремне яхшы хәтерлим.

Бервакыт бабай, Хәдичә әбине, минем әни Халидәне, бишектәге малайның әнисе Фәтанәт апаны үз янына дәшеп алып, сабыйга исем кушарга вакыт җитүен белдерде.

– Әтәй, улыбызга нинди исем кушабыз инде? – дип сорады шунда кулларын һәм тәпиләрен селкетеп ятучы малайның әнисе Фәтанәт апа.

– Сезгә ошаса, бер исем тәгаенләп куйган идем, – диде бабай.

– Әйдә, сузма, карт, нинди исем ул? – дип, Хәдичә әби дә сүзгә кушылды.

– Сәйфелмөлек! – дип җаваплады бабай, ап-ак кыска сакал-мыеклы башын горур күтәреп.

– И-и-и, әтәй, моны бит мишәре-татары, урысы-чуашы – һәркайсы үзенчә әйтеп, бозып-имгәтеп бетерәчәк, – дип, Фәтанәт апа борчылуын яшермәде.

Сүз уңаенда әйтим әле: бер йортта ике килен-килендәш, әни бабайдан тел яшерә, ә аның сеңлесе Фәтанәт апа исә гаҗәеп кыю холыклы, бабай белән бәхәсләшергә дә күп сорап тормый иде. Юкка гына аны алты бригадалы «Кызыл партизан» колхозында бик мөһим бригадир вазыйфасына куймаганнардыр иң авыр сугыш елларында. Кыскасы, ут чыгарып, тирләп-пешеп эшли, барысына да үрнәк күрсәтә иде апа.

Шунда бабай, түр өстәл өстендәге үзе еш укый торган китаплар белән бергә яткан яшел тышлы дәфтәрен алып, аңа бер мизгел карап торгач:

– Алай булганның соңында, мәгънәсе дә ачык, күркәм, һәркемгә әйтергә дә җайлы – Сәйфихан, ягъни гарәпчә «хан кылычы» – дәүләт җитәкчесенең үткен коралы була инде, – дип сүзен төгәлләде.

Әлеге ат-исем барысына да ошады. Бер уйлаганда, исең-хушың китәрлек, валлаһи, исеменең җисеменә ничек туры киләчәген карап алдан бак әле син! Соңыннан үсеп җиткән егет башта Чүпрәле районы прокуроры урынбасары, аннары Әлки-Базарлы Матакта, берничә елдан Бөгелмәдә, шуннан соң Казанда, һәм, ниһаять, давыллы-өермәле 90 нчы еллар башыннан 2000 нче елга хәтле Республика прокуроры һәм дә тагын 4 ел Республика Конституция суды рәисе була. Ни генә дисәң дә, бабай куйган бу кояшта корыч кылыч кебек балкып торган исемнең шулкадәр дәрәҗәдә җисеменә туры килүе барыбер сирәк күренештер.

Аеруча элегрәк заманнарда балаларга исем кушуга ни дәрәҗәдә мөһим, җаваплы эш итеп карауларын әлеге мисал-өлге үрнәгендә бөтен күңелем-рухиятем белән тойгач, ихтыярсыздан күзләремә кайнар яшьләр килде. Рәхмәт әби-бабайларга! Үземә дә бит шул ук Сафиулла бабай исем кушкан. Хәтеренә ни килсә, шуны түгел, бабай бу очракта да ашыкмыйча, тирән уйлап эш иткән. Мөхәммәд (с.г.в.), бервакыт сәхабәсе Гомәр разыйаллаһу ганһуга, үтә дә җаваплы вазыйфасын үрнәк башкарганы өчен, «Гомәрел Фарук» дигән өстәмә исем биргән. «Дөреслек-хакыйкатьне ялганнан нечкәләп аера белүче» дигәнне аңлата икән ул. Әйе, элегрәк, укымышлы бабайлар заманында, шулай булган. Совет властеның беренче елларында һәм ары таба да моңа хәтле колак ишетмәгән Даздраперма, Эрлен, Марлен, Вилорик, Лимузин, Гертруда исемнәре тезелеп китә. Соңга таба Италия, Испания, Франция, Германия якларыннан Рәсәй уртасындагы Татарстанга килеп җиткән Рафаэль, Ринат, Долорес, Альберт, Альфред, хәтта Адольф, Лениза, Лариса, Марсель, Марат, Марс исемнәре авыл-шәһәрләребезне басып китте. Ни өчен соң безнең халык шул дәрәҗәдә талымсызлык, зәвыксызлык күрсәтә?!.

Бервакыт мин – Тәтеш партия райкомында бүлек мөдире, Сәйфихан Казан прокуроры булып эшләгәндә, КПСС өлкә комитетында очраштык. Минем куратор шунда: «Сез бертуганнармы соң?» – дип сорау бирде.

– Безнең Фарук абый белән әтиләребез дә, әниләребез дә бертуганнар. Шуңа күрә без аның белән бертуганнардан да якынрак, – дип җавап бирде энем.

***

Хәбибулла абый 25 яшендә сугыш кырында корбан булганга, Сәйфихан, әнисенең бердәнбер улы буларак, кечкенә малай чагыннан ук аның төп ярдәмчесенә әйләнде. Улын сыңар канаты белән тәрбияләп, мәктәптә, аннан соң вузда югары белем биреп, җәмгыятькә лаеклы кеше итеп үстерү өчен, ялгыз ана бөтен көчен бирде. Апа,

абыйның истәлегенә ахырга хәтле тугры калып, кияүгә чыкмады, вафатына чаклы улы гаиләсендә яшәде. Әйе, дөньяда иң изге хис ул – ана мәхәббәте!

Ә бит 700 йортлы безнең Мунчәли авылында бу чорда Сәйфиханның туганнан туган 33 абыйсы һәм энесе, 15 апасы һәм сеңлесе бар иде. Барысы да аны иң якын кардәше итеп күрде. Үзем, Казанда булган саен, янына кереп, хәлен белешә идем, фатирында кунып калган очраклар да булды. Бервакыт мин аңа чынын да, шаяртуын да бергә кушып, дигәндәй:

Хәбибулла Сафиулла улы Нәфиев. 1941 ел

– Синең бит авылда, районда, республикада дүрт дистәдән артык кардәш абый-энеләрең, апа-сеңелләрең бар. Алар арасында никадәр югары белемле белгечләр, педагоглар, әдәбият-мәдәният эшлеклеләре, берничә колхоз председателе, әниең белән бертуган Зәйнәп апаңның Рафигы – Мәскәүдә КГБ полковнигы. Ул бит белеме-әзерлеге белән бүгеннән Татарстанның эчке эшләр министры һәм башкалар булып эшли ала. Ә үзем, район газетасы редакторы булып эшләгән журналист, бүген – райком әһеле. Синең бит сүзең үтә. Казандагы берәр газета-журналга редактор итеп кирәкле җирдә тәкъдим итсәң, эшли алуыма ышанам, – дидем.

– Кара әле, әнинең энесе Нурмөхәммәт абый – ИЯЛИ институты директоры, хатыны Фәһимә апа – КДУ профессоры, туганнарыбыз Алсу Гайнуллина – Камал театры артисты, Венера апа Шәрипова – Опера театры солисткасы, Алсу сеңлебез Әбелханова – танылган җырчы. Аларга минем бер тамчы да ярдәм иткәнем юк.

Сәйфихан әнисе Фәтанәт белән үзе салдырган өйдә – туган авылы Мунчәлидә. 1969 ел

һәммәсе дә барысына да үз көчләре белән ирештеләр. Шуңа күрә җитди әйтәм: калганнарыгыз да, олы максат куеп, үзегез ирешегез. Ачуың килмәсен, абый, минем биредә, үземнең эш урынымнан файдаланып, гаилә фирмасы оештырырга бер теләгем дә юк! – дип кырт кисте Сәйфихан. Нишләтәсең, туры сүзгә җавап юк...

Сәйфиханның Чүпрәле районы прокурорының урынбасары вазыйфасын башкарган чагы

Шулай Казан университетында икенче курсны тәмамлап, каникулга кайткач, Сәйфихан мине үзе чәчеп-карап үстергән кукуруз басуына алып барды. Анда бамбук урманын хәтерләткән 4 метрдан узган кукурузларны гомеремдә беренче тапкыр күреп, шаккаткан идем. Шунда, кызык өчен, дип, янәшәдә генә туктаган йөк машинасы әрҗәсенә менеп бастым, ә кыр «королевалары» миннән дә биегрәк иде! Соңыннан силос өчен яшел массаның биредән гадәттәгедән ике тапкырга артыграк алынуы турында, Авыл хуҗалыгы министрлыгы белгечләре килеп тикшереп, махсус брошюра әзерләп чыгара. Яшь комсомолец, спортчы-көрәшче, алдынгы механизаторны район комсомол комитетының оештыру бүлеге җитәкчесе итеп алалар. Ул эшне озакка сузмый, Казан дәүләт университетының юрфагына читтән торып уку бүлегенә кереп кайта. Аннары, ел да үтмәстән, Чүпрәле районы прокурорының урынбасары булып эшли башлый. Әле озак дәвам итәчәк олы юл башы менә шулай үзе туып үскән җирдән, кыр-басудан, анда тирләп-пешеп эшләүдән башлана...

Хезмәт юлыбызны башлаган вакытларга әйләнеп кайтыйк әле. Үзем дә, районыбыз үзәге Чүпрәледә урта мәктәп тәмамлап, көзен армия хезмәтенә алынып, өч ел буе Ерак Көнчыгышта, Тын океан флотында хезмәт иттем. Ә Сәйфихан исә, урта мәктәпне күршедәге Чуашстанның Баеш авылында русча тәмамлап, әнисенең бердәнбер терәге-таянычына әйләнә. Әле армия хезмәтенә дә елдан артык вакыт бар. Нишләргә соң? Сәнәк, көрәк тоттырып, колхоз фермасына җибәрергәме? Апаның башында әнә шундый сораулар өере бөтерелә. Район үзәгенә барып киңәшә дә күршедәге Тәтеш районының Монастырск механизация училищесына укырга җибәрергә була ул улын. «Механизатор – авылда күренекле фигура, эше дә, ашы да бар. Ипи-күмәчсез тормыйбыз, кеше арасында кимхур булмабыз», – дип фикерли апа һәм ялгышмый. Сәйфихан кайчандыр әтисе дә укып чыккан училищены уңышлы тәмамлап кайта һәм туган «Кызыл партизан» колхозында башы-аягы белән эшкә чума. Язын чәчә, җәен эшкәртә, көзен уңышын җыя.

Ә бит Сәйфиханның киләчәк язмышына старты да, алдарак әйтелгәнчә, нәкъ менә шушы кыр-басудагы фидакарь хезмәтеннән башлана.

Бераз алгарак китеп, энемнең кыюлыгын, тапкырлыгын, булдыклылыгын күрсәткән, мине инде ничәнче тапкыр гаҗәпкә калдырган чираттагы гыйбрәтле очракны искә аласым килә. Бервакыт, туксанынчы еллар азагында, җәйнең матур бер көнендә Сәйфихан аккош кебек балкып торган мәһабәт ак машинада Тәтеш прокуратурасының яңа бинасын ачу тантанасына килеп төште.

Төрле чыгышлар яңгырап, тәбрикләр әйтелеп, рәсми өлеш тәмамлангач, район башлыгы республика кунагын ул чагында үзенең дөнья һәм олимпия чемпионнары белән СССРга гына түгел, бөтен дөньяга танылган данлыклы стендчылар тирына чакырды. Сәйфихан мине үз машинасына утыртып алып китте. Озакламый Идел ярындагы

М.Ш.Шәймиев һәм С.Х.Нәфиев Дәүләт Советы утырышыннан соң

«Сәйфихан Хәбибулла улы Нәфиев бөтен гомерен бик кыен, әмма мәрхәмәтле эшкә – кеше һәм гражданин хокукларын яклауга багышлаган шәхес, Татарстанның күренекле, иң абруйлы җитәкчеләренең берсе иде. Сәйфихан Хәбибулла улын белүчеләр аңа яшьтән үк гаделлек, дөреслек-хакыйкать хисе хас булуын аерым билгеләп үтәләр. Яшь егетнең гомерлек профессиясен сайлавына нәкъ менә шушы хис ярдәм иткән дә инде.

Казан университетының юридик факультетын тәмамлагач, ул прокуратура органнарына эшкә килә. Анда бөтен барлыгы – сәләте-таланты белән эшкә чумып, барлык үсеш баскычларын үтеп, чирек гасырга якын фидакарь хезмәт куя. Аны Чүпрәле һәм Әлки районнарында, Бөгелмәдә яхшы хәтерлиләр.

Җинаятьчелек җәелеп киткән 80 нче елларда, җәмгыятьтәге давыллы үзгәрешләр чорында, ул башта Казан, аннары Республика прокуратурасын җитәкләде. Сәйфихан Хәбибулла улы әлеге җаваплы постларда, эшлекле принципиальлеге, ныклыгы белән, хокук саклау органнары эшен оста оештырып, җинаятьчелек белән көрәштә хәлиткеч нәтиҗәләргә иреште.

чәчәкле гүзәл болынга урнашкан мәһабәт спорт комплексына килеп җиттек. Шунда тир комплексы директоры – халыкара спорт мастеры Сергей Протасов, кулына ике көпшәле спорт винтовкасы алып, төрле каланчалардан очып чыккан графит тәлинкәләргә атып күрсәтте. Аннары район һәм шәһәр түрәләре дә спортның бу төрендәге маһирлыкларын күрсәтергә ашыкты. Бу тамашаны күзәтергә халык та күп җыелган иде.

Шулчак район башлыгы Марат Фазлыев:

– Сәйфихан Хәбибуллович, бәлки, Сезнең дә атып карыйсыгыз киләдер? – дип, винтовкасын Казан кунагына сузды.

– Спортның бу төре белән шөгыльләнгәнем юк-югын. Алай да, халкыбыз әйткәнчә, ятып калганчы атып калыйк әле, – дип, позиция пьедесталы өстенә менеп басты һәм, мылтыгын ике кулы белән күтәреп, мушкага карауга: «Дай!» – дигән боерыгын бирде. Соңгы аваз яңгырап беткәнче, каланчадан ике тәлинкә – берсе югарыга – болытларга таба, икенчесе түбәннән фырлап очып чыкты. Шунда Сәйфихан, яшен тизлеге белән мылтыгын өскә төбәп, аннары аска юнәлтеп, ике тәлинкәне дә чәлпәрәмә китерде. Тамаша кылып торган халык «аһ!» итте. «Спорт белән шөгыльләнмәгән» кешедән беркем дә моны көтмәгән иде…

Әгәр дә мәгәр суверенитет яулау чорында аның Мәскәү белән аяк терәп сөйләшеп, үз республикасы халкы мәнфәгатьләре өчен ничек кыю көрәшүе турында бәйнә-бәйнә сөйләсәм, бу журнал язмасына түгел, зур бер повесть-бәянга әйләнер иде. Ә журнал мәйданы резина түгел!

Татарстан Республикасы прокуроры буларак, Сәйфихан Хәбибулла улы дәүләт хакимиятенең федераль органнары белән мөнәсәбәтләрдә катлаулы һәм бәхәсле мәсьәләләрне үз халкы һәм республикасы мәнфәгатьләрендә җайга салуда күп эшләр башкарды. Аның принципиаль һәм бер үк вакытта сыгылмалы позициясе республикабызга үзенең норматив-хокук базасын ныгытырга, федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрне җайларга мөмкинлек бирде.

Сәйфихан Нәфиевнең җитәкчелек һәм зур юристлык таланты Татарстанның Конституция суды рәисе булганда аеруча ачылды. Ул үзе җитәкчелек иткән органнар эшчәнлеген республика тормышыннан аермады, аларның тырышлыгын Татарстанда тынычлык һәм иминлек саклауга юнәлтте.

Без аны иң кыен тормыш ситуацияләрендә бердәнбер дөрес юлны таба белүче, гади гражданнарның да өмет һәм ихтыяҗларын тирән аңлап, барысына да ярдәм итәргә тырышкан күркәм холыклы, интеллигент кеше буларак хәтерлибез. Ул кешеләргә һәрвакыт ачык иде, үзенең фидакарь хезмәт чорында меңләгән кешене кабул итеп, гозерләрен үтәде.

Сәйфихан Хәбибулла улын дуслары һәм якыннары зур җитәкче, югары профессиональ сыйфатында гына түгел, ә барлык туганнар өчен дә ныклы терәк буларак та беләләр иде.

Ул үзенең мәрхәмәтен, ышанычын дуслары һәм хезмәттәшләренә мул итеп бүләк итә белә иде. Аның Татарстан Республикасы һәм аның халкы өчен кылган игелекле гамәлләре бервакытта да онытылмаячак.

Кыскасы, ул бөек шәхесләргә генә хас югары әхлак, тирән профессиональ сыйфатларга ия уникаль шәхес-зат иде».

М.Ш.Шәймиев, *Татарстан Республикасының беренче Президенты*

Шуңа күрә балачагыбыз хатирәләренә бәйле берничә мизгелне генә сурәтлим дә нокта куям.

...Сафиулла бабай бик җитди, кырыс табигатьле кеше иде. Ул кайбер яктан үзенең шаярырга ярата торган оныгы Алеша Пешков өчен пеше тал чыбыкларын зур агач ләгәндәге суда тотучы Каширин бабайны хәтерләтте. Бервакыт, 4 яшьтә чагымда, бакчадагы әле өлгереп җитмәгән әче борыч кузакларын өзеп, майка итәгенә тутырдым да, бабай каршына килеп: «Бабай, менә нәрсәләр таптым!» – дип мактанырга җыенганда, аның ак чөй сакалы ачудан бизгәк тоткандагы кебек калтырана башлады һәм көрәк хәтле кулы, миңа таба сузылып, колагымны борып алды. Мин исә, мактаганны көтеп торган малай, авыртуга чыдый алмыйча: «Бабай, колагымны урынына куй!» – дип, байтак вакыт аның артыннан ияреп йөрдем. Соңыннан Сәйфиханга да аның үтемле тәрбия ысулы эләкми калмады, билгеле. Малай үзе дә кырыслык һәм җитдилек дигән нәрсәләрне бабайдан шактый кабул итте кебек.

Әле уйлап куйдым. Педагогик тәрбия әллә ни үсеш алмаган чорда кечкенә Алеша Пешковка бабасының тал чыбыклары гомергә онытылмаслык тәрбия чарасы булгандыр дип ничек нәтиҗә ясамыйсың?!. Бернинди институт, университеттан башка гына бөтен дөньяга танылган даһи шәхес нинди тәрбия җимеше соң? Сәйфиханны һәм мине үз методикасы белән тәрбияләгән Сафиулла бабай да үзенә күрә халык педагогы-профессоры булган икән бит. Сәйфиханның соңыннан легендар шәхес булып җитешүендә бабайның да роле булгандыр дип уйлыйм.

Булачак прокурор Сәйфихан Нәфиев (рәсемдә уңнан беренче, армиядән кыска ялга кайткан чагы) якын туганнары Фарук һәм Рәшидә белән. 1961 ел

Без дә Сәйфихан белән, Такташның ак каеннарга үрмәләп үскән табигать балалары кебек, урманы, болын-кырлары, елга-инешләре белән бизәлгән гүзәл почмагында үстек.

Нәкъ безнең урам башыннан башланган, иңе – 2, буе 5-6 чакрымга сузылган өстәл өсте кебек тигез, исәпсез-хисапсыз төрле чәчәкләр белән бизәлгән болынны икегә бүлеп, Татарстан белән Чуашстан чиге буларак, карталарда күрсәтелгәнчә әйтсәк, мул сулы Бизнә елгасы ага, ә безнең авыл халкы аны, Чуашстан ягындагы Әсән авылы исеме белән, Әсән елгасы яки Әсән суы дип йөртә иде. Язын елга суы ташып, бөтен болынны мул итеп сугарганга, колхоз бирედән печәнне өч тапкыр чабып ала иде. Бераз көнчыгышка табарак Бизнә суы җәй буе җәелеп, суы кипми торган 5-6 квадрат километр мәйдан билəгән сазлык та бар. Анда урман кебек 5-6 метр биеклеккә үскән таллар, балан, шомырт, тирәк кебек агачлар, аланы-аланы белән камыш үсә иде. Ул сазлык эчендә бүре, төлке, янут этләре, торна, киек каз, үрдәк кебек кошлар да, оя ясап, бала чыгардылар. Кыскасы, искиткеч гүзәл почмак – табигый заказник. Оныта язганмын, аннан чиләк-чиләк чиядәй эре кара карлыган да җыя идек.

Җәйнең матур көннәрендә Сәйфихан белән мин, чалгы һәм урак алып, сазлык эчендәге болыннардан камышны чабып-урып, көлтәгә бәйлибез дә, кичләрен җигелгән үгез белән килеп, төяп өйгә алып кайтабыз. Аннан таратып киптерәбез, мал-туарга печән-азык әзерләп куябыз…

Әле сугышка чаклы Хәбибулла абый – өйләнмәгән егет – мине, 4 яшьләр тулып килүче малайны, шул Әсән суына кармак белән балык тотарга алып бара иде. Башта тиреслектән суалчаннар җыеп тартмага тутыра да, аның белән елганың балык шәп чиртә торган урынына килеп, кармагын суга ташлый. Шундый сафлык, чисталык – су үтә күренеп тора. Менә берзаман суалчаны селкенеп торган кармакны дистәләгән кәрәкә сырып ала һәм иң көчлесе, суалчанлы кармакны кабып, читкә сөйрәп китә һәм мизгел эчендә яр буенда сикергәләп, кояшта көмештәй ялтырый башлый. Абый аны сулы бидонга сала да калган «компаньоннар»ын да бер-бер артлы эләктерә.

Хәтеремә, балык тотудан да бигрәк, абыйның полуторка кабинасына янәшә утыртып йөрүе балачагымның иң гүзәл мизгеле булып гомергә уелып калган. Кабинасындагы бензин исе миңа бүгенге иң шәп француз хушбуеныкы кебек тоела иде! 25 яшендә чагында Белоруссиянең Полесье якларындагы дәһшәтле, каты сугышта Ватаны, халкы өчен гомерен биргән Хәбибулла абыйның урыны җәннәттә булсын. Аларның тиңдәшсез батырлыгы сугыштан соң үткән 75 елда һәм алга таба да онытылмаячак. ■

Җиңүгә – 75 ел

Сугыш еллары кайтавазы

(Ш.Камалның Милли музейда сакланучы архивы материалларыннан)

Гөлназ Җиһангирова

Ш.Камал – уңда (утырган), хатыны Хәят – уртада, уллары Йосыф – уңнан икенче. 1935 ел

Тарихи мирасны саклау үзәкләре буларак, музейлардагы ядкәрләр халкыбызның үткәнен чагылдыручы искиткеч бай хәзинәне саклап киләләр. Күптән түгел яңадан үз ишекләрен ачкан Татар әдәбияты тарихы һәм Ш.Камал музее да – тарихи истәлекләрне саклаучы шундый урыннарның берсе.

РСФСР Халык Комиссарлары Советының 1944 елның 2 июнендә «ТАССР Халык Комиссарлары Советына 1 июльдән Татарстан АССРның туган якны өйрәнү музее әдәби филиалын оештырырга рөхсәт итәргә...» дигән карары нигезендә, язучы Ш.Камал яшәгән фатир музей дип игълан ителә. Бу Ш.Камалның исемен мәңгеләштерү максатыннан эшләнә. Танылган шәхес, халыкның яраткан язучысы Ш.Камал, озак вакыт авырганнан соң, 1942 елда Казандагы фатирында вафат була. «Татарстан Совет Язучылары Союзы правлениесе һәм башлангыч партия оешмасы татар әдәбиятының классигы, орденлы язучы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Язучылар Союзы правлениесенең члены, ВКП (б) члены Шәриф Камал иптәшнең 1942 елның 22 декабрендә вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм мәрхүмнең гаиләсенең кайгысын уртаклашалар», – диелә матәм хәбәрендә. Ике елдан Ш.Камал яшәгән, күренекле татар шәхесләренең очрашу, фикерләшү урыны булган фатирда музей оештырыла. Бу йортка әле күптән түгел

генә Ф.Кәрим, М.Җәлил, Г.Кутуй сугышка китәр алдыннан хөрмәтле өлкән остазлары, каләмдәшләре булган Ш.Камал белән хушлашырга, фатиха алырга килгән булалар. Әлеге фатирның кунак бүлмәсе С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, Ф.Туишев башкарган көйләр моңын, язучы А.Фадеев, Ф.Кәрим, М.Садри һәм башкаларның тавышын саклый. Чыннан да, музей буларак, Ш.Камал фатиры бик күп истәлекләрне торгызырга ярдәм итә.

Бөек Ватан сугышы белән бәйле тагын бер тарих – Шәриф Камалның улы Йосыф Байгильдеевнең язмышы. Рыбинск шәһәрендә урнашкан Г.К.Орджоникидзе исемендәге авиация институты студенты Йосыф Байгильдеев 1942 елның маенда сугышка алына. 1942 елның азагында, яраланып, госпитальгә эләгә. Йосыф 1943 елның апрелендә Донбасс районында барган һөҗүм вакытында һәлак була. Әмма аның вафаты турындагы докуметлар Ш.Камал архивында да, Оборона министрлыгы архивларының моңа кадәр басылып чыккан материалларында да табылмады.

Шәриф Камалның улы Йосыф Байгильдеев

Хатлардагы аянычлы бер хакыйкать: Йосыфның 1943 елның 20 гыйнварында язылган соңгы хатыннан күренгәнчә, апасы аңа госпитальгә язган хатында әтисе Шәриф Камалның үлүе хакында хәбәр итмәгән. Яралы солдатны борчырга теләмичә, якыннарының бу турыда әйтмәве һәм Йосыфның: *«Кадерле әни, әти, Ефрем, Зәйнәп, Эльвира, Валерий! Һәммәгезгә дә күп, кайнар, сагынычлы сәлам. Туган апам! Синең 6.01.1943 язган хатыңны 13.01. алдым. Өйдә барысы да яхшы икәнен белеп, чиктән тыш шатландым»,* – дип язуы әле дә тетрәндерә. Фидакарьлек, сабырлык, батырлык үрнәге булган шәхесләрнең язмышы – авыр сугыш елларының тагын бер чагылышы. Игътибарыгызга музей архивындагы берничә хатны тәкъдим итәбез. Хатлар каләм белән «ачык хат» бланкасына язылган, бик тузган, шунлыктан, кайбер урыннары бик авырлык белән генә таныла. Танылмаган сүзләр урынына күп нокталар куелды. Хатта исемнәре аталган туганнары: Зәйнәп – Йосыфның бертуган апасы, Шәриф Камалның кызы; Ефрем – Зәйнәпнең ире; Эльвира һәм Валерий – Зәйнәпнең балалары.

Беренче хат:

«Кадерлеләрем әти, әни, Зәйнәп, Ефрем, Эльвира, Валерий!

Һәммәгезгә дә кайнар, сагынычлы сәлам. Сезнең 14/IX һәм 8/X язган хатларыгызның килүе миңа дөнья хәтле шатлык китерде. Югыйсә, элек язганча, озак хәбәр булмавы борчый башлаган иде. Үзем исән-сау, яхшы торам. Шушы көннәрдә кышкы киемнәр алдык. Сезнең хатларыгызны алгач та хат яза алмадым, ачуланмагыз, вакыт булмады. ... көннәрдә обстоятельныерак хат язарга тырышырмын. Кечкенә племянникка ифрат матур исем тапкансыз, мин үзем дә нәкъ шундыйны бирер идем. Эльвира шикелле ма-



Йосыф Байгильдеевнең хаты

«Йосыфның 1943 елның 20 гыйнварында язылган соңгы хатыннан күренгәнчә, апасы аңа госпитальгә язган хатында әтисе Шәриф Камалның үлүе хакында хәбәр итмәгән.

турмы? Минем сезгә карата теләкләрем: мин кайтканчы әнинең күзе элекке шикелле булсын, бөтенләй лечить итегез. Әти эшкә бик налегать итеп перетрудиться итә күрмәсен. Барыгызга исән-саулык теләп калып, Йосыф. 30.10.1942 ел».

Икенче хат:

«Кадерле әни, әти, Ефрем, Зәйнәп, Эльвира, Валерий!

Һәммәгезгә дә күп, кайнар, сагынычлы сәлам. Туган апам! Синең 6.01.1943 язган хатыңны 13.01. алдым, өйдә барысы да яхшы икәнен белеп, чиктән тыш шатландым. Минем хәлләр яхшы, осколоклар янтыгыма һәм уң аякка тигән иде (сөякләргә зарар килмәгән). Хәзер көннән-көн төзәлә барам, аяк өсте йөрим инде. Озак ятмам дип уйлыйм (госпитальдә). Яраланганнан соң (мин шактый кыска гына хатлар язган идем) 18.24. ... белән бер хатны гына алгансыз икән. Госпитальдә лечение курсы беткәч, авыр яраланган кешеләргә отпуск бирәләр, мин ул категориягә туры килмим. ... бар икән, кучу исключительныйда гына практиковаться итә. Димәк, мин бирдән частька...

Хушыгыз хәзергә. Сәлам белән, Йосыф. 21.01.1943 ел». ■

Карлыгач оясы

Сәмига Сәүбанова

Матбугат йорты. 1960 нчы еллар

Бауман урамы, 19 нчы йорт. Әле кайчан гына ачык китапны хәтерләткән бу бина республика зыялыларын, әдәбият-сәнгать әһелләрен туплаган иде. Биредә газета-журнал редакцияләре, китап нәшрияты урнашкан. Олпат язучылар белән бергә яңа каләмен чарлый башлаган яшьләр, авыр ишекне ачып, тылсымлы, мавыктыргыч әдәби мохиткә тәүге адымнарын атлыйлар.

Мәрмәр баскычлардан икенче катка менгәч, уң як коридор аша «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналлары, Литфонд, Язучылар Союзы... Яшь каләм ияләренең иҗат җимешләре беренче чирканчыкны шушында ала... Аларның язмаларын олпат язучылар укый, киңәшләр бирә, әз генә иҗат очкыны сизелсә дә, үстерергә тырышып, эшләргә илһамландыра, үсендерә һәм матбугатка чыгарырга матди ярдәм дә күрсәтә...

Талантлы яшьләрне үзләренә алмаш итеп әзерләргә вакытларын җәлләмиләр иде...

Төрле катлардагы редакцияләр аша иң өстәге Тукай клубының сәхнә артында урнашкан машинисткалар бүлмәсенә илтә торган баскыч янындагы мәйданчыкта, стенаны тутырып, «Тылсымлы каләм» газетасы өч-дүрт метрга сузылган. Берберсенең иҗат уңышлары, кайбер гадәтләреннән дусларча көлеп язылган рәсемнәр,

парчалар... Үзе дә әдәбият капусына тәүге адымнарын атлаган Фаил Шәфигуллин редакторлыгында һәм авторлыгында булуга карамастан, өлкәннәр бу аерымлыкны әллә сизә, әллә юк – аның яныннан кеше өзелеп тормый. Чеметеп-чеметеп алса да, яраталар бу гәзитне, үпкәләп йөрмиләр. Чөнки беләләр, үзләренең әсәрләрен укып иҗатка килгән иптәшнең чынлап яратуы гына бар бу язмаларда...

Бу йортка зур өметләр баглап, беренче тапкыр килгәч, мин дә шушы газета янында тукталдым, озаклап укыдым. Хәтергә уелып калганы – Нури Арслановның кызлар яратуы турында иде. Ул чагында бик популяр булып киткән «Нәсимә» җыры кылт итеп исемә төште:

Нәсимә, дия-дия,
Теңкәңә тия-тия,
Язмыштан көлгән чагым,
Утларда көйгән чагым,
Өзелеп сөйгән чагым...
Үзең сөймәсәң сөймә,
Минем сөюгә тимә...

Бу җырны радиодан көн саен тапшыралар, клубта һәвәскәр артистлар башкара, җәйге кичләрдә клубтан кайтканда, яшьләр җырларга ярата. Кая карама, шагыйрьнең мәхәббәтен санга сукмаучы кыз турында җыр ишетелә...

Нәсимә берәү генә, ә монда кызлар турында сүз бара. Кызлар берлек санда түгел, күплек санда бит!

Бу мәйданда Тукай һәйкәле янында, эш арасында тәнәфес ясап, бильярд сугып, бадминтон уйнап та алалар.

Әдипләрне хатыннарыннан башка илһамландыручылары яисә музалары барлыгын ишетеп белә идем. Күптән түгел генә «Яшәү белән үлем арасында» дигән бестселлеры чыккач, Нәби Дәүли дигән «карт» язучының да кызларны бик яратуын ишеткән идем.

Танылган әдипләрнең хатыннарыннан башка иҗатка рухландыручы музалары барлыгын белә идем инде.

Нури аганың илһамчысы да гадәти кыз түгелдер. Тик ничек инде аның мәхәббәтен кабул итмәскә була?

Миңа да шушы данлыклы йортта танылган әдипләр белән эшләргә генә түгел, алар белән аралашып, бәйрәм табыннарында очрашып тәгам җыярга, чәйләр эчәргә дә насыйп булды.

Нәби Дәүли дә, Нури Арслан да, мин уйлаганча, карт түгелләр икән бит! Илленең ар ягына гына чыкканнар, гәүдәләре төз, күңелләре көр, энергияләре бихисап. Хатын-кыз ягыннан да тыйнаклар, гаиләләре өчен үлеп торалар. Тик барыбер аларның читтән генә кызыккан, сокланган, хөрмәт иткән, яраткан илһамчылары – музалары да бар икән! Хатыннары да белә бу турыда, көнләшеп үзәкләренә дә үтмиләр!

Без, Язучылар Союзы, «Идел» альманахы һәм «Казан утлары» журналы машинисткалары утырган сәхнә арты бүлмәсендә нинди генә танылган кешеләр булмады. Тукай клубында төрле чаралар, тантаналы очрашулар үткән чагында да арткы бүлмәдә язу машинкасы тукылдавыннан туктамады. Артистлар киемнәрен алыштыра, ә безнең күтәрелеп карарга да вакыт юк – бармаклар клавишлар өстеннән йөгерә генә. Сәхнәдә уйнаган музыканы дүрт машинка тыкылдавы тулыландыра...

Тукай клубының 50 нче еллардагы күренеше

Күтәрелеп карарга вакыт юк дисәк тә, күз бар бит – кирәген дә кирәкмәгәнен дә күреп өлгерә...

Ә машинисткалардан башка әдәбият кешесенең эше бармый. Яхшы машинистка, җитмәсә, ике телне дә белсә – үзе бер хәзинә инде ул. Нәшриятка роман-повестьларны дәфтәр битләренә генә язып тапшыра алмыйсың. Дөрес, кайбер язучыларның үз машинкалары да бар-барын, ә күпчелек өчен бу тормышка аша торган да, булыр дип өметләнә торган хыял да түгел – картаеп, буыннар каткач, эш белү уңайсыз шул. Алар болай да алфавит алыштыра-алыштыра, үзләштерә-үзләштерә арыган, сугышлар алҗыткан, грамоталары да чамалырак, әмма әйтер сүзләре саллы олпат кешеләр... Без аларның беренче укучылары да. Гадәттә, әсәренең уңышлымы-уңышсызмы икәнен аларга иң беренче без әйтәбез...

Грамоталы машинистка хәреф хаталарын гына түгел, җөмлә кыеклыкларын да төзәтә, әсәрне калыпка кертә...

Халык яратып укыган әсәрләргә башта безнең бүлмәдә бәя бирелә...

Шуның өстенә, җитәкче оешмаларга гозерләр дә була бит. Фатир зурайтырга да, матди ярдәм сорарга да һәм дә бетмәс-төкәнмәс үтенеч кәгазьләрен тотып та безгә киләләр. Әлбәттә, һәр хезмәтнең бәясе булган кебек, безнең өчен дә болар үзенә күрә бер чумара. Өлгермәсәк, эштән соң да калабыз, ял көннәрендә дә киләбез – ул чагында ишекләр теләсә кайчан ачык – ишек төбендә швейцардан башка кеше юк – ял көне эшкә киләсебезне әйтеп, гариза гына калдырабыз.

Ә инде ул хатларның ияләре үз үтенечләрен тормышка ашу сөенечен уртаклашырга безнең янга чәй күчтәнәчләре белән килгәч, тәнәфес ясап, чәй эчәргә дә вакыт табыла...

Әсәрләре үз укучысын табып, аларның уңай фикерләрен ишеткәч тә, әдипләр безгә киләләр. Кем ничек, ә менә язучы халкы яхшы сүзгә аеруча мохтаҗ икән бит. Әсәр аның карынында тугыз ай буе йөрткән бала шикелле генә түгел, баланың карында йөрү срогы билгеле, ә иҗат җимешенең төгәл вакытын берәү дә әйтә алмый. Ул гомер буе башта әвәләнеп тә, бер мизгелдә язылырга, бер мизгел эчендә туып, гомер буе язылырга да мөмкин. Кайбер әдипләрнең беренче укучылары хатыннары булса, күпләренең хатыннарын әсәрнең эчтәлеге түгел, кулга керәсе бәясе дә түгел,

ә бу әсәрне язгач, гаиләсенә зыян килә күрмәве генә кызыксындыра. Күпме асыл ирләр бер гаепсез юкка чыккан заманнан ерак китмәгән әле.

Дөрес, әсәр безнең кулдан үтеп, редакциягә тапшырылгач, тагын җиде иләктән үтәсе бар әле. Авторга гына түгел, аны дөньяга чыгарган редакциянең үзенә дә сүз килмәсен өчен, редактор кабаттан укып, төзәтердәен төзәтә, алып ташлардаен ала, артыграгын кыскарта. Инде бөтенесе дә әзер булып, соңгы имзаны салырга тиешле цензура оешмасыннан үткәч кенә, җиңел суларга була...

Ничек инде тугыз ай гына карынында яткан бала белән чагыштырырга булсын иҗат җимешен?

Бу газапларны, өметләрне уртаклаша-уртаклаша, нәтиҗәсен көтә-көтә, хатын да, балалар да туеп беткән, тиешле гонорарны алгач, үткәнне искә дә аласы килми, якты киләчәк күз алдына килә. Баласын мең газап белән табып, сабыен кулга алгач, аларның барысы да онытыла бит, башка мәшәкатьләр башлана. Ә әсәр авторы һаман да үткәненнән аерыла алмый. Аның шатлыгын-сөенечен уртаклашасы, еллар буе газапланып дөньяга китергән баласыннан да кадерле әсәре, аның уңышлары турында сөйлисе, фикер алышасы, фикер ишетәсе килә... Әйбәт фикерне кабат-кабат тыңласа да, туяр хәлдә түгел ул. Шулай булмыйча, бу көнне күрер өчен күпме газап, күпме әр ишетте ул.

Әсәрең дөньяга чыккач та, бу халәтеңнән тиз генә аерыла алмыйсың әле. Аерыласы килми дә. Тик синең әсәреңнең язылып бетеп, укучысына ирешүен дүрт күз белән көтеп алган гаиләң башка мәшәкатьләр белән яши хәзер. Аның тукталып торырга вакыты юк. Ә син әле һаман да аерылып китә алмыйсың. Әсәреңнең уңышлымы, түгелме икәнен билгеләүче укучылар конференцияләре дә бу бушлыкны тутырып бетерә алмый.

Гадәттә, җитәкченең иң ышанычлы уң кулы – шоферы булса, язучының һәм шул ук вакытта җитәкченеке дә – сәркатибе яисә машинисткасы инде. Барлык документлар аның кулы аша уза. Һәр әсәр, кечкенәме, зурмы, укучыга ирешкәнче әле ручка белән язылган кульязма хәлендә машинистка өстәленә куела, ә аның җитез бармаклары, машинка клавишлары өстеннән йөгерә-йөгерә, билгеле бер калыпка кертә. Хәреф хаталарын төзәтә, килешмәгән җөмләләрне дә тәртипкә кертеп куя. Грамоталы машинистка – язучының хәзинәсе инде ул. Һәм язучы белән ике арадагы дуслык, хезмәттәшлек озакка, гомер буена диярлек сузылуы, кайчагында аның музасына әйләнүе дә һич гаҗәп түгел...

Безнең бүлмәдә дүрт машинистка эшли иде. Каршы өстәлдә Тукай клубы директоры Лариса апа утырды. Дүрт машинка тавышына ничек түзгәндер. Аның сабырлыгына сокланырга гына кала. Ә без, үзебезнең төп эшебездән кала, өстәмә эшләргә дә иренмибез. Анысы – үзебезнең чумара яисә өстәмә керем чыганагы инде. Хезмәт хакыбыз аз булгач, беркем сүз әйтми, хәтта җитәкчеләребез үзләре дә акча түләп эшләтә иде. Эшләгәнебезне яраталар гына иде. Күбрәк эшләгән саен, осталык та арта гына дип исәпләделәр. Китап булып басылгач, үзләренә дә көрәп диярлек акча түләнә торган бәхетле заманнар да бар иде...

Язучы машинисткадан башка яши алмый. Гомумән, бер оешманың да эше, әгәр сәркатибе берәр көн эшкә чыкмый калса, туктап калырга мөмкин. Ә газета-журнал редакцияләре, китап нәшриятларында аларның хезмәте бәһасез. Үзеңнең даими машинисткаң булу ул – шәхси табибың белән бер. Һәм һәр абруйлы язучының, шагыйрьнең, фән кешесенең үзе генә ияләшкән, якын күргән һәм еллар буена кульязмаларының беренче укучысы гына түгел, беренче тәнкыйтьчесе булган кешесе гаилә дустына гына түгел, илһамчысына да әйләнеп куйгалый...

Монда аның гәүдәсенең зифалыгы да, чибәрлеге дә әһәмиятсез. Хәтта әдипнең үзен ярату-яратмавы да мөһим түгел. Ул синең иҗатыңны аңласын, яратсын, фикерен әйтсен. Тәнкыйтьләсен, бәхәсләшсен. Ташка басылганчы төзәтүе мөмкин, ташка басылгач, тәнкыйть ишетүе җиңел түгел. Кайчакта машинистка ошатмаган текстларны яңадан эшләр, тулыландырыр өчен читкә дә алып куярга туры килә…

Язучылар Союзының документлары белән эш итүче Мәдинәбез дә модель кыяфәтле түгел. Ике бала үстерә, эштән бер минут калмыйча балалар бакчасына чаба. Бизәнми, киеме дә гади, җайлы. Тиз йөрергә җайлы булсын өчен, түфлинең дә үкчәсезен кия. Тик бер елмаеп куйса, Софи Лоренның бер читтә торсын! Ияк чокырыннан кояш чыккан кебек тирә-як яктырып китә. Менә шул ияк чокырындагы яктылыктан күзен ала алмыйча, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри, гозерләре үтәлгәч тә, тиз генә китә алмыйлар иде. Ирләренең монда эш белән генә түгел, илһам алырга килүләрен хатыннары да белә, вакыт-вакыт чәй күчтәнәчләре дә җибәрәләр иде…

Мөхәммәт Садри муен асты бизендәге ракны җиңгән кеше, ул, базарда үзе генә белгән үләннәр һәм ул чагында бик авыр табып була торган мумия төнәтмәсе алып килеп, безгә дә авыз иттерә, безнең дә муен тирәләрен сылый, Мәдинәнең кулын, үз учына салып, төнәтмә белән ышкый. Озак кына җибәрә алмый тора, иреннәре белән тиеп тә ала. Бу вакытта ак сакаллы әдипнең күзләрендә – искиткеч ярату, соклану. Аның өчен бергә утырып эчкән чәебезнең кульминацион моменты шушы инде.

Нәби Дәүли дә ярата Мәдинәне. Тик ул шуграк. Икесе бергә туры килгәндә, Мәдинәгә күбрәк игътибар биргән булып, каләмдәш дустын үрти. Ә ул чынлап та үртәлә. Чөнки бу кыска бәхетле минутларын, илһам чыганагын аның утны-суны бергә кичкән дусты белән дә бүлешәсе килми…

Без, яшьрәкләр, әле боларны аңлап та бетермибез. Мөхәммәт абыйның шигырьләре, җырлары белән илһамланып үссәк тә, бер заман ак сакаллы картның мондый сентиментальлеге ешаеп киткәч, Мәдинәгә бу күренешне туктатырга киңәш бирдек. Тыңлады. Икенче тапкыр килгәч, күтәрелеп тә карамады. Әдип ул көнне бездән кояшын югалткандай чыгып китте. Безнең күңелебез булды.

Бераздан минем напарнигым – «Казан утлары» машинисткасы Мәгъмүрә апа Кисловодскига санаторийга киткән җиреннән юл фаҗигасына эләгеп вафат булды. Бу безгә бик авыр тәэсир итте. Аның ире Әхәт абый Шәрәфетдинов – МВД подполковнигы, уллары Рәис, Васил, кызы Гөлнур белән, мин фатир арендалап яшәгән Тихомирнов урамына якын яңа салынган биш катлы йортның бишенче катына күчеп яши генә башлаганнар иде. Баксаң, без үзебез белән иртәгә нәрсә буласын да белмибез икән бит!

Шуннан соң без Мөхәммәт абый алдында гаебебезне төзәттек, якты чыраебызны бүтән жәлләмәдек. Һәм без тагын аның иң якын кешеләренә әвереллек. Хәтта берничә тапкыр аңардан аерыла алмыйча, Мөхәммәт абый Мәдинәне балалар бакчасына кызы белән улын алырга гына түгел, өенә хәтле озатып та куйган иде әле.

Мәдинәнең ире Равил бик тыныч, акыллы кеше, ул да хатынын озаткан олуг шагыйрьне хөрмәтләп каршы ала, хөрмәтләп озата.

Берничә елдан Мәдинәбез заманы өчен төшемлерәк урынга – азык-төлек оешмасына күчте. Мөхәммәт ага музасыз калды. Тик ул барыбер бәхетле гомер кичерде, озак яшәде. Телевизордан бер тапкыр биргән әңгәмәсендә аяклары сызлавын, хатынының бик әйбәт каравын сөйләгәне хәтердә… Ул заманның хатыннары да шагыйрь ирләренең рухи халәтен аңлыйлар иде…

1974 елда безнең редакция Декабристлар урамындагы Казансу елгасы буена урнашкан 14 катлы йортка күченде. Нәби Дәүли әсәрләрен бастырырга бу бинага

Декабристлар урамындагы Матбугат йорты. 1974 ел

килеп йөрсә дә, Бауман урамындагы карлыгач оясын хәтерләткән бүлмәдәге кебек күңелле чәй эчүләр булмады.

Безнең авторлар тормыш тарафыннан иркәләнгән кешеләр түгел – утызынчы еллар шаукымыннан һәм Ватан сугышы фаҗигасыннан исән кала алганнар. Аларны һәр саксыз сүз яралый, куркыта, котын ала. Алар яклауга, аңлауга, җылы сүзгә сусаган. Ә без әдәбият белән үскән, тәрбияләнгән. Үзебез аңламаган сорауларны китаплардан эзләгән һәм тапкан кешеләр. Бу китапларны язучылар безгә пәйгамбәргә тиң һәм аларга табынып үскән, яшәгән кешеләр. Шуңа күрә безнең кышын салкын, җәен эссе булган бу бүлмәгә килергә яраттылар, үзләренең әсәрләренә беренче хәерхакны бездән алдылар...

Сәхнә артындагы бүлмәдә дүрт язу машинкасы шакылдый, ә залда биредә эшләүчеләр өчен генә түгел, вакыт-вакыт республика күләмендәге зур җыелышлар да була. Тамаша залы шыгрым тулы, беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова, ил күләмендә танылган иллюзионист Кио, әдипләр Чыңгыз Айтматов, Әнгам Атнабаев һәм бик күпләрне хәтерли тамаша заллары. Ә сәхнә артында залдагылар өчен Ленин образына керергә Шәүкәт Биктимеров әзерләнә, Таһир Якупов, Венера Шәрипова чыгарга чиратын көтә. Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ та тәүге шигырьләрен шушы залга сөйләде.

Танылган композитор Сара Садыйкова үзенең яңа җырларын иң беренче клуб рояленда уйнап җырлаганы булды.

Ул рояльдә кемнәр генә уйнамагандыр? Танылган композиторлар да, яңа гына көй иҗат итә башлаучылар да. Биредә эшләүчеләрнең музыка мәктәбенә йөрүче балалары да... Пианино бәясе тешне сындырырлык, кибетләрдә дә сирәк күренә. Бәхетең булып, берәрсенең үзеннән артканын таба алсаң гына... Күрше бүлмәдә эшләүче «Совет мәктәбе» журналы машинисткасы Гөләндәм апа улын, дүртенче каттагы «Яшь ленинчы» газетасының әдәби хезмәткәре, журналист, тәрҗемәче Саимә Ибраһимова ике кызын шактый вакыт шушы пианинода музыкага өйрәтте.

Ә бервакыт «Азат хатын» журналисты Эльмира Эдиятуллина, шагыйрьләр Әминә Бикчәнтәева белән Нури Арсланның улы Илдар иҗат иткән җырны шушы пианинога кушылып кат-кат җырлаганнан соң, журналга бирергә яраклы дип тапты.

Кызганыч, без Илдарның башка җырларын ишетмәдек… Ул күзгә-башка күренмичә, тыныч кына яшәде, эшләде.

Нури аганы да, әнисен дә, вакыты җитеп, узып та киткәч, улларының өйләнмичә йөрүе күңелләрен тырнамыйча тормагандыр. Ә минем күңелемнән стенадагы газетадан хәтеремдә калган теге сүзләр истән чыкмый. Журналның поэзия бүлеген җитәкләүче олуг шагыйрьне үртим, яшьләрчә шаяртам:

– Нури абый, улыңа кәләш ит әле, үзеңне буш итмәм, – дим.

Мин аның шигырьләрен чиратсыз җыеп бирүне күздә тотам.

Шаяртуыма күңеле булып елмая, бүлмәдәгеләр исә башка мәгънә салып хихылдыйлар.

Яшь кеше булгач, икенче кат белән бишенче кат арасында мине йөгертәләр, эш алырга көненә бу араны ничә тапкыр урыймдыр.

Нури аганың 60 еллык юбилее якынлашты. Кичә Г.Камал театрында үткәрелергә тиеш. Гадәттә, театрда дүшәмбе – ял көне, зал буш, димәк. Әдипләрнең мондый кичәләре шул көнне үткәрелә.


Нури Арсланов

Гадәттәгечә, шаяртам:

– Мин залдан чәчәкләр тапшырырмын да халык алдында пәп итәрмен. Көнләшсеннәр әле сине яратып йөрүчеләр! – дим.

Андый чәчәк букетларын, гадәттә, оештыручылар һәм автор үзе оештыра. Миңа андый тәкъдим булмады, эштәгеләр дә моны кирәксенмәделәр бугай. Тик шагыйрь котлаулардан соң залга борылып-борылып карагач, минем шаяртуымны чын итеп кабул иткәнлеген берәрсе аңлады микән?

Кайчагында ул безнең «карлыгач оясы»на менә, бераз сөйләшеп утыра.

Сафия апа белән Мәгъмүрә апа озаграк эшләгән кешеләр, алар аның гаилә тормышын яхшы беләләр. Танылган шагыйрә Әминә ападан киткәч, үзеннән олырак марҗа хатыны белән яшәвенә гаҗәпләнәләр. Ә ул сәбәбен бик гади итеп аңлатты:

– Мин аңа башта фатирга кердем бит. Тотнаклы булды. Шул сыйфаты белән үзенә бәйләде инде.

Марҗа хатыны белән Камал театрында күргәнем дә булды аларны. Кыяфәте затлы, үзен тотышы күркәм иде ул хатынның. Шуңа күрә «Тынгысыз каләм»дә аңардан ни өчен шаяртканнарын башта аңламадым әле. Тик соңыннан сәбәбен төшендем. Бик тиз популярлашып киткән җырның прототибы, чынлап та, шул исемдәге кыз булган икән! Ә ул язучылар оешмасының китапханәсендә эшләгән.

Мин ул кызны бер тапкыр да күрмәдем, кияүгә чыгып башка шәһәргә күченгән иде. Тик нинди дә булса сәбәп белән бергә җыелып утырган чакларда «Нәсимә» җырын җырламыйча калмыйбыз һәм моңа шагыйрьнең күңеле була иде. Нинди дә булса каналлар аша аның тормышыннан да хәбәрдар иде…

Ул заманда пенсия яшенә җиткәч, эшләргә рөхсәт ителми, эшлисең икән, пенсия түләнми иде.

«

Марҗа хатыны белән Камал театрында күргәнем дә булды аларны. Кыяфәте затлы, үзен тотышы күркәм иде ул хатынның.

60 яшьлек кенә сәламәт ир-ат эшсезлекне ничек кичергәндер, яңа шигырьләре-җырлары да бүтән булмады шикелле. Тик ул эшләп киткән коллективын сагынды, берничә тапкыр ирләр кучтәнәчләре белән «Казан утлары» егетләре янына да килде. Бер тапкыр аны күргәч, гадәтемчә, улы белән кызыксынып, шаяртып та алдым әле. Ул үпкәләмәде.

– Һаман буйдак әле, ичмасам, үзеңә дә өйләндермәдең, – дип, авыр сулады.

Миннән генә тормады шул, гадәттә, без башка тәрбия белән үскән. Егет үзе башлап дәшсә генә, җавап кайтара идек.

Татар ашлары йорты бинасында ниндидер табынга Илдар белән кызы да килгән иде. Икесе дә гаилә кормаган кебек иде әле. Әле менә яңарак кына кызыксынып, интернет челтәрендә актарына торгач күрдем – Илдар Мәдәният академиясендә укыта, матур гына гаиләсе дә бар икән. Сөендем...

Егетләрнең, эшләрен онытып, Нури ага белән чәйләп утыруы озаккарак сузылып, тагын да ешаеп китүеннән куркып, редактор Ренат Харисов Нури агага башка эшләреннән аерып йөрмәскә кушып кисәтү ясагач, Кояш Тимбикова:

– Бездән башка кая килсен инде? – дип аптыраган иде.

Нури ага редакциядә бүтән күренмәде...

Картлык көннәре күңелле булмады дип ишетелде.

Ул елларның афәте булган эчү марҗасын нык эләктергән, диделәр... Марҗа алданрак китте, ә Нури аганы Әминә Бикчәнтәева янына үзебезнең дин буенча җирләделәр...

Биредә әдәбият укып үскән, аңа чын күңелдән гашыйк кешеләр генә эшләде. Очраклы кешеләр бездә озак тоткарланмый иде.

Ә безнең өчен өлкән әдипләр пәйгамбәрләргә тиң, алар безнең янга кульязмаларын машинкада бастыру өчен генә түгел, иҗатларына этәргеч, якты йөз, тәмле сүз эзләп тә килгәннәр икән бит.

1974 елда Казансу аша салынган күперне чыккач ук Декабристлар урамы башланып киткән урында яңа Матбугат йорты төзелгәч, редакцияләрнең күбесе шул бинага күчте. Ә ул бинада калганнарга йорт иркенәеп, бүлмәләр бушап калды. Без утырган сәхнә арты бүлмәсе дә үз функциясен генә үти башлады. Лариса апа пенсиягә чыкты, аның урынына калган шагыйрь Әхмәт Рәшитов аны чын-чынлап кабул итү бүлмәсенә охшатып җиһазландырды...

Еллар үтте, заманалар үзгәрде. Халыкның рухи мәркәзе булган ул бинага бөтенләй башка вазыйфа йөкләнде хәзер...

Ноябрь, 2019 ел ■

«Ногай» кунакханәсе. 2019 ел

Истә, һаман да истә!

Язучы
Нәби Дәүлинең
тууына 110 ел



Шагыйрь һәм прозаик Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) 1910 елның 1 июнендә элекке Казан губернасының Спас өязендәге (хәзерге Татарстанның Әлки районы) Мәүләшә (Иске Камка) авылында туган.

Н.Дәүли Бөек Ватан сугышы башлануга фронтка китә, әмма 1941 елның августында Орша тирәсендә барган авыр сугышларның берсендә дошманга әсирлеккә эләгә һәм 1942 елның яз башында Германиягә озатыла. 1945 елның апрелендә ул лагерьдан кача, совет гаскәрләренә кушыла һәм сугышны фронтта тәмамлый.

Н.Дәүли – 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, «Яшәү белән үлем арасында» (1958), «Җимерелгән бастион» (1965) дигән әсәрләр авторы.

Әдип 1989 елның 18 маенда Казанда вафат булды.

Балет артисты
Бари Әхтәмевнең
тууына 110 ел



Балет артисты, ТАССРның атказанган артисты (1945) Бари (Габделбари) Шәрифҗан улы Әхтәмев 1910 елның 7 (19) июнендә Казанда туган.

1930-1934 елларда ул Татар академия театрында биюче. 1939-1969 елларда – Татар опера һәм балет театры артисты.

1945 елның 8 мартында «Шүрәле» (Ф.Яруллин) балетының премьерасы уйнала. Анда Гали батыр ролен Бари Әхтәмев башкара. Соңыннан ул Шүрәле ролен уйнап дан казана. Б.Әхтәмев башкарган кайбер рольләр: Нур («Зөһрә», Н.Җиһанов), Гали бай («Алтын тарак», Ә.Бакиров), Зигфрид («Аккош күле», П.Чайковский) һ.б.

Б.Әхтәмев 1999 елның 17 гыйнварында вафат булды.

Драматург
Шамил Шаһгалинең
тууына 100 ел

Драматург Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев 1920 елның 9 июнендә Башкортстанның Чакмагыш районындагы Калмашбаш авылында крәстиян гаиләсендә туган.

1962-1964 елларда ул Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби һәм 1966 елда «Мосфильм» киностудиясе каршындагы режиссерлык курсларын тәмамлый.

Ш.Шаһгали «Бала бәхете – ана бәхете» исемле беренче пьесасын 1955 елда яза. Аның 1956 елда иҗат ителгән «Таң атканда» пьесасы (1956) 1959 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела.

Ш.Шаһгали 1962 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Ул 1987 елның 15 гыйнварында вафат булды.

Шагыйрь
Әнәс Кариның
тууына 100 ел

Шагыйрь Әнәс Кари улы Кари (Кариев) 1920 елның 11 июнендә Азнакай районының Уразай авылында туган. 1939 елда Үзбәкстанның Үргәнеч шәһәрендәге укытучылар институтын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң башта – Арча педагогика училищесында, аннары Питрәч районына керә торган Янсуар урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Ә.Кариның кайбер китаплары: «Балаларга бүләк» (1947), «Гөлбакча» (1948), «Күңелле ял» (1951), «Дуслык» (1953), «Беренче адымнар» (1954), «Тамчы һәм чишмә» (1985) «Тамчы тамганда» (1990) һ.б.

Язучы 1954 елның 4 апрелендә вафат булды.

Язучы
Гомәр Галинең
тууына 120 ел

Язучы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Билал улы Гали (Галиев) 1900 елның 16 июнендә хәзерге Татарстан Республикасының Буа районындагы Иске Тинчәле авылында игенче гаиләсендә туган.

1925 елда Гомәр Гали – «Безнең юл» журналының баш мөхәррире, 1927 елда исә ул Татарстан дәүләт китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире итеп билгеләнә.

Репрессияләр шаукымыннан Гомәр Гали дә котылып кала алмый – 1937 елның 9 мартында кулга алына.1947 елның 10 мартында срогын тутырып иреккә чыга, әмма 1949 елның 23 июнендә янәдән кулга алына.

Әдип 1954 елның 5 июлендә, сөргендә чакта, фаҗигале рәвештә вафат булды.

Актриса
Һаҗәр Шәкүрованың
тууына 80 ел

ТАССРның атказанган (1979) һәм Татарстанның халык артисты (1999) Һаҗәр Закир кызы Шәкүрова 1940 елның 26 июнендә Саба районының Олы Саба авылында туган. 1964 елда Республика күчмә театрында (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында) эшли башлый.

Һ.Шәкүрова тудырган иң матур рольләрнең берсе – Мостай Кәрим әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Айгөл иле» спектаклендәге Айгөл образы. Артистка башкарган рольләрнең кайберләре: «Хаҗи әфәнде өйләнә»дә (Ш.Камал) – Камилә, «Гармун уйный беләсеңме?»дә (Т.Миңнуллин) – Мәрзия, «Җаным җәл түгел сиңа»да (Г.Зәйнашева) – Зөһрә, «Сары чәчәк ата көнбагыш»та (А.Гыйләҗев) – Лира...

Һ.Шәкүрова 2019 елның 26 июнендә (нәкъ туган көнендә) вафат булды. ■

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

Борынгы татар милли музыка уен кораллары

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Үзләү

Алтай үзләүчесе дәрес бирә

Борынгы заманнарда ыру-кабиләдә килеп туган күптөрле аңлашылмаган хәлләрне җайга салу эшләрен имчеләр, күрәзәчеләр, шаманнар, нинди дә булса уен коралына кушылып, үзләү, камлау, ягъни транска кереп ияләр белән сөйләшү аша башкарганнар. Үзләү – шулай ук камлауның, ягъни Тәңре, Ходай белән сөйләшүнең алыштыргысыз бер ысулы. Итальян галиме И.Вандер: «Үзләү» яки буддизмдагы «Ян» Тәңре белән сөйләшү, аралашу өчен хезмәт итә. Ә аллалар белән кеше белән сөйләшкән кебек сөйләшеп булмый», – ди. Тамак төбеннән чыккан тавыш (гортань) ярдәмендә төрле кош, җәнлек, табигать тавышларын чагылдырып була. Ул «үзләү», «гүзләү» (горловое пение) дип атала.

Үзләү татар тормышында, һичшиксез, булган. Аны нинди дә булса уен коралына кушылып та, аерым гына да башкарганнар. Ул шулай ук музыкага тормыш-көнкүрештән килеп кергән. Элек нинди дә булса уен коралында уйнап, үзләү алымы белән халыкның батырлыгы турында каһарман җырлар җырланган, батырларны

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

мактап тулгау әйтелгән, риваятьләр сөйләнгән. Яхшы үзләүче, имчеләр кебек үк аерым бер камлау көченә ия булып, уен коралына кушылып камлаган. Үзләүче уен коралын тере, изге итеп күргән, аның белән сөйләшкән. Аның тавышы һәр кешенең йөрәгенә барып ирешсен, тавышы беркайчан да бетмәсен өчен, уен коралын кымыз һәм башка эчемлекләр белән сыйлаган. Үзләүче, башта уен коралына кушылып, үзенең җыруын ияләргә багышлаган, аннан соң инде, уйнамыйча гына, үз тавышы белән үзләгән, тыңлаучыга җиткергән. Уен коралларына килгәндә, кубыз, кыл-кубыз, ятаган, дөңгер – шундыйлардан.

Көндәлек тормышта үзләү, гүзләү алымы уен коралларына караганда иртәрәк килеп чыккан булырга мөмкин. Чөнки гүзләү сүзеннән «гөслә», камлау сүзеннән «камуз» уен коралларының килеп чыгышы – моңа ачык мисал.

Электән үк күп кенә Аурова галимнәре Россиягә сәяхәтләре вакытында Идел-Урал буйларында яшәүче татар-башкорт халык җырларына игътибар иткәннәр. Сузып җырлана торган мондый озын моңлы җырлар, көйләр кешене йоклату, сихерләү, авыру кешеләрне дәвалау көченә ия икәнен дә белгәннәр. Шуңа да татар көйләрен, заманга яраклаштырып, музыкотерапиядә куллану бер дә гаҗәп түгел. Ауропада Рудольф Штайнер мәктәпләре бар. Анда балага, 9 яшькә кадәр дөрес тәрбия формалашсын өчен, пентатоник музыка тыңлаталар.

1993 елда «Сорнай» ансамбле Ауропаның унике илендә узган II Халыкара этномузыка һәм музыкотерапия симпозиумында катнашты. Вена һәм Истанбул университетлары оештырган «Дуслык күпере» дип аталган әлеге симпозиумның безне таң калдырган үзенчәлеге шунда: ул пентатоник музыкага нигезләнгән иде. Дөрестән дә, пентатоникадагы биш тавыш – чын табигать тавышлары. Пентатоника һәм үзләү аша бик тиз транска кереп була. Шуңа да музыка терапиясендә пентатоник көй уйнау бик мөһим.

Күрсәтмә сеансларның һәрберсе дә татар халкының «Каз канаты», «Иркәм», «Ачма тәрәзәңне», Әгъзам Фәттахның «Әгәр син булмасаң янымда» дигән җырлары аша башкарылды. Һәр семинар барышында йөзләгән Ауропа кешесенең транска керүен, музыкотерапия сеанслары алуын күрү безне бик нык гаҗәпләндерде. Чөнки аңа кадәр мондый сәнгать төренең бар икәнен күз алдына китерми идек әле. Симпозиум Әхмәт Ясәви, Мәүлана, Хаҗи Бикташ Вәли һәм башка күренекле суфичы галимнәрнең эшчәнлеге нигезендә алып барылды.

Кеше табигать биргән сынаулар алдында чарасызлыктан Тәңрегә, Ходайга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була, ярдәм сорый. Ә бит хәзер дә медицина дәвалый алмый торган күптөрле чирләрдән коткара алырдай имчеләр, күрәзәчеләр, багучылар бар. Шулай ук Коръән аятьләре дә шундый ук көчкә ия.

Унике томлык «Йола һәм уен җырлары» китабына да, төрле авыруларны куу өчен, зәхмәт теле, уңыш теләү кебек, барлыгы 20ләп шундый йола үрнәкләре кертелгән. Алар – шаманлыктан сакланып калган ядкәрләр.

Үзләү ул, гаять үзенчәлекле катлаулы сәнгать төре булып, бик тирән, фәлсәфи мәгънәне аңлата һәм җыр сәнгате төренә карый. Монда күптөрле резонатор нокталарын (тамак, күкрәк, аңкау, борын, маңгай һ.б.) файдалана белергә кирәк. Үз-үзең белән сөйләшү – «үзләү» ярдәмендә, үзләүче төрле табигать серләрен, кешеләрнең, хайваннарның эчке дөньясын аңларга һәм тыңлаучыга да моны аларның авазлары аша аңлатырга тырыша.

Төрки дөньяда үзләүнең дистәләрчә башкару алымы кулланыла. Шуларның иң кулланыла торганнары – тыва телендәге «хөмей», «каргыра», «сыгыт» төрләре. Татар һәм башкорт телләрендә исә, барысын да берләштереп, «үзләү» яисә «гүзләү», диләр.

Рус телендә бу «горловое пение» дип йөртелә. Үзләүнең барлык төрләрен дә башкару өчен, башта тын юлы аша узган һаваны туктата белергә кирәк. Үпкәдән алып авыз-борын куышлыгына кадәрле тын юлында һава агымын өч урында туктатып була. Беренчесе күкрәк белән ашказаны арасында – иң түбән тавыш, икенчесе нәкъ күкрәк турысында – урта регистрда, өченчесе борын төбендә – югары регистрда.

«Сорнай» ансамбле солисты Сәйдәш Гыйләҗев

Хөмей – хырылдап чыккан бик түбән обертонлы, фәлсәфи, дини тавыш. Имче һәм күрәзәчеләр аны аллалар белән сөйләшү, кешенең эчке дөньясына үтеп керү, багу, батырларга дан җырлау кебек максатларда кулланган.

Әлеге алымда һаваны тирән итеп эчкә алабыз да көчле итеп, «һэн», дип, һава юлын күкрәк асты клапаныннан ябып куябыз. Нәтиҗәдә, авыр әйбер күтәргәндәге кебек, тын юлында зур көчәнеш хасил була. Ябык клапанның бер кырыен аз гына ачып, һаваны тышка чыгарабыз. Күп тапкырлар кабатлаганнан соң, ниһаять, сез кирәкле югарылыктагы, хырылдап өзлексез яңгыраган тавышны таптыгыз. Шушы тавышның яңгырашын, югарылыгын үзгәртмичә, бер үк вакытта сак кына сулыш юлы куышлыгын (тамак төбеннән алып үпкәгә кадәрге ара) киңәйтеп-тарайтып, шулай ук авызны да ачып-ябып, тавышның тембрын көйлибез. Тавыш югарылыгы көчәнүнең көченә карап көйләнә.

Каргыра – карлыккан аваз чыгару. Әйтик, бәлагә юлыккан үгез мөгрәве, үлгән баласына карап, чарасызлыктан кычкырган дөя тавышы, төрле авазлар чыгарып хәбәр биргән карга, козгын, кәккүк кычкырулары һәм тагын бик күп авазлар, мизгелләр халыкка бик нык тәэсир иткән.

Каргыра алымында тавыш хасил булу нәкъ хөмейдәге кебек. Аермасы бары тик шунда: биредә кирәкле тавыш күкрәк клапанында хасил була һәм урта диапазоннарда башкарыла. Ә инде авыз куышлыгы, иреннәр, тел, аңкау ярдәмендә югары обертоннарда, кубызда уйнаган кебек, тавышның тембрын көйләп була.

Сыгыт «сызгырт, сыгылу» дигән мәгънәдә тәрҗемә ителә. Үзләүче сыгыт алымы аша үткәннәрне, үлгәннәрне сагынып, алдагы көннәр турында хыялланып, сызгыруга охшаган югары обертонлы авазлар чыгара. Биредә аваз борын төбендәге клапан аша хасил була һәм авыз куышлыгы ярдәмендә «ө», «ү» хәрефләрен әйтеп башкарыла. Оста үзләүче бер үк вакытта берничә аваз да чыгара ала. Әйтик, өзлексез каргыра авазы яңгырап торганда, югары обертонда (сыгыт алымы аша) көй башкарып була. Авыз куышлыгы акустика, резонатор булып тора.

Соңгы елларда үзләү татар фольклор һәм эстрада концертларында сәхнәләрдән дә ишетелә башлады. Сыйфатлы, дөрес итеп башкарган үзләү беркемне дә битараф калдырмый. Ул татар музыкасын бары баета, тарихыбызны яңарта гына. ■

«Галиябану» спектакле: ике Хәлил, ике Галиябану

Галиябану – Марзия Миңлебаева,
Хәлил – Хәким Сәлимҗанов.
1937 ел

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

Галиябану – Илсөя Төхфәтуллина,
Хәлил – Рамил Төхфәтуллин.
1991 ел

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

Татарстан артистлары Башкортстанда. 1988 ел

1987-1997 еллар

■ 1988 елның 20-21 декабрендә беренче тапкыр «Татар җыры» конкурсы уза. Аны гамәлгә куючылар – ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты, ТАССРның Мәдәният министрлыгы, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, «Песня и милосердие» театр студиясе.

■ 1989 елда конкурс Бөтенсоюз конкурсы дип игълан ителә. Аның лауреатлары һәм дипломантлары – Венера Ганиева, Идрис Газиев, Гөлнәзирә Талипова, Нәзиф Арсланов, Салават Фәтхетдинов, Георгий Ибушев, Асаф Вәлиев, Зөһрә Шәрифуллина, «Сабантуй» һәм «Гүзәлем» ансамбле.

■ 1993 елда конкурс «Халыкара конкурс» статусы ала. 1997 елда ул күренекле композитор Сара Садыйкованың тууына 90 ел тулуга багышлап уздырыла.

■ 1988 елда Татарстан Республикасы җыр һәм бию ансамбле «Халыклар Дуслыгы» ордены белән бүләкләнә.

■ Ансамбль 1987 елда – Япониядә, 1988 елда – Йәмән Республикасында, 1989 елда – Германия Федератив Республикасында һәм Финляндиядә, 1991 елда Төркиядә гастрольдә була.

Сулдан уңга: Равил Шәрәфиев, (билгесез), Раушания Шәрәфиева, Хәйдәр Бигичев, Римма Ибраһимова, Рафаэль Сәхәбиев, Алмаз Имаев, Зөһрә Сәхәбиева, Ганс Сәйфуллин. Казан, Ирек мәйданы. 1983 ел

■ 1991 елның 15 февралендә Җыр һәм бию ансамбле мөстәкыйль иҗат коллективы булып эшли башлый, филармония составыннан чыга.

■ 1992 елның 9 ноябрендә Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе итеп Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров билгеләнә.

■ Филармония 1992 елда Татарстан Композиторлар берлеге башлангычы белән үткәрелгән Халыкара «Европа-Азия» фестивалендә актив катнаша. 1996 елдан фестиваль Казанда ике елга бер тапкыр үткәрелә башлый. Ул Мәскәү, Чаллы һәм башка шәһәрләрдә дә уза.

■ 1993 елда Татар дәүләт филармониясе составында Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестры эшли башлый. Оркестрның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижер – Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Анатолий Шутиков.

Оркестр белән төрле елларда дөнья һәм Россия күләмендә танылган башкаручылар; Татарстанның күренекле җырчылары Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Юрий Борисенко, Галина Ластовка, Георгий Ибушев, Рөстәм Маликов, Резеда Галимова, Айдар Фәйзрахманов һ.б. чыгыш ясый.

■ 1994 елда Музыкаль-әдәби лекторий бүлеге үзгәреш кичерә: ул «опера һәм камера музыкасы бүлеге» кимәлендә эшли башлы. Аның җитәкчесе Татарстанның халык артисты Владимир Варшавский була.

■ 1997 елда Татар дәүләт филармониясе оешуга 60 ел тула. Юбилей уңаеннан, Илһам Шакиров башлангычы белән, филармония музее ачыла.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Татар тарихи лексикологиясенә бер караш

Миңнира Булатова, филология фәннәре кандидаты

Археолог А.Окладников (сулда) Америка һиндиләре 20 мең еллар элек Көнчыгыш Себердән, Беринг җирләре буйлап Азиядән Төньяк Америкага күчкән дип фаразлый.

Лингвистикада, хәзерге телләрнең төзелешен һәрьяклап тикшерү белән бергә, телнең тарихи лексикологиясен өйрәнү дә әһәмиятле фәнни юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Тарихи лексикология телнең лексик составында күп гасырлар дәвамында барлыкка килгән үзгәрешләрне өйрәнә. Татар галимнәре Р.Г.Әхмәтьянов, Ә.Г.Кәримуллин, В.Х.Хаков, М.З.Зәкиев, Р.А.Юсупов, Ф.С.Сафиуллина, Ф.М.Хисамова һ.б.ның туган тел тарихын, аның сүз байлыгын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре билгеле.

Соңгы вакытта филология фәннәре докторы, профессор Дария Бәйрәм кызы Рамазанова тарафыннан татар лексикологиясенә багышланган берничә китап чыгарылды: «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика», «Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре», «Татар тарихи лексикологиясенә материаллар». Болар барысы да, туган телебезнең байлыгын, тирәнлеген күрсәтү белән бергә, аның тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле хезмәтләр.

Тел тарихын өйрәнү бик күп көч куюны сорый. «Татар тарихи лексикологиясенә материаллар» хезмәтендә Д.Б.Рамазанова татар теленең лексик системасы, аның төп лексик фонды формалашу процессын тарихи аспектта мондый чорларга бүлеп өйрәнергә мөмкин дип саный:

1. Ностратик чор: безнең эрага кадәр 11 мең еллар элек.

2. Бабаалтай чоры: X меңьеллыкта, безнең эрага кадәр VI меңьеллыкта бабаалтай берлеге тунгус-маньчжур, корея-япон, төрки-монгол төркемнәренә бүленгән.

3. Монгол теле: безнең эрага кадәр IV меңьеллыкта төрки һәм монгол төркемнәренә аерылган.

4. Бабатөрки чор: америка һиндиләре, шумерлар, хеттлар, скифлар, этрусклар, аланнар.

5. Бабаболгар һәм болгар телләре: безнең эрага кадәр III-II гасырлардан.

6. Борынгы төрки чор: безнең эраның 7-9 йөзләре.

7. Болгар-татар чоры.

Әлбәттә, бу шартлы бүленеш. Тел тарихына караган материаллар, эзләнүләр арта барган саен, әлеге бүленешкә үзгәрешләр керергә мөмкин. Ностратик телләргә түбәндәгеләр керә.

Һинд-европа гаиләсе. Моңа һинд, иран, славян, балтыйк, герман, кельт, роман, грек, албан, әрмән телләре карый.

Урал гаиләсенә фин-угыр, самодий төркемнәре һ.б. керә.

Семит-хәмит (афроазиат яки афроазия) **гаиләсе**. Бу гаилә бик күп тел төркемнәреннән һәм аерым телләрдән тора. Шулардан төрки телләргә туры мөнәсәбәте булганнары – гарәп һәм иврит телләре.

Алтай гаиләсенә монгол, төрки, тунгус-маньчжур төркемнәре керә.

Картвель гаиләсе Кавказда таралган картвель, абхаз-адыг, дагыстан һәм башка төркем телләрен үз эченә ала.

Дравидий гаиләсенә Көньяк Азия субконтиненты халыклары телләре карый.

Телләрнең барысы өчен дә уртак булган меңгә якын сүз һәм грамматик элементлар ностратик чорда ук булган дип фараз ителә [Иллич-Свитыч, 1971, 1976, 1984]. Алар кеше һәм аның көндәлек эшчәнлеген, табигый шартларны белдерәләр. Мәсәлән, *карын, куен, тел, ал, яка, яту, кисү, кору, бору/борау, чалу, моң, ир, килен, кода* һ.б.

Сыйфатлар, урын-вакыт төшенчәләре белән бәйле төркемнәр дә ностратик сүзлектә үк теркәлгән. Билгеле, әлеге төркем сүзләр икенче дәрәҗәдәге сүзләр һәм аларның ясалуы, формалашуы тормыш-көнкүрешнең билгеле бер кысага керүе белән бәйле.

Д.Б.Рамазанованың хезмәтендә ностратик сүзлектә (Иллич-Свитыч, 1971, 1976, 1984) теркәлгән һәм татар теле белән дә уртак булган лексемаларның бер өлеше генә китерелә. Иң әһәмиятлесе шул: ностратик характердагы лексемалар, фонетик күренешләр табыла һәм ностратик телләр дә арта тора.

Бабаалтай чоры безнең эрага кадәр X меңьеллыктан VI меңьеллыкка кадәр булган араны алып тора. Алтай чоры уртаклыгына мисаллар шулай ук шактый табыла.

Алтай телләре берлеге чорына карый торган лексиканы барлау өчен, борынгы төрки тел, тунгус-маньчжур һәм монгол телләре өчен уртак булган, шушы өч төркемнең барысында да табылган сүзләрне ачыклап карарга булдык.

Кешенең тән төзелеше белән бәйле сүзләр тотрыклы, чит телләр йогынтысына бирешми торган сүзләр төркемен тәшкил итәләр. Хезмәттә кеше белән бәйле 250ләп сүз тикшерелгән, шуларның 217се гомумалтай чоры лексикасы булуы мөмкин [Рамазанова, 2016]. Карап чыккан сүзләрнең бер өлеше ностратик сүзлектә үк теркәлгән.

Туганлык атамалары *(ир, килен, кода, кияү, хатын, кодагый, апа, ага/ака, бабай, авага, ав, ака, мама, ама, энин, әче, ачи, әҗи/эди, авус, ата, катук, катуган, ыру/уру* һ.б.) шулай ук алтай чорыннан ук килә булса кирәк.

Көнчыгыш телләр белән уртаклык семантик параллельләрдә дә табыла.

Алтай берлеге чорында – безнең эрага кадәр IV меңьеллыкта төрки һәм монгол төркем телләре аерылган дип санала. Төрки һәм монгол телләрендәге уртаклыклар хәзергә кадәр сакланып киләләр.

Археолог А.Окладников **Америка һиндиләре** 20 мең еллар элек Көнчыгыш Себердән, Беринг җирләре буйлап Азиядән Төньяк Америкага күчкән дип фаразлый. Еллар үтә торгач, алар Американың төрле төбәкләренә таралган. Америка һиндиләренең телендә төрки сүзләр турындагы мәгълүматлар шактый. Академик Ә.Г.Кәримуллин, аларны җыеп, җитди хезмәт язып чыга, сүзлекләрен китерә: *wata* – вата, *koda* – иптәш, *кан* – кан тамыры, *ми* – мин, *ик* – ике һ.б.; майа һиндиләрендә: *йаш* – яңа, яшел, *кун* – кояш (борынгы төрки телдә *көн* – шулай ук), *ош* – өч, *ак* – ак, *чапак* – бик матур, *чул* – су, *чалан* – елан, *шаган* – агач, чаган, *билим* – белем, *токмек* – тукмак, *вел* – белү һ.б.; кечуа һиндиләре телендә: *ина* – әтисенең апасы, *кок* – һава, күк йөзе, *миси* – мәче, песи, *ари* – ябык, *пак* – бак, кара һ.б. [Каримуллин, 1995, с. 25].

Тематик яктан Америка һиндиләренең тормыш-көнкүреш белән бәйле туганлык атамалары, тән төзелеше, кешенең эшчәнлеге, кием-салым, үсемлекләр, хайваннар, аш-су, алмашлыклар, саннар, тормыш-көнкүреш, табигать, сыйфат, рухи тормыш һ.б. бөтен төркемнәрдә дә табыла.

Бабатөркидә икенче тел – **шумер теле.** Алар хәзергә билгеле булган иң борынгы төркиләр дип санала. Алгы Азиядә борынгы төрки ареаллар булу топонимнар белән дә раслана. Урта һәм Алгы Азиядә төркиләрнең безнең эрага кадәр күп мең еллар элек яшәвен раслый торган мәгълүматлар Библиядә дә (б.э.к. III-II гасыр), Корьәндә дә (VII гасыр) бар. Соңга таба шумерларның бер өлеше аккадлар тарафыннан йотыла [Зәкиев, 2008, б. 128-132].

Антропология мәгълүматларына караганда, шумерлар европеоид расаның Балкан-Кавказ җирле төркеменә керә. Алар безнең эрага кадәр IV-III меңьеллыкларда Тигр һәм Ефрат елгалары арасында беренче дәүләт төзегән, чөй язуны уйлап чыгарган, 15 мең чамасы язулы плитәләр калдырган һ.б. Шумер теле Ф.Р.Латыйпов (шумер, этруск телләрендәге текстларны тәрҗемә итүче), Р.Г.Әхмәтьянов, О.Сөләйманов һ.б. тарафыннан өйрәнелгән. Язма чыганаклар безнең эрага кадәр II меңьеллыкта семит телләренә нигез салган аккад теле өчен субстрат катлам булып калган дип санала.

Ф.Р.Латыйпов, этруск һәм шумер телләренең сүзлек составын, фонетик һәм морфологик уртаклыкларын өйрәнү барышында, аларның төрки телләр (шул исәптән Казан татарлары теле) белән дә уртаклыгын күрсәтә: төрк. *узба* (рус. изба, дом с крышей) – тат. ызба, өй һ.б. [Латыпов, 2009, с.13-16].

О.Сөләйманов төрки һәм шумер телләренең чагыштырма таблицасын төзегән. Шулардан кайберләрен китерәбез: *ада* – ата, *ама* – ана, *ту/туу* –тудыру, *мен* – мин, *еш* – өй, *ешик/есик* – ишек, *тибир/дебир* – тимер һ.б. [Сулейменов, 1975, с. 239-242].

Этрусклар безнең эрага кадәр I меңьеллыкта Апеннин ярымутравының төньяк-көнбатышында яшәгән. Аларны А.М.Немировский, В.Брайзенштейн (1937), Адиле Аида (1988, 1992), Ф.Р.Кляшторный (1983) һ.б. өйрәнгән.

«Ветхий завет»тагы мәгълүматлардан чыгып, Ф.Р.Латыйпов төркиләрнең иң борынгы бабалары Иафет, аның улы Гомер, аның улы Тагирма (Тогарма) булган дип яза, «Таг исемле кешедән килеп чыккан халык» дип тәрҗемә итә. Тага халкы үзенең бабалары итеп безнең эрага кадәр XI-IX гасырларда Кече Азиядән күчеп килгән этрускларны санаган, алар үзләрен тарк, треклар, тиреннәр дип атаганнар [Латыпов, 2009; с.220; Рамазанова, 2016, б.220].

Этрусклар телендә үк булган сүзләргә мисаллар: *ез* – күз, *ел* – кул (әл борынгы төрки телдә – *кул*), *кеше/еш* – кеше, *мейт* – мәет, *килеш* – кылыч, *табле* – табын, *акыл* – акыл, *туника* – кием, *ипа* – ипи, *фирин* – бәрән, *фарси* – барысы да, *хара* – кара, *хасил* – кызыл, *хан* – кан, *туз* – тоз һ.б. Бу телдә татар теле белән уртак тамырлар байтак.

Хеттлар. Хетт патшалыгы безнең эрага кадәр 18-12 йөзләрдә Кече Азиянең урта һәм көнчыгыш өлешендә яшәгән. Хеттлар терлекчелек, ат һәм сыер асраучылык белән шөгыльләнгән [Десницкая, 1952. с.3-35]. Хетт телендәге кайбер сүзләр: *атта* – ата, *анна* – ана, *ит* – үт (фигыль), *каруйли/карили* – кары (карт), *аис* – авыз, *салу (сылу)* – хатын-кыз, *аззик* – азык, *кайсу* – кайсы, *уту* – кояш (ут) һ.б.

Скифлар безнең эрага кадәр VIII-III йөзләрдә Алтайдан Кара диңгезгә хәтле булган биләмәләрдә гомер кичергән. Алар төрле кабиләләрдән торган. Скифлар арасында төркиләр дә булганлыгы төрле хезмәтләрдә яңадан-яңа фактлар белән расланып тора. Алар турындагы материаллар антик дөнья тарихыннан килә, тарихта бу халык скиде, скиф һ.б. исемнәр белән билгеле.

Кайбер скиф сүзләре: *асу* – ачы, *игә* – ия, *гер* – җир, *иргу* – сикерү, *каинос* – каенана, *инә* – әни, *аиз/ооз* – авыз, *агыр* – авыр, *тери* – тире, *каез* – ремень, *арым* – ярым, *йелау* – елау, *ике, ватан, калай, бакыр, курчак* һ.б.

Аланнар хакындагы мәгълүматлар безнең эрага кадәр I гасырда ук очрый. Безнең эраның беренче гасырындагы Рим, Кытай, Кавказ галимнәренең хезмәтләрендә аланнар еш телгә алына. Аларның теленә караган берничә язма истәлек бар: «Зеленчук эпитафиясе», «Игорь полкы турында кыйсса» (XI гасыр), Иоанн Цецның алан телендәге фразасы (XII гасыр).

Аланнарга караган текстларда мондый төрки сүзләр теркәлгән: *киши* – кеше, *йок* – юк, *йурт* – йорт, *этә* – итә, *кан* – хан, *йуртлу* – йортлы, *от* – ат, *җ(ы)л* – ел, *асса* – үссә, *баг(к)а* – бага, карый, *басу* – дала, басу, *блесен* – беләсең, *алан* – алан, *темр* – тимер, *үйене* – өенә, *син* – син, *акра* – акыра, *кайтер* – кайтар, *тес* – җиз, бакыр, *кана* – кайда, *көрдең* – күрдең, *кинже* (төпчек) – кинҗә һ.б. [Зәкиев, 2008, б. 220-236; Рамазанова, 2016, б.243]. Күргәнебезчә, алан телендәге күп кенә сүзләр хәзерге төрки телгә шактый якын.

Галимнәр борынгы славян һәм төркиләр арасындагы багланышлар безнең эрага кадәр IV гасырда бабаславян берлеге таркалган чорда барлыкка килгән дип саныйлар. Чөнки төрки халыклар – бу вакытта болгарлар – Азов һәм Кара диңгез буйларында яшәгән һәм славян күршеләре белән бергә тормыш-көнкүреш алып барган (Хабичев, 1975; Юсупов, 1980; Зәкиев, 1977; Добродомов, 1976; Фәттахов, 2013 һ.б.).

Болгарларның славяннар белән бәйләнешләре VI гасырдан да алдарак башлана. Славян телләренең барысында да табыла торган төрки элементларның зур күпчелеге гомумславян теленә бик борынгы заманнарда ук борынгы болгар теленнән кергән дип санала.

Күрсәтелгән фактлар болгар теленең гадәти төрки тел икәнен раслый. Азов һәм Кара диңгез, Төньяк Кавказ ареалында яшәгән бәҗәнәкләр, хазарлар һәм болгарларның безнең эраның II меңьеллыгы башында бергә тормыш-көнкүреш итүләре рус елъязмаларында да ачык чагылыш тапкан. Д.Б.Рамазанова борынгы болгар чоры лексикасын табу һәм анализлауда Ф.Р.Латыйпов (2013), Ф.Ш.Фәттахов (2013), Р.М.Кадыйров (2014), М.З.Зәкиев (2008) һ.б.ларның хезмәтләре аеруча әһәмиятле дип ассызыклый. Аларда протетик авазлар турында да материаллар бар, бу исә протезаның чуаш теленә генә түгел, башка борынгы телләргә дә хас булуын, алынма сүзләрне үзләштергәндә әһәмиятле роль уйнавын күрсәтә.

Р.М.Кадыйров күрсәтүенчә, болгарлар Европада белгиялеләр, ирландлар, итальяннар һәм немецларның тарихында әһәмиятле роль уйнаган [Кадыров, 2014, с.249].

Болгарлар Италиядә дә борынгы чордан ук билгеле булганнар. Болгарлар бирегә безнең эраның 568-686 нчы елларында күчеп килгәннәр дип санала. Монда да болгарлар белән бәйле бик күп топонимнар сакланып калган. Италиядәге болгарлар тарихын өйрәнүче Винченцо Д'Амико 1943 елда Италиядә 3 млн чамасы кеше Булгари, Булгарелли, Булгарино, Булгаро, Булгарани фамилияләрен йөртә дип күрсәтә. Рим кардиналларыннан берсе Пьетроның (ул 560 елда туган) да фамилиясе Булгаро булган. Италиядәге болгарлар, хронистлар күрсәтүенчә, безнең эраның VIII гасыр азагына хәтле үз телләрендә сөйләшкән.

Болонья шәһәре университеты XVI гасырга кадәр Болгар университеты дип, ә үзәктәге мәйдан «Болгар мәйданы» дип йөртелгән. Мәхмүт Кашгарыйда, шулай ук Шәмсетдин Суфый әсәрләрендә Каспий диңгезе Болгар диңгезе дип аталган. Төп Кавказ сырты Болгар таулары дип йөртелгән. Төркиядә дә «Булгар даг» дигән таулар системасы бар икән [Кадыйров, 2014].

Татар телендә болгар сүзе дип каралган лексик берәмлекләр шактый табыла: М.Кашгарый, Р.Г.Әхмәтьянов, Х.Ш.Мәхмүтов, Л.Т.Мәхмүтова, Н.Б.Борһанова, К.М.Мусаев, А.В.Дыбо һ.б., аеруча Р.Г.Әхмәтьяновның этимологик сүзлекләрендә. Бу өлкәдә Болгария галимнәренең эзләнүләре кызыклы, чөнки алар бабаболгар суперстратын барлауга юнәлтелгән (М.Москов, Т.Яруллина, И.В.Шишманов, И.Г.Добродомов, А.Г.Вәлиева, Р.Ф.Нәбиев).

Д.Б.Рамазанова борынгы төрки чор белән татар әдәби телен «Древнетюркский словарь» (1969) буенча чагыштырып, үзенең күзәтүләрен тәкъдим итә. Әйтергә кирәк, әлеге күзәтү бик әһәмиятле, чөнки автор татар теленең лексикасы VIII-XIII гасырларда ук формалашкан икәнлеген ача. Кайбер сүзләргә кыскача аңлатмалар бирелгән, аерым сүзләр диалектларда гына сакланып килә.

Билгеле булганча, «Древнетюркский словарь» VII-XIII гасырларны үз эченә ала. Әмма тикшеренүләр һаман арта тора һәм борынгы чорның вакытын бераз кыса төшәргә мөмкин дип, автор борынгы төрки чорны VIII-X гасырлар белән чикләп буладыр дигән фикерен дә белдереп уза [Рамазанова, 2016, б.245].

Хезмәттә сыйфатлар, саннар, алмашлыклар һ.б. буенча кызыклы күзәтүләр китерелә. Алмашлыклар – бик борынгы сүз төркеме. Алар шумер, этруск, америка һиндиләре телләрендә үк (*ми* – мин, *си* – син, *ол/ул* – ул һ.б.) очрый. Күп кенә татар сөйләшләрендә әдәби *миңа/синә*, *минем/синең* алмашлыклары *мәңа/мага*, *сәна/сага, сәнең, мәнең* дип әйтелә. Бу борынгы әйтелешләр белән дә бәйле булырга мөмкин. Борынгы төрки телдә *бәни* – мине, *бәнем* – минем, яки *сәнең* – синең формалары булган.

Пермь сөйләшендәге *минеңдән* – миннән, *сәнеңдин* – синнән, *минеңдә* – миндә дә борынгы төрки телдә булган. Пермь, нократ, себер сөйләшләрендә борынгы төрки телгә хас формалар яшәп килә.

Сыйфатларның бер өлеше ностратик сүзләр тезмәсендә үк урын алган: кара, кызыл һ.б. Алтай чорыннан, мәсәлән, *күк, сары, яшел, җирән, кечек, асан, буе, туң* һ.б. сыйфатлар билгеле.

Борынгы төрки телдә кайбер сүзләрнең тамырлары гына чагылган: сы – сындыру, *йиг* – җегерләү, орчык, *чып* – чыбык, *тал* – талак, *өз* – үзәк, *том* – томау, *са* – санау, *уз* – оста, *чит* – ситсы һ.б. Шушы ук рәттә кайбер борынгы төрки сүзләрнең хәзерге телгә килеп җитмәве дә күзәтелә: *кырмачы* – столяр, *күвүк* – салам, *салчы* – пешекче, *тизиг* – мәрҗән, *сарым* – сөзгеч (саркыту, димәк, сар тамыры булган) һ.б. Бүгенге

Болонья шәһәре (Италия) университеты XVI гасырга кадәр Болгар университеты дип, ә үзәктәге мәйдан «Болгар мәйданы» дип йөртелгән.

татар теленең иң әһәмиятле сүзләре, төп лексик фонды борынгы төрки телдә үк шактый тулы системаны тәшкил иткән.

Д.Б.Рамазанованың хезмәтендә татар теленең лексикасын тарихи планда тикшерү өчен мул материал тупланган. Ул татар теле лексикасының тарихы белән генә түгел, гомумтөрки лексиканың формалашуы белән шөгыльләнүчеләрдә дә кызыксыну уятырлык.

Гомумән, телебезнең сүзлек составы гаҗәеп дәрәҗәдә бай булып оешкан. Аның лексик системасы бүген дә хәрәкәттә, туктаусыз үсештә. Д.Б.Рамазанова һәм башка галимнәребезнең тел тарихы, аның лексик фондының тарихи үсеш-үзгәреше мәсьәләләренә кагылышлы күзәтүләре һәм хезмәтләре туган телебезнең үткәнен белү һәм киләчәгебез өчен бик әһәмиятле.

Әдәбият:

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). 543 б.; II том (М-Я). – Казан: «Мәгариф–Вакыт», 2015. – 567 б.

2. Десницкая А.В. О хеттском языке (вступительная статья) // Фридрих И. Краткая грамматика хеттского языка. – М.: 1952. – 3-35 с.

3. Зәкиев М.З. Татар халкы тарихы (этник тамырлары һәм киләчәге). – Казан: 2008. – 544 б.

4. Иллич-Свитыч В.М. Опыт сравнения ностратических языков (семитохамитский, картвельский, индоевропейский, уральский, дравидийский, алтайский). Т.I. – М., 1971. – 370 с. Т.II. – М., 1976. – 156 с.; Т.III. – М., 1984. – 135 с.

5. Кадыров Р.М. Глобальный характер булгарской цивилизации. – Ульяновск: 2014. – 25 с.

6. Каримуллин А.Г. Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы. – М.: «Инсан», 1995. – 80 с.

7. Латыпов Ф.Р. Факты шумерского языка как основного предтюркского субстрата, участвовавшего в формировании пратюркских языков Древнего Ближнего Востока. – Уфа: «Полиграфиздат», 2009. – 68 с.

8. Рамазанова Д.Б. Татар тарихи лексикологиясенә материаллар (борынгы чордан болгар чорына кадәр). – Казан: Школа, 2016. – 412 б.

9. Сулейменов О. Аз и Я. Книга благонамеренного читателя. – Алма-Ата: Жазушы. 1975. – 304 с.

10. Фомина М.И. Современный русский язык: Лексикология. – М.: Высш. школа, 1978. – 256 с. ■

Безнең мирас №6 июнь 2020

Көлке куа килә...

Илдус Гыйләҗев
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Илдус Гыйләҗев
(1946-2018)

Ак эт бәласе кара эткә

Бер ир бичә алыштырган,
Алтмыш яшьтә бозган антын.
Игәүләпме игәүли бит,
Ишеткән дә шуны хатын:
«Барыгыз да бер чыбыктан,
Сиңа да бит тиздән алтмыш.
...Кемдер рәхәт чиккән өчен,
Мин җәзасын күреп ятмыш...»

Мөхәммәт Мәһдиев
(1929-1995)

Үз хатының
(Күзәтүләрдән)

Ул үз хатыны белән танцыга чыккан кеше кебек тонык, кәефсез.

***

Үз хатының белән ресторанга барып танцевать итеп йөрү кебек мәгънәсез эш бу.

***

Колхоз председателе әйтә:
– Үз хатының янында әтәчләнеп булмый, чөнки синең бөтен кимчелегеңне белүче кеше бу дөньяда бары ул гына.

1985

Авторы билгесез

Максатыма ашыгам

Әй, үзем ашкынам,
Әй, үзем ашыгам.
Җил-яңгыр булса да,
Изүләр ачылган.

Ярсу ат шикелле
Барам да барам мин.
Ниһаять, ашханә...
Ашыгып, чәй, котлет
Һәм токмач алам мин.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1975 ел)

Безнең мирас №6 июнь 2020

Туфан Миңнуллин
(1935-2012)

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Җырламый тормыйк әле...

Моннан 7-8 еллар элек заманча татар җырларына пародия язган идем. Барлык агач, чәчәк-үлән исеме татар җырларына кереп бетте, калса, алабута, тигәнәк, шайтан таягы гына калгандыр, дигән идем. Ниһаять, радиодан «Тигәнәк» дигән җыр яңгырады. Сөенеп туя алмадым. Инде хәзер алабута белән шайтан таягы гына калды. Хәер, тигәнәкнең малай чагы – әрекмән бар икән әле. Тиздән алар турындагы җырны түземсезлек белән көтәм. Булыр, Алла боерса, җыр язучылар – талантлы халык. Мин үзем дә әле бирешергә теләмим. Җыр сәнгатенә чираттагы өлешемне кертеп, «Әрекмән» дигән җыр тексты язып ташладым:

Ком чүлендә – төрекмән,
Юл читендә – әрекмән.
Ташлап китәм, дип өркетмә,
Өркетсәң дә, өрекмәм.
Кушымта:
Әрекмәнем, әрекмән,
Серләремне белдертмәм –
Тәнем белән берексәм дә,
Җаным белән берекмәм.

Җырлагыз, дускайларым! Әрекмән генә җитми, дисәгез, шайтан таягына да җырым әзер:

Кайсы гөлгә тиңлим сине,
Шайтан таягынамы?
Күңелләрем сөрлеккәндә,
Сиңа таяныргамы?
Кушымта:
Шайтан гөле чәнечкеле,
Чәчәгенең исе юк.
Кит янымнан, шайтан тәре,
Йөрәгең бар, хисең юк.

Әгәр дә инде шайтан таягына милли-сәяси төсмер биреп җырларга телим, дисәгез, ошбу вариантны тәкъдим итәм:

Ник татарник диләр сине,
Чәнечкеле булгангамы?
Безгә кулын сузучының
Учын чәнчеп торгангамы?
Кушымта:
Әлеге дә баягы,
Без ул – шайтан таягы.

Җыр тексты язу өлкәсендә иҗат ачылып китте бит әле. Әниләргә милиун җыр язылды, әтиләргә багышлап бер-ике җыр гына чыкты. Беркөн «Апаем» дигән җыр ишеттем. Бутәннәр өлгергәнче, әби-бабайларга да җыр язып кую – саваплы эштер:

Рәхмәт әйтә белик бабайларга –
Алар безнең алда йөрүче.
Безнең ише уңган егетләргә
Кирәк чакта акча бирүче.
Кушымта:
Әти ягыннан да – бабаем,
Әни ягыннан да – бабаем,
Айгыр печкәндә дә,
Сыра эчкәндә дә,
Сездән генә үрнәк алаем.
Монысы әбиләргә:
Әби, әби, әбәктер,
Әби безгә кирәктер.
Әбиләрнең кирәклеген
Белмәгәннәр сирәктер.
Кушымта:
Әби, әби, әбәнәк,
Бабайдан ул тәбәнәк.
Безнең өчен әби чаба –
Атлап түгел, тәгәрәп.

5 апрель, 2004 ел ■

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Казанда «Аллаһның сөекле рәсүле Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәллам» дип исемләнгән китап чыкты. Аның авторы – күренекле дин әһеле, Казандагы «Миргазиян» мәчетенең имам-хатыйбы Габдеррәүф хәзрәт Зәбиров.

● 9 майда Җиңү паркында Дан мемориалы колоннадасының Мәңгелек утына чәчәкләр салу һәм Совет солдатына һәйкәл ачу тантанасы узды.

Әлеге күркәм чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе, Россиянең Хезмәт Герое Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР премьер-министры Алексей Песошин, Казан мэры Илсур Метшин катнашты.

● 11 майда Чирмешәндә, ТАССР төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан, ярты гектар мәйданда ике меңләп карагай агачы үсентесе утыртылды.

● Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров авылдашлары – Яңа Шимбер халкына бик матур бүләк ясады: ул, Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, сугышта һәлак булганнар истәлегенә обелиск төзетте.

● 13 майда Әлки районының административ үзәге булган Базарлы Матак авылында – әдип исемен йөрткән гимназия бинасы каршында – язучы һәм фронтовик Нәби Дәүлигә һәйкәл ачылды. Әлеге тантанада Нәби Дәүлинең кызы Гөлфия Дәүләтшина, Әлки районы башлыгы Александр Никошин, Әлки районының Якташлар җәмгыяте рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Алсу Нәбиева, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим һәм башка рәсми затлар катнашты.

● 15 майда КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтының беренче директоры, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнү буенча методик кулланмалар авторы, күренекле тюрколог Җәмил Габделхак улы Зәйнуллин вафат булды.

● Буа районының Аксу авылында «Гыйниятулла бабай чишмәсе»н яңартканнар. Авыл халкы әлеге күркәм эш өчен 60 мең сум акча җыйган.

● 18 майда ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы Алинә Заһитованы туган көне белән котлады.

«Кадерле Алинә! Сине 18 яшьлегең белән котлыйм. Бәхет, сәламәтлек, уңышлар һәм синең талантыңа лаеклы яңа югары максатлар телим. Янәшәңдә сиңа иң кыю башлангычларда ярдәм итәргә әзер торган эчкерсез, ышанычлы, яратучы кешеләр күп булсын. Татарстанлылар синең белән горурлана, сиңа ышана һәм чын күңелдән спортта һәм тормышта яңа җиңүләр тели. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе Ә.Ә.Сәфәров», – диелгән Хөкүмәт телеграммасында.


ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ ТЕЛЕГРАММА

Прием 16/05 го 13 час. 30 мин. Для заметок адресата
Бланк № 000301
Принял: А.П. Широбокова

КАЗАНЬ 200/1201Ч 108 16/5 1219=

ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ Г. ИЖЕВСК УЛ. [illegible] ЗАСЛУЖЕННОМУ МАСТЕРУ СПОРТА РОССИИ А. И. ЗАГИТОВОЙ=

ДОРОГАЯ АЛИНА.
ПОЗДРАВЛЯЮ ТЕБЯ С ВОСЕМНАДЦАТИЛЕТИЕМ.
ЭТО КРАСИВАЯ И ЗНАЧИМАЯ ДАТА В ЖИЗНИ КАЖДОГО ЧЕЛОВЕКА, И МНЕ ПРИЯТНО НАПРАВИТЬ В ЭТОТ ДЕНЬ СВОИ ПОЗДРАВЛЕНИЯ СОСТОЯВШЕЙСЯ ЛИЧНОСТИ, С СИЛЬНЫМ ЦЕЛЕУСТРЕМЛЕННЫМ ХАРАКТЕРОМ, ДОБИВШЕЙСЯ БЛИСТАТЕЛЬНЫХ РЕЗУЛЬТАТОВ В ИЗБРАННОМ ДЕЛЕ. ЖЕЛАЮ ТЕБЕ БОЛЬШОГО СЧАСТЬЯ, ЗДОРОВЬЯ, УДАЧИ, НОВЫХ ВЫСОКИХ ЦЕЛЕЙ, ДОСТОЙНЫХ ТВОЕГО ТАЛАНТА. ПУСТЬ РЯДОМ С ТОБОЙ БУДЕТ МНОГО ИСКРЕННИХ, НАДЕЖНЫХ, ЛЮБЯЩИХ ЛЮДЕЙ, ГОТОВЫХ ПОДДЕРЖАТЬ ТЕБЯ В САМЫХ СМЕЛЫХ НАЧИНАНИЯХ. ТАТАРСТАНЦЫ ГОРДЯТСЯ ТОБОЙ, ВЕРЯТ В ТЕБЯ И ИСКРЕННЕ ЖЕЛАЮТ НОВЫХ ПОБЕД В СПОРТЕ И В ЖИЗНИ.=
РУКОВОДИТЕЛЬ АППАРАТА ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН А. А. САФАРОВ
НР 02-Ч26Ч 16.05.2020 Г.-

НННН 1226 16.05 009

ПОЧТА РОССИИ

● Омск өлкәсенең Тевриз районында татарлар яши торган Тайчы авылы турында китап дөнья күрде. Авылның 300 еллыгына багышланган әлеге китапны шушы авылда туып-үскән этнограф Наилә Галиева өлкән яшьтәге кешеләрнең истәлекләренә, көндәлек язмаларына, архив документларына һәм фәнни әдәбиятка нигезләнеп язган.

● 19 май көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Кадер кичәсе уңаеннан Татарстан мөселманнарына мөрәҗәгать итте: «Дөньякүләм пандемия шартларында Татарстан Республикасы мәчетләре әлегә ябык. Әмма «Кадер кичәсе»н без өйдә дә каршы ала алабыз. Моның өчен безгә бер намазлык яки хәтта бер чиста почмак та җитә. Иң мөһиме — калебләребездә Раббыбызга карата мәхәббәт дөрләсен». ■

МИРАСВОРД



Ак төстәге хуш исле чәчәк ата торган куак

Грек хәрефе

Әдип ... (татар шагыйре, прозаик)

... дәфтәре

Җәлилче ... Бохаров

Бер илдә, төбәктә яшәгән барлык кешеләр (иск.)

Николай Гоголь повесте

Борынгы Мисырда: арыслан кыяфәтендәге кеше башлы сын

Урта диңгезнең көнчыгыш яр буенда урнашкан борынгы дәүләт

Рәт, мәгънә, җай

Борынгы семитларда баш Алла

XIX гасыр венгр композиторы

Кайбер Шәрык илләрендә чуклы милли баш киеме

Язучы ... Нуруллин

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

... Баширова (тел галиме)

Легендар крейсер

Җөмләнең баш кисәге

Себерне яулаган казак атаманы

Мөмкинлек, җай, чара

Йогышлы авыру

Мәшһүр фламанд рәссамы

Триумфаль ...

Габдерәхим Утыз ...

Хатын-кызларның борынгы бизәнү әйбере

Ислам, христиан

Греция мәркәзе

XVI гасыр итальян шагыйре, фәлсәфәче

Койма белән әйләндереп алынган урын, ишегалды

Франция каласы

Казакъларда киң таралган фольклор жанры, сюжетлы җыр

Итәк яки җиң очына тегелә торган тар тукыма

Ау мылтыгыннан ату өчен кара кургаштан ясалган шарчык

...-егет

Кораллы хезмәтчеләр, сакчылар (бор.)

Борынгы гарәп кыллы уен коралы

... Насыйри

Сибгат Хәким поэмасы

Гарәп әлифбасында тартыктан соң сузыкның булмавын күрсәтүче билге

Италиядәге елга

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Садри, Камо, батыр, гаур, Шәһит, би, Бари, игезәк, «Матәм», «Муса», каска, литавра, ачу, шәрех, Макс, Иво, Шәвәлиев, Ван, нар, Гурас, тити, нам.
Өстән аска: Сабир, лаеш, Бабич, дот, шат, ТУ, Әрә, мәргән, Ибраһимов, ал, Икар, Рим, «Тимка», сенат, Ауг, Васил, конгресс, Закиров, Мәгубә, Ева, Якир, Яхин.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / июнь



Брест крепосте каһарманы, Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов

1030 ел элек (990)

Кимәк каһанлыгыннан аерылып чыккан кыпчак кабиләләре бәҗәнәкләр яшәгән далага килеп керә. Бәҗәнәкләр исә, гаять ишле кыпчаклар тарафыннан кысрыкланып, Дунай елгасы буйларына күченеп китәргә мәҗбүр була.

215 ел элек (1805)

Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария» дигән хезмәте дөнья күрә.

120 ел элек (1900)

30 июньдә Брест крепосте каһарманы, Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов (1900-1979) дөньяга килә.

75 ел элек (1945)

16 июньдә Польшаның Згеж шәһәрендәге хәрби госпитальдә Гадел Кутуй (1903-1945) вафат була.

55 ел элек (1965)

«Совет әдәбияты» журналы «Казан утлары» исеме белән чыга башлый.

50 ел элек (1970)

Казанда «Татарстан» кунакханәсе ачылды.

30 ел элек (1990)

17-18 июньдә халыкара «Идел» лагерендә Беренче Бөтендөнья татар яшьләре көннәре оештырыла.

22-28 июньдә Татарстанда эстон әдәбияты көннәре булып үтә.

20 ел элек (2000)

4 июньдә Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов (1925-2000) вафат була.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Содержание. Июнь 2020

И останется в мире слово моё...: Рафаэль Тухфатуллин.

Историческое наследие: «Идегэй» – народный дастан». Л.Мухамматзянова; «Татары Ханской Орды (Ставка хана)». Г.Мырзагалиева; «Воспоминания, что сохранились в моей памяти». Г.Тухфатуллин; «Наши фамилии». Г.Хазиева; «Связь поколений». К.Тукаева; «Отражение деревни Полевые Бикшики в зеркале истории». Н.Каштан.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Стихи Исфандияра Ишгая»; «В Москву – дяде Миргазияну». Л.Лерон; «Наш дом был под ивами». М.Юныс.

В глубинах памяти: «Надгробный камень Баруди». А.Гайнутдинов; «Прокурор». Ф.Нафиев; «Ласточкино гнездо». С.Саубанова; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:



Мәкалә авторы Альберт Гаделшаның бабасы Сөнгатулла (аның алдында – улы Рәшит), әбисе Мәфрузә (оныгы Альберт белән), әнисе Гөлҗәннәт һәм әтисе Сафиулла. Зәй. 1940 ел

- Сон (Сөн) мәдрәсәсе тарихы. **Рәйсә Муллахмәтова**
- 75 ел эзләдем. **Альберт Гаделша**
- Мамадыш төбәгенең фольклор мирасы. **Гөлфинур Дувалова**
- Албай керәшеннәре бунты. **Юрий Карпов**
- Чукындыру сәясәте Үтәмешне дә читләтеп узмаган. **Нияз Исхаков**
- Мәхәббәт чокыры. **Камил Кәримов**

Әдип авылы — фотоларда

Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр. 1974 ел

Арча районының Яңа Кенәр авылына (язучы Рафаил Төхфәтуллин биредә җаваплы мөхәррир булып эшләгән) кагылышлы әлеге фотолар «Казан арты» тарих-этнография музее фондыннан алынды.

Яңа Кенәрнең милиция бүлеге хезмәткәрләре. Сулдан: Фәезхан Фәйзрахманов, Зөфәр Морзаев, Зәйнулла Нәбиуллин, Васил (фамилиясе билгесез). 1959 ел, июль

Гайшә Ермакова бакчада китмәнли. 1965 ел

Рафаил Төхфәтуллин Кызыл Юл районы газетасы һәм типография хезмәткәрләре белән. 1948-1949 нчы еллар

Безнең МИРАС

ИКЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫК ӨЧЕН
«БЕЗНЕҢ МИРАС»КА ЯЗЫЛ һӘМ БҮЛӘК ОТ!

БҮЛӘКЛӘР:

· ЭЛЕКТРОН КАЛӘМЛЕ КОРЪӘН · ТАТАР БҮРЕГЕ · НАМАЗЛЫК ·
· КӘЛӘПҮШ · ШӘЛ · МӨСЕЛМАН ЯУЛЫГЫ · ЧИТЕК ·

Язылу квитанциясенең күчермәсен yanamiras@mail.ru электрон почтасына яки элемтә бүлеге аша хат белән ошбу елның 25 июненә кадәр юлла!
Хәбәрләшү өчен телефон номерыңны да язарга онытма.
Җиңүчеләр 1 июль көнне «Безнең мирас» журналының инстаграм аккаунтында (@beznenmiras) туры эфирда ачыкланачак.
Изге айларда кадерле әби-бабайларыңа, әти-әниләреңә һәм якын туганнарыңа саваплы гамәл кылырга ашык – аларга «Безнең мирас»ны яздыр!

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.